ПРЕЗИДЕНТ ӘЙТТЕ

Владимир Путин журналистлар сорауларына җавап бирде

> 2

БӘЙРӘМГӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

Яңа елны ничек каршы алырга?

> 10

ӘСХӘТ ХИСМӘТ:

«Мин – чып-чын татар ир-аты»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 188 (28770) | Җомга | 24 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

АКЧАМ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА?!

ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕННӘН СОҢ КЕСӘДӘ ҖИЛЛӘР УЙНАМАСЫН

Бер генә яшибез! Адәм баласының күңеле ял теләгәндә иң еш әйтелә торган сүз бу. Бәйрәм вакытларында, бигрәк тә Яңа елны каршылаганда аны аеруча еш ишетергә туры килә. Шушы шигарь астында табыны да мулдан әзерләнә, бүләк бирешү, күңел ачуга да саранланып торыш юк. Яңа елны матур һәм купшы итеп каршы алу өчен хәтта банктан кредит алучылар да бар.

> 5

Ишетми калмагыз

Шәхси йортлар күбрәк төзеләчәк

Киләсе елда Татарстанда 2,75 миллион кв. метр торак мәйданын файдалануга тапшыру күздә тотыла. 2023 елга төзелгән пландагы күрсәткеч – 2,8 миллион кв. м чамасы. Бу хакта төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илшат Гыймаев белдергән. Белгечләр фаразлавынча, төзелешнең якынча 40 проценты күпфатирлы йортларга, 60 проценты шәхси йортларга туры киләчәк. Хәзерге вакытта Татарстан торак төзү буенча Россиядә җиденче урында бара. Ә Идел буе федераль округында – Башкортстан белән бертигез дәрәҗәдә. Республиканың төгәл урыны киләсе елның гыйнвар – февраль айларында рәсми йомгак ясалганнан соң билгеләнәчәк.

Әйбәт хезмәт хакы кайда?

Спортчы-инструктор, директор һәм товар төрүчеләр. Хәзерге вакытта Татарстанда иң зур хезмәт хакы алып эшләүче һөнәр ияләре бу. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, бүген спортчы-инструктор – аена 100 мең сум, директор – 87 мең, товар төрүче – 91 мең, машинист-торба салучы – 90 мең, химия һәм нефть сәнәгате предприятиеләр җиһазын монтажлаучы 82 мең сум акча алып эшли. Электр белән эретеп ябыштыручы, тимерче, монтажникның да хезмәт хакы аз түгел: 67 мең сум. Шул ук вакытта Татарстанда декабрь башына 61 мең чамасы буш эш урыны булган. Шуның 42 меңнән артыгракы (69%) – эшчеләр өчен. Татарстанда 11,5 мең кеше эшсез буларак теркәлгән.

Чамасын белеп кенә

Хәмерне теләсә кайдан сатып алу фаҗига белән төгәлләнергә мөмкин. Дәүләт алкоголь инспекциясе контроль-инспекция бүлеге башлыгы Татьяна Хәбибуллина шулай дигән. Аның сүзләренә караганда, хәмерне һич тә кулдан һәм интернет аша алырга ярамый. Ул шулай ук әлеге продукцияне интернет аша сатуның закон нигезендә тыелуын искә төшергән. Хәбибуллина көмешкә сатучылардан да читтәрәк йөрергә киңәш иткән. Анысы да сәламәтлеккә зур зарар салырга мөмкин, дигән ул.

Сәламәтлек саклау министрлыгының баш психиатр-наркологы Резеда Хәева әйтүенчә, хәмер эчү аркасында үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә җитүчеләр гадәттә 5–8 гыйнвар тирәсендә нык арта башлый.

РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ:

«МИН КЫШ БАБАЙГА РӘХМӘТЛЕ»

ВЛАДИМИР ПУТИН ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН АРАЛАШТЫ

Икътисад коронавируслы чорны ничек кичерде? Президентның иң яраткан министры кем? Кыш бабайга ул ни өчен рәхмәтле? Россия Президенты Владимир Путин журналистлар белән зур матбугат очрашуы оештырды. Кемдер – кызыл күлмәге, кайсы кызыл йөрәге белән Президентның игътибарын җәлеп итәргә, кызыксындырган соравына җавап алырга теләде. Татарстан вәкиленә дә бу уңыш елмайды. «ВТ» исә чараны онлайн күзәтте. Президент журналистлар белән нәрсә турында сөйләште?



kremlin.ru

Коронавирус һәм икътисад

Билгеле инде: матбугат очрашуына җыелганнарның күпчелеген коронавируска бәйле сораулар борчыды. Беренче сорау шушы инфекциягә һәм аның ил-көн тормышына йогынтысыннан башланды да. Россия икътисадтагы киеренкелекне ничек кичерә? Бу чордагы Хөкүмәт эшеннән дәүләт башлыгы канәгатьме?

Владимир Путин әйтүенчә, коронавирус белән көрәш әле дә дәвам итә. «Аның икътисадка тәэсире турында күп сөйләнде. Коронавирус алдыбызга китереп куйган бурычларга, башка илләр белән чагыштырганда, күпкә әзерлеклерәк булып чыктык. Икътисадтагы кимү дәрәҗәсе 3 процентны тәшкил итте. Без башкаларга караганда икътисадны тизрәк торгыздык», – диде дәүләт җитәкчесе.

Владимир Путин сүзләренә караганда, быел тулай эчке продуктның 4,5 процентка үсеше көтелә. Үзгәреш башка өлкәләрдә дә бар.

– Сәнәгать җитештерүчәнлеге – 5, эшкәртү җитештерүчәнлеге 5,2 процентны тәшкил итә. Төзелешкә бәйле күрсәткечләр яхшы. Быел 90 млн квадрат метр торакны кулланышка тапшырдык. Инфляция 8 процент булыр дип фаразлана. Бу алдан фаразлаган күрсәткечтән күбрәк. Эшсезлекнең пандемиягә кадәр булган күрсәткеченә кайтасыбыз килгән иде. Ул 4,6 иде, хәзер – 4,3. Дәүләтнең тышкы бурычы бераз кимеде, – дип сөйләде Президент. – Безне борчый торган бер мәсьәлә – гомер озынлыгы. Ул бераз кыскарды. Узган ел 71,5 булса, хәзер – 70,1. Бу – коронавирусның тискәре йогынтысы.

Владимир Путин Хөкүмәт һәм Үзәк банк эшчәнлеген уңай бәяләве турында әйтте. «Азрак тыйнак булыйк – канәгатьләндерерлек эшчәнлек. Нәтиҗәләре яхшы», – диде ул.

Коронавируска бәйле вазгыятькә килгәндә, ил җитәкчесе хәзер инфекциягә каршы күмәк иммунитет дәрәҗәсе 59,4 процентка җитүе турында белдерде. Тик бу гына җитми. Коронавирустан күпләп үлүчеләр саны да күмәк иммунитетның тиешле дәрәҗәдә булмавына бәйле дигән фикердә Президент. «Яңа штамм һәм инфекцияләр дә сәламәтлек саклау тармагында проблемалар һәм иммунитет дәрәҗәсе түбән булган җирдә барлыкка килә. Хәзер иң мөһиме – вакциналарны үзара тану һәм аларны бөтен дөнья буенча мөмкин кадәр тизрәк, күбрәк күләмдә тарату. Глобаль бәлане башкача хәл итә алмаячакбыз. Кайбер илләрдә 90–95 процентка ирешү зарурилыгы турында сөйлиләр», – диде ил башлыгы.

Шул ук вакытта вакцина ясатудан баш тарткан өчен җәза булырга тиеш түгел дип саный Владимир Путин.

– Безнең халык тапкыр ул: басым ясый башласаң, чикләүләрне урап узу юлларын табачак. Нинди фикердә булуына карамастан, кешеләргә хөрмәт белән карарга кирәк, – диде ул.

Үсеш нокталары

Владимир Путин матбугат очрашуы барышында илнең алга таба үсешендә төп өч бурыч торуын билгеләп үтте. Аның берсе демография белән бәйле. «Шундый зур ил өчен 146 млн җитми», – дип искәртте Президент. Тагын бер мөһим мәсьәлә инфраструктурага бәйле. Бу максатларга илкүләм проектлар кысасында да акча бүлеп бирелә. Өченче бурыч – хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру.

Очрашуда пенсия турында да сүз булды. Владимир Путин фикеренчә, Хөкүмәт пенсия күләмен чынбарлыктагы инфляция дәрәҗәсенә карап индексацияләргә тиеш. «Моны һичшиксез эшләячәкбез», – диде ул. Хокук саклау органнары һәм көч структуралары хезмәткәрләренең акчасы һәм пенсиясе дә чынбарлыктагы инфляция дәрәҗәсенә карап индексацияләнергә тиеш.

Тышкы һәм эчке сәясәт

НАТО һәм Россиянең мөнәсәбәтләре турында сораугa Путин: «Безне алдаладылар. НАТО үз көчләрен көнчыгышка юнәлтмәячәк дип ышандырган иде. 90 нчы елларда шулай вәгъдә иттеләр», – дип җаваплады.

Кытай белән мөнәсәбәткә килгәндә, Президент анысын дусларча дип атады. «Без бер-беребезне дуслар дип атыйбыз. Бу эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырырга мөмкинлек бирә. Азия тиз үсеш ала, Кытай дөньякүләм икътисадта алдынгы саналa. Төрле юнәлешләрдә эшлибез», – дип шәрехләде ул.

Оппозиционер Алексей Навальныйга бәйле хәлгә килгәндә, Россия Президенты бу вакыйга турында сөйләүне туктатырга кирәк булуын белдерде.

Украина турында әйткәндә, ил башлыгы алар белән күршеләрчә мөнәсәбәт корырга теләүләрен белдерде. Әмма хәзерге җитәкчелек белән моңа ирешеп булмый.

Татарстан соравы

Владимир Путинга сорау бирү бәхете «KazanFirst» интернет-басмасы редакторы Кирилл Шлыковка елмайды. Татарстан вәкиле күпбалалы гаиләләр өчен җир кишәрлекләрен бүлеп бирү һәм әлеге территорияләрне алга таба да үстерү мөмкинлеге турында сорашты. Журналист республикада күпбалалы гаиләләрнең күп булуын, җир кишәрлекләре бирелсә дә, инфраструктура юклыгыннан даими рәвештә зарлануларын ишетергә туры килүен әйтте.

– Россиядә инфраструктураны үстерүгә күп акча бүлеп бирелә. Бу ихтыяҗларны проектларга кертергә кирәк. Хөкүмәт алдына мондый бурыч куелыр, – дип җавап бирде Владимир Путин.

Инфраструктура димәктән, матбугат очрашуында авылларның хәле турында да сүз булды. Президент моңа бәйле эшне зур бурыч, комплекслы эш дип атады. «Инфраструктура үсешенә китәчәк акчаның зур өлеше авыл җиренә кагыла», – диде ул.

Интернетта куркынычсызлык

Бу мәсьәлә турында күптән сүз куерталар инде. Әйтик, социаль челтәрләргә паспорт белән генә теркәлү мөмкинлеген дә тәкъдим итеп карадылар. Ил башлыгы бу уңайдан ни уйлый?

– Интернет безнең тормышның күп өлешен алып тора. Димәк, ул да әхлак кагыйдәләренә һәм законга буйсынырга тиеш. Күп кенә илләрдә трафикны киметү, челтәрләрне юк итү кебек ысуллар кулланалар. Мондый чараларга ук бармаска иде безгә. Алтын урталык кирәк, – диде Президент. – Ирекне дә чикләргә кирәкми, җәмгыятьне тискәре күренешләрдән дә саклау мөһим.

Европага газ җибәрү

Европага газ җибәрү һәм бәя артуда Россияне гаепләүләр турындагы сораугa:

– Ялганлыйлар инде һаман. «Газпром» соралган күләмне җибәрә, хәтта арттыра да. Минемчә, бу – бердәнбер шундый компания. Америка да Европа базарына сатасы газ күләмен киметте. Бәя артты. Монда, саный китсәң, кытлык тудырырдай сәбәпләр күп. Европадагы төп кулланучыбыз – Германия, – диде ил җитәкчесе.

Төрмәдә көч куллану

Бу хакта сорауны ил башлыгына Ксения Собчак бирде. Владимир Путинның бу җәһәттән җавабы мондый булды:

– Көч куллану һәм кешеләргә карата рәхимсез мөгамәлә күрсәтү Россиянең генә проблемасы түгел. Башкаларда да моңа бәйле хәл ителмәгән мәсьәләләр аз түгел.

Төрлесеннән

Чара гел җитди рухта гына бармады. Мәсәлән, журналистлар Владимир Путиннан аның Кыш бабайга мөнәсәбәте турында кызыксынды. «Әлегәчә Кыш бабай белән минем арадагы мөнәсәбәтләр яхшы иде. Мин аңа рәхмәтле. Ә аеруча зур рәхмәтем – Россия халкына. Президент вазыйфасын ышанып тапшырган өчен», – диде Владимир Путин.

Шәхси сорауларга да вакыт калды. Дәүләт җитәкчесеннән спортка, блогерларга мөнәсәбәтен сораштылар. «Спорт белән шөгыльләнүне бурычым дип саныйм. Блогерлар тормышын күзәтмим. Гомумән, мин ФСБ җитәкчесе вазыйфасыннан киткәннән бирле беркем артыннан да күзәтмим», – дип җаваплады ул бу сорауларга.

Хөкүмәттәге яраткан министрлары турында да кызыксындылар.

– Андыйлар булырга да мөмкин түгел, булмады да. Күпләре белән озак еллар эшлим, аларны яхшы беләм. Әгәр дә нәрсәнедер эшләп җиткермәүләрен күрәм икән, шәхси мөнәсәбәтләребез нинди булуга карамастан, әйтәм. Теләсә кайсы сорауга тиешле мөнәсәбәт күрсәтүләренә ирешәм, – диде ул.

Мәскәү белән Санкт-Петербургтан кала, яшәү өчен кайсы шәһәр иң яхшысы? Дәүләт җитәкчесе Россиядә зур шәһәрләр белән бергә кечкенәләре дә үсеш ала дигән фикердә.

– Безнең илдә үзенең уңайлы хис итә алырлык матур урыннар күп. Краснодар, Кырым һәм Казан яхшы үсеш алган, – диде ул.

Уфа турында

Күптән түгел Президент Уфа шәһәре юбилееи бәйрәм итү турындагы указны имзалады. Күршеләр аннан нинди ярдәм күрсәтеләчәге хакында кызыксынды.

– Уфага килергә тырышырмын. Искиткеч урын. Россиядә ислам дөньясы үзәкләренең берсе ул. Без республика җитәкчелеге белән өстенлекле юнәлешләрне билгеләячәкбез. Өстәмә ярдәм кирәк түгелдер. Булганнарыннан дөрес итеп файдаланырга кирәк, – диде Владимир Путин.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ПРЕЗИДЕНТ – ҖИРЛЕ ХАКИМИЯТКӘ:

«КАЗАННАН ГЫНА ЯРДӘМ КӨТЕП БУЛМЫЙ»

Авыл һәм шәһәр халкын чиста су белән тәэмин итү, муниципалитетлардагы хезмәт хаклары, җәмәгать транспорты. Муниципаль берәмлекләр советының Казанда узган XVI съездында әнә шул һәм башка мәсьәләләр күтәрелде. Съезд барлык район башлыкларын, республика дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары ветераннары, якташлык җәмгыяте, иҗтимагый берәмлекләр вәкилләрен бер залга җыйды.

tatarstan.ru

Ел дәвамында эшләнгән эшләргә йомгакны «Татарстан муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин ясады. Көн кадагындагы һәм халыкны борчыган сорауларның берсе итеп ул чиста су проблемасын күтәреп чыкты. Форум алдыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыклары белән очрашуын һәм аларның күпчелеген сыйфатлы су булмавы борчуын әйтте.

– Статистика мәгълүматлары буенча, республикадагы суүткәргеч челтәрләренең 32 проценты тузган. Бу – 6 мең чакрым тирәсе дигән сүз. Ун ел эчендә алыштырырга тиешле челтәрләр озынлыгы 800 чакрымга җиткән, – диде Әгъзам Гобәйдуллин.

Дөрес, Татарстанда су проблемасын хәл итүдә программаларның роле зур. Ел саен 650 млн сумга эшләр башкарыла. Ә 2010 елдан башлап 2700 чакрым суүткәргеч челтәрләр төзелгән. Шул ук вакытта күпчелек районнарда халыкны су белән тәэмин итү мәсьәләсе катлаулы булып кала.

– Су белән тәэмин итү чыганакларының күпчелек өлеше муниципалитетлар тарафыннан кадастр учетына куелмаган, күпчелек объектлар һәм челтәрләр авыл җирлеге карамагында. Аларны махсуслашкан оешмаларга тапшыру бик сүлпән бара. Шулай ук, алдагы сәбәпләр нәтиҗәсендә, скважиналарны лицензияләү дә акрын бара. Әлеге авырлыклар белән беррәттән су өчен тарифны билгели алмыйлар. Бу проблемалар йомгагын сүтәргә кирәк, алга таба сузудан мәгънә юк, – диде Әгъзам Гобәйдуллин.

Билгеле булганча, ел дәвамында муниципалитетларда территорияләрне планлаштыру документларын җайга салу буенча эшләр актив рәвештә алып барылды. Гомумән алганда, быел уңай күренешләр күп булды – 1096 торак пункт чикләре кадастр учетына куелган. Шул ук вакытта закон бу эшне 2024 елның 1 гыйнварына кадәр тәмамлауны таләп итүне истә тотып, район башлыкларына әлеге мәсьәләне шәхси контрольгә алырга кирәк. Беренче чиратта әзерләнә башлаган 994 торак пункт чикләре буенча документларны эшләү һәм кабул итү тора. Монда эш акчада гына түгел, ә оештыру һәм бюрократик сорауларда тукталып кала. 1029 торак пункт буенча эшләр әле башланмаган да. Әлеге эшләрне башкарып чыгарга акча кирәк, – диде Әгъзам Гобәйдуллин.

Су белән тәэмин итү проблемасына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та игътибар итте. Ул муниципаль берәмлекләр алдына бурычлар куйды.

– Республикада су буенча проблема зур, – диде ул. – Суны яхшы сыйфатлы итеп бирергә тиешбез. Яхшы сыйфатлы булсын өчен, бик күп акча түгәргә кирәк. Ә ул суны бакчага сибәбез, башка җирдә кулланабыз. Сусыз булмый. Һәр авылда, һәр шәһәрдә җитәрлек күләмдә су булырга тиеш.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, республикада бик күп эшләр эшләнә, эшләгән саен эш кимеми, арта гына.

– Районда эшләдек, моның кадәр программаның чирегә дә, ун проценты да юк иде. Шулай да тормыш алга бара, халыкның таләпләре хәзер икенче. Без бу таләпләргә әзер булып торырга тиеш. Монда күтәрелгән мәсьәләләр турында да беләбез, – диде ул.

Президент халык санын алуның алдан нәтиҗәләре белән канәгать булуын белдерде.

– Төгәл нәтиҗәләрне вакыты килеп җиткәч җиткерербез. Мин исә бераз алга китеп булса да әйтәм, республикада яшәүче халык саны арта. Бу безне бик сөендерә. Димәк, Татарстан кызыктыра. Килүчеләр булса да, килүчеләр кимрәк түгел. Дөрес, демография буенча да позитив динамика көткән идек. Ләкин пандемия безнең планнарны бераз бозды. Республика үзенең мөмкинлекләрен үстерә. Ул икътисады белән дә, уку йортлары, инвестицияләре белән дә кызыктыра. Яшәү сыйфаты буенча иң яхшы төбәкләрнең берсе, – диде ул.

Халык санын алу димәктән, Президент Туган телләр һәм халыклар бердәмлегe елы булган 2021 елга да йомгак ясады. «Нинди генә милләт кешесе булса да, телен өйрәнергә шартлар булырга тиеш. Татар теле генә түгел, чуваш, удмурт, мари, мордва телләре дә…Дини традицияләр буенча яшәргә шартлары булырга тиеш. Бу юнәлештә зур эшләр башкарыла», – диде ул.

Президент сүзләренә караганда, авыл территорияләрен комплекслы үстерү буенча да зур эшләр алып барыла. Бу мәсьәләдә аеруча актив районнар исемлегендә – Саба, Кукмара, Буа, Питрәч һәм Апас.

– Бүген съезд башланыр алдыннан без шәһәр һәм районнарга 69 юл-коммуналь техника тапшырдык. Шушы көннәрдә тагын 86 машина бирәчәкбез. Без техникадан башка сыйфатлы эш алып барып булмавын аңлыйбыз, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов җәмәгать транспорты белән авырлыклар барлыгына басым ясап, аерым бер урыннарда бу эш тиешле дәрәҗәдә оештырылмаганлыгын әйтте.

– Казаннан гына ярдәм көтеп булмый, урыннарда үзегезгә дә эшләргә кирәк. Транспорт схемаларын караячакбыз. Бу системада тәртип салырга кирәк. Монда акча мәсьәләсе генә түгел, ә оештыруны да карарга кирәк, – диде ул.

Әлбәттә инде, съездда пандемия турында да сүз булды. «Барлык хакимият органнарының төп бурычы – авырулар санын киметү һәм җәмгыятьне гадәти тормыш шартларына кайтару. 60 яшьтән узганнарны вакцинацияләү эшен җиренә җиткереп башкармыйсыз. Хәзер көненә 5–6 кешене югалтабыз, ә 10–12 кешене югалткан көннәр булды бит. Җирле хакимияттә аерым җаваплылык. Сездән башка бу проблеманы хәл итеп булмый. Чикләүләрне катгый үтәргә кирәк. Тикшерүләр белән чыгабыз, кайбер урыннарда моңа ваемсыз карауларын күрәбез. Бездә барысы да вакцинация узган: Минтимер Шәрипович, Фәрит Хәйруллович, мин дә инде берничә тапкыр. Көн саен эшкә йөрибез бит. Халыкка таралган сүзләрне фейк дип аңлатырга кирәк. Иң аянычы – кеше үлеме», – диде Президент.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЯРДӘМНЕҢ ЯЛЫ ЮК

Казанда «Бердәм Россия» партиясенең волонтёр үзәкләре быел башкарган эшкә йомгак ясадылар.

Партиянең генераль советы секретаре Андрей Турчак видеоконференция режимында уздырган утырышта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» төбәк бүлегенең сәяси советы секретаре Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Андрей Турчак әйтүенчә, 80 мең кеше икенче ел рәттән халыкка, медицина хезмәткәрләренә булыша. Ял көннәрендә башкаларга ярдәм итә, авыр тормыш хәлендә калучыларга булышу өчен үз көчен кызганмый. «Партия пандемиянең беренче көннәреннән башлап һәр төбәктә волонтерлар үзәкләре ачты», – дип искә алды Андрей Турчак. Аның сүзләренә караганда, быел партиянең волонтер йөртүчеләре 287 мең мәртәбә ярдәм күрсәтергә барган. Алар табибларны эшкә илткәннәр, алар белән авырлар янына йөргәннәр, мохтаҗларны хастаханәгә алып килгәннәр, дарулар илтеп биргәннәр. «Шул рәвешле табибларның транспортка булган ихтыяҗын бөтенләй диярлек канәгатьләндердек», – диде Андрей Турчак. Партиянең генераль советы секретаре әйтүенчә, «Бердәм Россия» волонтерлары быел авыру кешеләргә – 2 миллионга якын дару комплекты, «кызыл зона»да эшләүче табибларга исә 10 миллионнан артык азык-төлек җыелмасы илтеп биргән.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстанда бүген партия вәкиле булган 170 волонтер эшли. Кирәк булган очракта, аларның санын арттыру мөмкинлеге дә бар. Ноябрь аенда исә төбәк бүлеге әгъзаларыннан җыелган взнос акчасының бер өлеше ягулык карталары сатып алуга тотылган.

– Без, Россия Федерациясенең башка субъектларындагы кебек үк, авыруларга, аз керемле кешеләргә булышучы волонтерларга ярдәм итү эшенә алындык. Җаен автоволонтерларны бушлай ягулык карталары белән тәэмин иттек, азык-төлек һәм дарулар алып килдек, – дип сөйләде Фәрит Мөхәммәтшин. – Партия активы, яшьләребез, волонтерлар, табибларның пандемия вакытында килеп чыккан проблеманы хәл итүдә бик җаваплы булдылар.

Әйтеп кенә бактым

Юк инде бу илдә, юк...

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бүген кем иренми – шул зарлана. Кайчак юк-бардан гына бәхәс куптарабыз да күңелләр тулганчы тартышабыз һәм моннан үзенә күрә бер рәхәтлек хисләре кичерәбез. Бу бәхәс еш кына «Сүз югында сүз булсын, ата казың кукәй саламы?»га кайтып кала һәм аңа, гадәттә: «Юк инде бу илдә, юк», – дигәнрәк сүзләр белән нокта куела.

Мондый бәхәсләргә кызык өчен мин дә кушылам, әй, рәхәтләнеп, нәрсәнеңдер, кемнеңдер тетмәсен тетәбез. Тик бөтен бәхетсезлекләребездә ил гаепле булып чыга.

Беркөнне бер дус хатыныннан зарланды әле: «Картайган саен эзбиргә әйләнә башлады, малай!» – ди.

– Шуңа ук барып җиттемени? – дигән булам.

– И-и... бу хатын-кызга ирек бирсәңме? Эштән кайтам, ашарга әзер түгел. «Мин дә синең кебек үк эшлим. Әнә кешенең ире уч тутырып акча ала, хатыны тиеннәр санап утырмый», – дип авызны томалый. Үләм инде бу хатын белән, юк инде бу илдә, юк.

– Монда илнең ни гаебе бар? – мәйтәм. Дәшми, аптырап карап тора. Тагын нидән зарланырга, кемне сүгәргә – шул турыда баш вата иде бугай ул. Тик күңеленә бер-бер уй килми. Миңа кызык булып китте, кызуга ут өстисе килә генә бит!

– Балалар ничек?

– Нәкъ әниләре инде, гел киресен сукаларга гына торалар. Юк инде бу илдә, юк...

Аның бу сүзләре минем өчен үзенә күрә бер такмазага әйләнде дә куйды. Дус-ишләр белән очрашкач, ниләр генә турында сөйләшсәк тә, сүзне «юк инде бу илдә, юк» дип тәмамлыйбыз, үзебез эч катканчы көләбез. Чөнки минем даирәдәгеләр – Тукайча, ягъни «монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл» дип яшәүчеләр.

Үземнең чит илгә барганым юк, Төркияне исәпләмәгәндә. Шуңа күрә чит илдәге «җәннәт»тәй тормыш турында өздереп кенә бернидә әйтә алмыйм. Ә менә эшләмәсәң, бер җирдә дә балда-майда йөзеп булмаячагын беләм. Иң кызыгы: без тормыш әйбәтләнгән саен зарланабыз. Юк инде бу илдә, юк, тиз генә үзгәрә алмабыз, ахрысы.

Менә Яңа ел да якынлаша. Һәрвакыттагыча туар елларга өметләр баглыйбыз, бер-беребезгә иң матур теләкләр телибез. Әмма «Чит илләрдә яшәргә язсын!» дигән сүз ишеткәнем юк әле. Ә менә: «Илдә чыпчык үлми», – дип шактый еш кабатлыйбыз. Әле «ялгыз кайгы – кайгымыни, илгә кайгы килмәсен...» дип җырлап җибәрергә дә күп сорамыйбыз. Черек баеганнарның ишәя баруы турында ишетсәк тә, әллә ни исебез китми. «Тиге дөньяга күтәреп алып китә алмаслар», – дип күңелне тынычландырабыз. Хикмәтле илдә яшибез без.

Беркөнне Яңа ел турында сүз китте дә, дусларның берсе: «Яңа елны ничек каршылыйсың, шулай яшисең инде ул», – дип куйды. Бу – күптәннән яшәп килүче халык сынамышы. Әмма икенче беребез: «Яңа елга Россия халкының яртысы мүкәләп керә, димәк, мүкәләп яшәрбез микәнни?» – дигән шик белдерде. Не дождешься, дустым. Мүкәләсәк тә, җиргә егыла торган халык түгел без. Андый нәрсә бу илдә була да алмый. Чөнки без – инде менә ничә еллар буе егыла-тора яшәп өйрәнгән халык. Юк инде бу илдә, юк егылып яту дигәннәре.

КҮРШЕ МӘКТӘПКӘ ЙӨРТҮ – ӘТИ-ӘНИ ХОКУКЫ

tatarstan.ru

«Узып баручы ел җиңел булмады, кайгысы да булды». Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин мәгариф тармагына багышланган матбугат очрашуында елны әнә шулай дип бәяләде. Шулай да илкүләм проектларны тормышка ашыру буенча шактый эшләр башкарылган. Республикада 7 мәктәп төзелгән, ике һәм күптелле мәктәпләр ачылган.

Читнекенә кызыгу турында

Бүген әти-әниләрнең белем сыйфаты яхшырак дип, өйдән читтәрәк урнашкан мәктәпләргә кызыгу гадәте бар. Нәтиҗәдә үз авылларындагы мәктәпләрдә укучылар саны кими. Әлеге проблемага карата Илсур Һадиуллин үз фикерен белдерде.

– Без әти-әниләрне балаларын күрше авыл мәктәпләренә йөртеп укытудан тыя алмыйбыз. Мондый проблема бар. Аларны мәктәпләргә йә автобус, йә әти-әниләр үзләре машина белән йөртә. Авылда укучылар, укытучыларның дәресләр саны кимү сәбәпле, белем йортлары ябылырга мәҗбүр. Бу – бик зур проблема, әмма моны бернинди норматив документ белән дә хәл итеп булмый. Ни өчен дигәндә, бу – гаиләнең хокукы. Ул баласын үзе теләгән мәктәптә укыта ала, – диде министр. – Мондый хәлләр килеп чыкмасын өчен, укытучылар яхшы укыта, балаларны кызыксындыра белергә тиеш. Төп максат – яшь гаиләләр авылда төпләнеп, балалар санын арттыру.

Укытучылар җитмәү турында

– Бүген максатчан программа буенча укырга теләүчеләр алай күп түгел. Алар күп булсын өчен, киләсе елда безгә педагогика юнәлешендәге профильле сыйныфлар санын арттырырга кирәк. Соңгы вакытта укытучыларның дәрәҗәсен күтәрү, матди ягын кайгырту турында әйтәбез. Без сезнең белән күбрәк укытучының бөеклеге турында сөйләргә тиеш, – дип мөрәҗәгать итте министр журналистларга. – Укытучыны видеога төшереп, бертуктаусыз интернетка куеп яманлыйлар. Моны укучылар да күрә бит. Әти-әниләрнең хурлаганын да ишетеп торалар. Бу да укытучылыкка бармау өчен бер сәбәп булып тора.

Илсур Һадиуллин әйтүенчә, укытучылык эшенә җәлеп итүнең төрле юллары эзләнә. «Авыл укытучысы» федераль программасы буенча республика мәктәпләрендә 13 педагог эшли. Киләсе елда 23 укытучыны көтәләр. Бүген 640тан артык студент республика бюджеты хисабына укый. Шуның яртысы ике һәм күптелле мәктәпләр өчен әзерләнә. Аларга ай саен 15 мең сум стипендия түләнә. Максатчан программа буенча укыганда алар мәктәпкә беркетелергә тиеш. Башлангыч, физика, математика, рус теле, чит телләр укытучыларына кытлык бар. «Кайбер очракта вузларга аз баллы абитуриентлар килә, әмма без андыйларга ышана алмыйбыз. «Зле»гә укучы кемне әзерли ала – белмим», – диде Илсур Һадиуллин.

БДИ турында

Әлегә имтиханнар буенча расланган норматив документлар юк, ләкин аны коронавируска кадәрге форматта уздыру планлаштырыла. Рус теле һәм математика – мәҗбүри, вузга керү өчен ике ирекле фән сайлана. Быел чыгарылыш сыйныф укучылары БДИны яңартылган федераль стандартлар нигезендә тапшырачак. Биремнәр белемнәрне тормышта куллануга бәйле булачак.

Мәктәпләр төзү турында

Республикада яңа мәктәпләр төзелсә дә, уку йортлары җитми. Шул сәбәпле, 54 меңнән артык укучыга икенче сменада белем алырга туры килә.

– Шәһәр читендә мәктәпләр җитмәү кытлыгы бар. Бездә балаларның 11,89 проценты икенче сменада укый. Кайбер төбәкләрдә өченче смена да бар, бездә андыйлар юк, – диде Илсур Һадиуллин. – Без яңа мәктәпләр төзибез, төрле программаларга керергә тырышабыз, үзебезнекенә дә өметләнәбез. Мәктәп төзү һәр микрорайонда аерым карала. Кайбер укучыларны якын мәктәпләргә автобуслар йөртә. Барлыгы 810 мәктәп автобусы исәпләнә, 861 маршрут оештырылган. 23 меңнән артык баланы автобусларда йөртәбез. Бер бала да урамда калмады, барысын да урнаштырдык, әмма проблема бар әле. Әгәр урыннар булмау сәбәпле, баланы мәктәпкә кабул итүдән баш тартсалар, әти-әниләргә район мәгариф бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Балаларга вакцина ясату турында

– Хәзерге вакытта 12 яшьтән 17 яшькә кадәрге үсмерләргә коронавируска каршы вакцина ясату турындагы бернинди норматив документлар да юк. Әгәр Россия Мәгърифәт министрлыгыннан, республиканың ковидка каршы оператив штабыннан күрсәтмәләр булса, аны үтәргә тиешбез. Монда безнең яктан да, әти-әниләр тарафыннан да кыенлыклар булыр дип уйламыйм. Барысын да оештырырбыз, сораулар туса, аңлатырбыз, – диде республиканың баш педагогы.

Илсур Һадиуллин әйтүенчә, республика мәктәпләрендә һәр көн саен иртүк температурасы күтәрелгән, ютәлләгән 370–380 баланы өйләренә кайтарып җибәрәләр. Мәгариф хезмәткәрләренең 95 проценты вакцина ясаткан. Күпчелек уку йортларында бу сан 100 процентны тәшкил итә. Бары тик 30 укытучы гына эштән азат ителгән. Әмма аларга прививка ясату мөмкинлеге бирелеп, кире мәктәпләргә кайтканнар. «Бездә болай да укытучылар җитми, шуңа күрә моңа тыныч кына карый алмыйбыз», – дип аңлатты министр.

Сәрия МИФТАХОВА

АКЧАМ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА?!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Пандемия «җимеш»е

Банктан кредит алырга җыенуы хакында «Работа.ру» порталы уздырган сораштыруда катнашкан һәр ун кешенең берсе әйткән. Аларның 56 проценты бу акчаның күп өлешен бүләкләргә, 36 проценты бәйрәм табыны әзерләүгә тотмакчы. Бурычка алынган акчага Яңа ел каршылау өчен сәяхәткә китәргә җыенучылар да (23 процент), аны күңел ачу чараларына гына тотарга (15 процент) планлаштыручылар да бар. Бәйрәм дигәндә, аяк идәндә, кыскасы. Респондентларның күбесе 50 мең сум күләмендә бурыч алырга җыена. 25 проценты 100 мең сумга кадәр акча аласын әйткән. Күңел ачу һәм бүләкләргә тагын да күбрәк акча сарыф итәргә теләүчеләр дә бар.

Казан дәүләт медицина университетының клиник психологы Эльмира Миассарова халыкның шул рәвешле бәйрәм дип шашуын соңгы ике елда үзәккә үткән пандемия «җимеш»е дип саный. «Илдә кризис, пандемия кебек катлаулы вазгыять хөкем сөргәндә, кешеләрнең психикасы да үзгәрә башлый. Бу күбрәк рухи ныклыгы чамалы булган кешеләргә кагыла. Билгесезлек, иртәгәге көнгә ышанычы булмау, әледән-әле ишетелеп торган үлем-китем турындагы тискәре хәбәрләр, ахыр чиктә, үзенекен эшли. Кешене курку били, гел киеренке халәттә яши, хәвефләнә. Җәмгыятьтә киеренкелек арта бара. Кеше тормыштан ямь, тәм таба алмый тилмерә, аңа эмоцияләр җитми башлый. Бәйрәмнәргә, аерым алганда Яңа елга карата халыкта үзгә мөнәсәбәт барлыкка килү әнә шуның белән аңлатыла. Күргәнегезчә, күпләр җаны теләгәнчә ял итү өчен бернәрсә дә кызганмый, кредитка кадәр ала», – ди белгеч.

Исемлексез тотынма

Бер яктан, халыкның ел буе көтеп алган бәйрәмне күңеле теләгәнчә үткәрергә теләвенең бер гаебе дә юк. Ләкин тормыш бәйрәмнәр белән чикләнми шул. Озын-озак еллардан соң да кабат үз көенә дәвам итә ул. Яңа ел бәйрәменнән соң кесәдә җилләр уйнамасын өчен ни эшләргә? Акча тота белүнең сере нидә?

Бу сораулар белән финанс һәм хокук белгече, юрист Ләйсән ХАЛИКОВАга мөрәҗәгать иттек.

:: Ләйсән, ил халкының, бәйрәм дигәндә, кредит сазлыгына да батарга әзер булуын ничек аңларга?

– Безнең илдә менталитет шундый. Бүген халыкның финанс аң-белеме бик түбән. Шуның аркасында акча тота белмибез. Яңа ел – ел саен үткәрелә торган бәйрәм ул. Ел буена андый бәйрәмнәр шактый җыела. Аларның кайчан булачагын да, кемнәргә бүләк бирәчәгебезне дә якынча чамалыйбыз. Димәк, бу максатка дигән акчаны да алдан җыеп куярга мөмкинлегебез бар. Әйтик, сезгә бәйрәмгә бүләкләр алу өчен 10 мең сум чамасы акча кирәк була, ди. Айлык хезмәт хакының бер өлешен шундый бәйрәм

Илдар Мөхәммәтҗанов

чыгымнарына, икенче бер өлешен – финанс «мендәр»енә дип җыеп барырга кирәк. Ләкин без киресенчә эшләргә өйрәнгән. Бүгенге көн белән яшибез. Бәйрәм вакытларында, нәрсәдер алыр вакыт җиткәч кенә, бер тиен акча калмаганын аңлыйбыз. Бу очракта инде күпләр кредит алырга, йә булмаса, соңгы акчасына табын корырга, бүләкләр алырга мәҗбүр була. Чыгымнарын алдан планлаштырган кеше кыен хәлдә калмый.

:: Кешенең «кара көн»гә җыелган акчасы күпме булырга тиеш?

– «Кара көн»гә җыелган акча – алдарак телгә алынган шул ук финанс «мендәр»е инде ул. Аена ун мең эшлисеңме син, йөз меңме – мөһим түгел. Иң мөһиме аның бер өлешен, төгәлрәк әйтсәк, 10 процентын җыеп барырга кирәк. Әгәр кешенең мондый мөмкинлеге юк икән, анда аена кимендә 100 сум, 500 сум акча булса да җыелып барырга тиеш. Әгәр кеше үзе генә яши икән, аның кулында, ким дигәндә, өч айлык чыгымы күләмендә запас акчасы булса яхшы. Мисал өчен, айлык чыгымнары 10 мең сум икән, аның, ким дигәндә, 30 мең сум җыелган акчасы булырга тиеш. Гаиләле кешеләрнең финанс «мендәр»е алты айлык чыгым күләменнән дә ким булмаса яхшы. Бу акчаны яңа телефон, машина кебек зур әйберләр сатып алуга тотарга ярамый. Сәламәтлек какшау, эшсез калу яисә хезмәт хаклары киму кебек көтелмәгән хәлләр килеп чыга калса, кул астында булырга тиешле запас акча бу.

:: Яшерен-батырын түгел, бүген ил халкының күбесе бер хезмәт хакыннан икенчесенә кадәр яши. «Кара көн»гә 100 сум акча арттыра алмаган кешеләр дә бар. Бу очракта ни эшләргә?

– Акча җыю тәртибе турында сөйли башласаң, күпләр: «Нинди акча җыю турында сөйлисең?! Хезмәт хакыбыз болай да түбән», – дип зарланырга тотына. Бу – аклану гына. Теләгән кеше аз гына хезмәт хакыннан да запас җыярга җай таба. Пенсионерларны гына алыйк. 30–40 еллык хезмәт стажы булган кешеләрнең күбесе бүген нибары 8–9 мең сум чамасы пенсия ала. Әмма шуңа да карамастан, алар шушы минималь акчадан да оек эченә акча җыеп барырга җай таба. Теләк кирәк. Моның өчен ай саен билгеле бер күләмдәге акчаны җыеп баруны гадәткә кертергә кирәк. Бу иртүк торып теш чистарту, иртәнге аш ашау кебек гадәти күренешкә әйләнергә тиеш. Акчаны электкеге вакытлардагы кебек мендәр астына салып сакларга димәгән. Хәзер телефоннардагы онлайн банк кушымтасын ай саен кучкән акчаның билгеле бер өлешен автомат рәвештә туплау счетына күчеп бара торган итеп көйләп була. Бер хезмәт хакыннан икенчесенә кадәр очны очка ялгап яшәмәс өчен, өстәмә керем чыганаклары да табарга киңәш итәр идем. Бүген аның әллә нинди юллары бар. Йортыгызда иске кием-салым, тотылмаган савыт-саба, кирәкмәгән башка кирәк-яраклар булса, аларны махсус сайтлар аша сатарга да мөмкин. Сезнең өчен иске булып тыелган товарлар кем өчендер менә дигән коткару чарасы була ала бит.

:: Елның-елында халык декабрьдә хезмәт хакы, премияләр ала да гыйнвар уртасына кадәр акчасыз утыра. Яңа ел ялларыннан чыкканда кесәдә җилләр уйнамасын өчен, акчаны ничек тотарга кирәк?

– Бәйрәм дип башны югалтырга ярамый. Айлык керем-чыгымнарны һәрчак контрольдә тотарга кирәк. Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан да табын әзерләүгә, күңел ачу чараларына, бүләкләргә күпме акча тотарга җыенуыгызны планлаштырып, исемлек төзегез. Анда яллардан соң көндәлек тормышта тотарга да акча калган булсын. Бәйрәмдә тотылачак чыгымнарның һәркайсына конкрет сумма билгеләгез. Әйтик, 5 мең сумга Яңа елга якыннарыгызга бүләкләр алырга уйладыгыз, ди. Ни генә булса да, шушы чиктән чыгарга тырышмагыз. Бу суммага сыешмасагыз, исемлекне тагын бер кат карап чыгып, төзәтмәләр кертегез. Бүләкнең арзанрагын, йә булмаса башка төрлесен дә сайларга була бит.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Яңа елда буш акча янчыгы белән калмас өчен кагыйдәләр

✷Кибеттән азык-төлек җыяр алдыннан иң элек меню төзегез. Өстәлегездә нинди ризык, аны әзерләү өчен күпме күләмдә, нәрсә кирәк буласын граммына кадәр төгәл ачыклагыз. Исемлек итеп языгыз. Юкса, азык-төлекне артыгы белән яки бөтенләй кирәк булмаган әйберләр дә җыеп кайтуыгыз бар. Бозылмый торган, консервланган банкалы продуктларны алдан алып куегыз.

✷Кибеткә хуҗабикә үзе барса яхшырак. Бу эшне иргегезгә тапшырмавыгыз хәерле. Яшерен-батырын түгел, ир-ат азык-төлек алганда вакланып, бәя чагыштырып сайланып тормый, нәрсә туры килсә, шуны ала.

✷Яңа елны якыннар, дуслар белән зур компаниядә каршыларга яратабыз. Ләкин өегезгә кунаклар җыясы икән, алдан ук бер шартны сөйләшеп куегыз. Сез табын әзерләргә продукция аласы да квитанция буенча шуны кешеләр санына бүләсез. Икенче төрле дә эшләргә мөмкин: һәр гаилә үзе белән берәр төрле ризык алып килә дә табын шулай корыла.

✷Бүләкләрне Яңа елга кадәр 1–2 ай алдан алып куярга кирәк. Белеп торабыз: теләсә кайсы бәйрәм алдыннан бөтен әйбер кыйммәтләнә. Кул эшенә оста кешеләр бүләкне үз куллары белән дә әзерли ала. Андый бүләк кадерлерәк тә була, шактый акча да янга кала. Аннары Яңа елда бүләк бирешү мәҗбүри түгел бит. Өлкәннәр, үзара сөйләшеп, бөтенләй бүләк бирешмибез дип тә килешә ала. Ләкин балаларны сөенечтән мәхрүм итә күрмәгез! Балачакта Яңа ел да, анда бирелгән бүләкләр дә аеруча истә кала бит.

ЯҢА ЕЛДА КҮПМЕ АКЧА ТОТАРГА ҖЫЕНАСЫЗ?

Зәйнәб ФӘРХЕТДИНОВА, Татарстанның халык артисты:

– Яңа елда күпме акча тоту – һәркемнең үз эше. Ничек уздырасы килсә, шулай уздыра. Зурдан кубып табын әзерләмәсәң дә ярый. Иң мөһиме – гаилә белән бергә булу. Мин дә, Зөфәр дә шул фикердә. Бәйрәм табынын нәрсә бар, шуңардан әзерлибез, Аллаһка шөкер. Эчемлекләр алмыйбыз.

Гөлназ ГӘРӘЕВА, укытучы (Мамадыш районының Көек Ерыкса авылы):

– Яңа ел бәйрәме дип зурдан кубып әзерләнгән юк. Соңгы елларда аны өйдә генә каршылыйбыз. Кешегә бармаганга 20 елдан артык. Балалар үз гаиләләре белән каршы ала, кайта алмыйлар. Дөрес, керүче-чыгучы булса дигән уй, Яңа ел мул башлансын дигән теләк белән табын әзерлим үзе. Пилмән, бәлеш, салатлар – барысы да әзерләнә. Авылда булгач, үз продуктларыбызны исәпләмәгәндә, табын өчен, күп дигәндә, 3–4 мең сум акча тотыладыр. Яңа елга бүләк бирешәбез дип тә зурдан купкан юк. Бүләк – матур теләк. Гаиләдә безнең беребез өчен икенчебез булу, сәламәт булу – бүләк! Сатып алына торган бүләкне оныкларыбызга гына бирәбез. Яңа елга дип кредит алучыларны, гомумән, аңламыйм. Аның бик кирәк булганда алганнарын да түләргә кирәк әле.

ИЛШАТ ФӘРДИЕВ:
«ҺӘР КЕШЕНЕ КАЙГЫРТЫП, ҺӘР КЕШЕГӘ ЭНЕРГИЯ БИРЕП ЭШЛИБЕЗ!»

2022 ел Татарстанда Цифралаштыру елы дип игълан ителде. Цифралы, ягъни мәгълүматны анализлауга нигезләнгән ай-ти технологияләр бүген икътисадның барлык тармакларына да үтеп керде. Энергетика бу җәһәттән искәрмә түгел.
«Сетевая компания» җәмгыятендә ай-ти технологияләрне үстерү буенча эшләр инде 2000 нче еллар башыннан бирле дәвам итә. Алар электр челтәренә яңа төр җиһазлар урнаштыруда да, компания ихтыяҗлары өчен программа продуктларын үстерүдә дә чагылыш таба килде. Компаниянең быелгы уңышлары һәм киләчәккә планнары турында аның генераль директоры Илшат ФӘРДИЕВ белән сөйләштек.

:: Илшат Шәехович, сөйләшүне котлаудан башлыйм әле. Быел сезнең компания сакчыл җитештерү буенча бронза медаль алды. Япония белгечләреннән мондый югары бәя алу – зур казаныш. Моңа ничек ирештегез?
– Безнең предприятиедә 2014 елдан бирле «Сакчыл җитештерү» системасы эшләп килә. Ул «Тойота инжиниринг» компаниясе тәҗрибәсенә нигезләнә. «Сакчыл җитештерү» – чыгымнарны киметеп, ресурсларны тагы да нәтиҗәлерәк файдалану, эш процессларын камилләштерүне үз эченә алган менеджмент системасы. «Сетевая компания»дә бу процессларга һәр хезмәткәр җәлеп ителгән. Һәркем үзенең тәкъдимен кайдзен рәвешендә формалаштырып, ул хупланган очракта моның өчен әле премия дә ала. 2021 елның 10 ае буенча, безнең хезмәткәрләр керткән тәкъдимнәр барлыгы 125 миллион сум акчаны янга калдырыр дип көтәбез. Бу – шактый зур экономия.

«Тойота» җитәкчелеге «сакчыл җитештерү» менеджментын өлге итеп алган оешмаларда аудит уздырып, аларга алтын, көмеш я булмаса бронза дәрәҗәсен бирә. 2012 һәм 2018 елларда мондый аудит-тикшерүләр бездә дә узды. Дөрес, беренче нәтиҗәләр сөендерерлек булмады. Ләкин тырышкан табар, ташка кадак кагар дигәндәй, әлеге халыкара стандартлар буенча эзлекле эшне ташламадык һәм бүген бу карар үзен тулысынча аклады.

Быел Алабуга электр челтәрләрендә «Тойота инжиниринг» системасы критерийлары буенча кабат «Энергия» җитештерү системасының нәтиҗәләрелеге бәяләнде. Аудиторлар корпоратив күрсәткечләрне яхшырткан эш процессларының зур үзгәрешен ассызыклады. Аудит нәтиҗәләре буенча «Тойота инжиниринг» безгә бронза дәрәҗәсен бирде. Бу – көтелгән һәм зур җиңү.

Компаниянең президенты Тосио Харакири безгә ачыктан-ачык: «Сетевая компания» бүген Татарстан гына түгел, ә Россия күләмендә эшләүче предприятиеләрнең дә борынына чиртте», – дип белдерде. Без, баксаң, дөнья күләмендә «Тойота» бронзасын яулаган беренче электр челтәре компаниясе икән. Монын белән ничек инде горурланмыйсың? Безнең максат хәзер көмеш һәм алтын дәрәҗәләрне яулау.

:: Электр челтәрләре хуҗалыгы илдә совет елларында ук формалашкан. Ул цифралаштыру революциясенә ни дәрәҗәдә әзер?
– Без цифралаштыруны үзмаксат итеп куймыйбыз. Ул – беренче чиратта кулланучылар ихтыяҗын канәгатьләндерергә ярдәм итүче корал. Аның ярдәмендә электр белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшыртырга, утны сүндереп тору күрсәткечен киметергә һәм тергезү вакытын кыскартырга, электр белән тәэмин итүгә икътисади нигезле тариф кертергә мөмкин.

> «Без цифралаштыруны үзмаксат итеп куймыйбыз. Ул – беренче чиратта кулланучылар ихтыяҗын канәгатьләндерергә ярдәм итүче корал. Аның ярдәмендә электр белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшыртырга, утны сүндереп тору күрсәткечен киметергә һәм тергезү вакытын кыскартырга, электр белән тәэмин итүгә икътисади нигезле тариф кертергә мөмкин».

Республиканың электр челтәре комплексын цифралаштыруны планлы рәвештә башкару өчен 2014 елда «Сетевая компания»дә юл картасы эшләнде. Ул подстанция һәм җиһазлар алыштыруны автомат рәвештә эшләргә мөмкинлек бирүче база булдыруны күз уңында тота. Мәсәлән, Казан, Чаллы кебек халкы, социаль әһәмияткә ия объектлары, аз машина сыйдырышлы автомобиль юллары күп булган шәһәрләрдә автомат режимда эшләүче Smart Grid системасы («Акыллы челтәрләр») урнаштырыла. Авария килеп чыга калса, система зыян килгән участокны үзе таба, токның юнәлешен үзгәртә һәм бер минут эчендә кулланучыларга электр энергиясен җибәрә.

Компаниядәге тагын бер мөһим адым – 0,4–10 кВ көчәнештәге челтәрләрне автоматлаштыру. Без һава линияләрендә кыска ялганыш индикаторлары, реклоузерлар һәм башка җайланмалар урнаштыра башладык. Мисал өчен 2016 елда Аксубай районында һава линияләренә беренче кыска ялганыш индикаторлары куеп карарга булдык. Алар безгә чыбык өзелгән я булмаса кыска ялганыш килеп чыккан урыннарны төгәл һәм кыска вакыт эчендә ачыкларга ярдәм итте. Ә моңарчы махсус авария бригадалары мондый урыннарны эзләп вакыт сарыф итә иде. Беренче индикаторлар шактый финансларны экономияләде. Нәтиҗәдә компания аларны массакүләм куллана башлады.

Быел, ниһаять, диспетчерлык хезмәтендә дә зур реформа тәмамланды. Без биредә өч дәрәҗәле системадан ике дәрәҗәлегә күчтек. Сетевая компаниядә хәзер 65 диспетчерлык пунктыннан нибары унысы гына калды.

:: Ягъни цифралаштыру энергетика челтәре белән читтән торып идарә итү мөмкинлеген дә бирә?
– 2019 елда Казан шәһәрендә беренче цифралы «Портовая» подстанциясе ачылды. Бу подстанциядә бакыр кабель урынына мәгълүмат күчерүче оптик кабель кулланылды. Оптик коммутаторлар базасында станциянең бердәм шинасын төзедек. Ул микропроцессорлы җиһазларны кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итә. 2024 елга кадәр тагын 7 цифралы подстанция сафка бастыру өстендә эшлибез.

2019 елда 220 кВ Яшел Үзән подстанциясе төзекләнделәр. Бу объектны төзекләндерү нәтиҗәсендә реле саклаучы автоматика (РЗА) җайланмалары белән читтән торып идарә итүче технология кулланылышка кертелде. Әгәр моңа кадәр трансформаторны ремонтка чыгару эшен персонал 60 минут эчендә башкарса, хәзер бу нибары 3 минут вакытны ала.

:: Дүрт ел элек сез интеллектуаль счетчиклар куя башлаган идегез. Әлеге «акыллы счетчиклар» проекты үзен аклады дип әйтеп буламы инде?
– Интеллектуаль исәпләү системасы – электр энергетикасын цифралы трансформацияләүнең төп элементы. Элек халык күреп күнеккән счетчиклар заманы артта калды. Без урнаштыра торган заманча җиһазлар күпфункцияле, алар автомат рәвештә һәр ярты сәгатьлек һәм тәүлеклек күрсәткечләрне истә калдыра, терки, сервиска тапшыра. Моннан тыш, кулланучыларга уңайлы булсын өчен, мобиль кушымта да булдырылды. Җиһазларны компания хисабына алыштырабыз. Хәзер безнең югалтулар һәм операция чыгымнары кимеде, хезмәт нәтиҗәлелеге артты.

4 ел эчендә республикада барлыгы 270 меңнән артык интеллектуаль счетчик куелды. 2021 елның 9 аенда гына бу счетчиклар энергия югалтуларының дәрәҗәсен 5,84 процентка киметергә ярдәм итте. Әгәр 2017 нче елның шушы вакыты белән чагыштырсак, югалтулар 14 процентка кимегән. Россия территориясендәге энергетика оешмалары өчен бу иң яхшы күрсәткеч санала.

:: 2020 елда «Сетевая компания» үзенең «цифралы күчермә»сен эшләтеп җибәрде. Ул нәрсәдән гыйбарәт һәм аның файдасы нидә?
– Бу безнең «күчермә» түгел, ә Татарстан электр челтәренең виртуаль моделе. 2017 елга кадәр компаниянең электр челтәрләре активлары буенча мәгълүмат һәр системада аерым алып барылды һәм бер типтагы мәгълүматлар безнең үсешне тоткарлады. Шуңа күрә технологик идарәнең бердәм автоматлаштырылган системасын (ягъни цифралы күчермәсен) эшләргә карар кылдык.

Бу проектны мин цифралаштыруның нигезе, фундаменты дияр идем. Цифралы күчермә – республикадагы барлык энергетика объектларын һәм линияләрен үз эченә алган электрон модель. Аңа без 74 мең чакрым озынлыктагы электр линияләрен, баганаларны, 20 мең трансформатор подстанциясен керттек. Бу модельдә һәр объект хакында тулы мәгълүмат, аның техник сыйфатлары, паспорты күрсәтелгән. 2022 елдан без цифралы күчермәнең функцияләрен киңәйтү өстендә эшләячәкбез. Бу беренче чиратта әлеге модельгә электр челтәре объектлары белән идарә итү алымнарын кертү.

Цифралы күчермә электр челтәре хуҗалыгының төзелешен һәм торышын дөрес күрсәтә, теләсә нинди үзгәрешләрне чагылдыра. Диспетчерлар челтәрнең торышын, электр белән тәэмин итүнең сыйфатын онлайн режимда күзәтә ала. Әгәр моңа кадәр алар ут сүнү турындагы хәбәрне халыкның мөрәҗәгате аша белсә, хәзер мәгълүматны виртуаль модель аша ала. Ә киләчәктә мондый мәгълүматлар реаль вакыт режимында автомат рәвештә теркәләчәк.

:: «Сетевая компания» быел тагын бер перспектив юнәлеш – электромобильләрне электр белән туендыру станцияләре төзергә алынган. Илшат Шәехович, димәк, сез бу өлкәдә дә беренчеләрдән булып юл ярып барасыз?

Электр челтәрләрен комплекслы төзекләндерү һәм инновацияле җиһазлар куллану нәтиҗәсендә соңгы җиде елда утны сүндереп тору дәвамлылыгы 72,5 процентка кимеде.

– Әйе, «Сетевая компаниядә» электр белән туендыру (ЭЗС) станцияләрен төзү буенча максатчан программа эшләнде. Аның буенча, бу ел ахырына кадәр без республиканың төрле районнарында 14 шундый станция файдалануга тапшырдык.

«Сетевая компания» урнаштырган станцияләр берьюлы 3 машинага хезмәт күрсәтә ала. Машинага заряд алуның вакыты да кыска – 20дән алып 90 минутка кадәр генә. Электр белән туендыру (ЭЗС) станцияләрендә хезмәт күрсәтүче персонал юк. Бөтен процесслар смартфондагы махсус кушымта аша бара. Әлеге кушымтадан электромобиль хуҗасы башка заряд алу станцияләренең урыннарын да таба алачак. Өстәп, биредә заряд алу процессының барышын карап барырга һәм инде күрсәтелгән хезмәт өчен түләргә дә була.

Электр белән туендыру (ЭЗС) станцияләре программасы компаниябезнең Чистай электр челтәрләре филиалында старт алды. Беренче 3 станцияне автомобиль трафигы җанлы булган урыннарга куярга тырыштык. Бу Алексеевское поселогында Казан – Оренбург юлының 91 нче километры, Базарлы Матак авылында «Әлки район электр челтәрләре» тукталышы һәм Болгар шәһәрендә «Икмәк музее» тукталышы.

Безнең компаниядә заряд инфраструктурасын үстерү буенча оештырылган эшче төркем республика министрлыкларына үз тәкъдимнәрен юллады. Анда без электромобиль хуҗаларына төрле ташламалар булдыру өчен республика законнарына үзгәрешләр кертүне сорыйбыз. Мондый ташламалар – электромобиль хуҗасын транспорт салымыннан азат итү, электромобиль сатып алганда аның бер өлешен дәүләттән субсидияләү, мондый транспорт сатып алучыларга процентсыз я булмаса түбән ставкалы кредит программаларын булдыру һәм парковкаларда бушлай машина куярга рөхсәт итү.

Халыкта иң элек «үзеңнән башла», «башта үзең эшләп күрсәт» дигән гыйбарә бар бит. «Сетевая компания» бу җәһәттән республиканың башка предприятиеләренә үрнәк йөзеннән, үзенең тузган транспортын да электромобильләргә алмаштыру эшен башлый. Болай эшләсәк, безнең исәпләүләр буенча, компаниябезә ай саен ягулык чыгымнарын 17 процентка киметәчәк. Ә бүгенгә шартларда бу котылгысыз.

:: Илшат Шәехович, «Сетевая компания»нең хәйриячелек буенча да зур эшләр башкаруын беләбез. Әңгәмәбезне әнә шундый җылы рухта тәмамласак иде.

– Бүген «Сетевая компания» җәмгыятендә 7395 кеше эшли. Горурланып әйтә алам: бездә эшләүче белгечләр югары квалификацияле. Әлбәттә, энергетика да бүген зур үзгәрешләр алдында. Цифралы трансформация чорында яңа һөнәрләр барлыкка килә, кайберләре югала. Ничек кенә булмасын, интеллектуаль челтәрләрнең үзәгендә барыбер кеше шәхесе кайнаячак. Кадрлар – иң кыйммәтле һәм затлы ресурс булды, бар һәм булачак.

Республика энергетикасына нигез салган, иң авыр елларда фидакарьләрчә эшләгән ветераннарны да онытырга хакыбыз юк. 2015 елда компаниядә «Ышаныч һәм терәк» фонды эшли башлады. Ул хезмәткәрләрнең бер көнлек эш хакыннан җыелган акча хисабына тулылана. Фонд ел әйләнәсендә ветераннарга һәм инвалидларга азык-төлек, көнкүреш кирәк-яраклары белән адреслы ярдәм күрсәтә. Аларны юлламалар буенча «Шатлык» (Зәй районы), «Шәфкать» (Сарман районы), «Камские зори» (Кама Тамагы районы) тернәкләндерү үзәкләрендә, «Балкыш» санаториенда ял иттерәбез. Быел фонд аша ветераннарга һәм инвалидларга күрсәткән ярдәмне акчага күчерсәң, ул 20 млн сумга якынлаша. Ә инде фонд оешкан көннән алып санасаң, 100 млн сумнан артып китә. Пандемия булуга карамастан, быел балаларның җәйге ялы да өзелмәде. Ялта – Зәй лагеренда 4 сменалы ял оештырдык. Анда 674 бала ял итте. Аларның имин ялы өчен лагерьда барлык шартлар тудырылды.

Кыскасы, башкарган эшләребез дә байтак, уңышларыбыз да бар. Тынгысыз булса да, елны матур күрсәткечләр белән тәмамлыйбыз. Безнең компаниянең девизындагыча «Һәр кешене кайгыртып, һәр кешегә энергия биреп эшлибез». Һәм эшләячәкбез дә!

Зөһрә САДЫЙКОВА

14 гыйнвар көнне сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Гөлгенә ШИҺАПОВА** була. Сорауларыгызы, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Армиядән кайткан егетләргә ярдәм бармы?

Армиядән кайтып, эшкә урнашмаган егетләргә өч ай дәвамында социаль яклау бүлегеннән ун мең сум акча түләнә икән, дип ишеттек. Андый ярдәм, чыннан да, бар микән? Эшкә урнашкан очракта, ул түләү сакланамы?

Илһам АБРАМОВ. Арча

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте:

– Мондый ярдәм каралмаган. Эшкә урнаштыру юнәлеше буенча андый ярдәм социаль контракт кысасында гына күрсәтелергә мөмкин. Социаль контракт ул – кешенең авыр тормыш хәлен җиңеләйтү өчен, гражданин белән социаль яклау органы арасындагы төзелә торган килешү. Анда ике якның бер-берсе алдындагы йөкләмәләре билгеләнә. Социаль яклау бүлеге ярдәм күрсәтә, ә гражданин социаль контрактта билгеләнгән шартларны үти.

Хәләл меню төзергә мөмкинме?

Питрәч районының Көек авылында «Алгоритм» техник лицее ачылды. Лицей яхшы, тик ашханәдәге ризык хәләл түгел. Безнең мәктәптә беренче һәм икенче сменаларда мөселман балалары да укый. Хәләл ризык булмагач, алар ашханәдә ашый алмыйлар. Мәктәптә хәләл меню төзеп буламы? Моның өчен безгә, әти-әниләргә, нәрсә эшләргә кирәк?

ГҮЗӘЛ. Питрәч, Көек

Көек мәктәбе директоры Лариса Глибина:

– Юк, бу мөмкин хәл түгел. Сәбәпләрен аңлатуны кирәк дип санамыйм.

Питрәч районының мәгариф һәм фән идарәсе белгече:

– Хәләл меню ясар өчен, барлык учреждениенең хәләлгә күчүе кирәк. Моның өчен лицейда 1500гә якын укучы баланың әти-әнисе белән күрешеп сөйләшергә кирәк. Хәләл менюга күчәргә теләп мөрәҗәгать итүче әти-әниләр саны күп түгел.

Балаларга түләнәме?

Балаларыбызга – 9 һәм 11 яшь. Әтиләре аларга алимент түли иде. Ләкин эшсез калды. Хәзерге вакытта минем хезмәт хакыннан башка бер түләү дә алмыйбыз. Бу очракта балалар нинди дә булса пособиегә өмет итә аламы? Владимир Путин 8–17 яшьлек балаларга ниндидер түләүләр турында әйткән иде. Шул турыда аңлата алмассызмы?

Галия ИБРАҺИМОВА. Кукмара

Республика Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте:

– Бу очракта да авыр тормыш хәлен җиңеләйтү өчен социаль контракт төзергә мөмкин. Гаиләнең кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган очракта, матди ярдәм биреләчәк. Җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган һәм милек белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе 63-ТРЗ законында билгеләнгән дәрәҗәдән түбән булган балалы гаиләләргә 16 яшькә кадәр (гомуми белем бирү учреждениесе укучысына – укуын тәмамлаганчы, ләкин 18 яшькә җиткәнче) айлык пособие түләнә.

Россия Пенсия фонды Татарстан буенча бүлегенең матбугат хезмәте:

– Түләүләр әтисе яки әнисе тәрбиясендә генә булган, яки суд карары белән алимент түләнергә тиеш булып та, ниндидер сәбәпләр белән аны алмаучы, яки алимент алып та, мохтаҗ булган гаиләдә тәрбияләнүче 8–16 яшьлек балаларга гына каралган. Моннан тыш, әлеге акчаны алыр өчен, гаиләнең кереме бер гаилә әгъзасына яшәү минимумыннан (9955 сум) кимрәк булу шарт. Шулай ук мөрәҗәгать итүченең милке булу-булмавы да исәпкә алына. Шушы шартларга туры килгән очракта, социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шулай ук «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша да гариза тапшырып була. Әгәр ир белән хатын рәсми төстә аерылышмаган, ләкин ире алимент түләргә тиеш булган очракта, балалар әлеге пособиегә өметләнә алмый.

Тонзиллитны ничек дәваларга?

Дустым озак еллар хроник тонзиллит белән авырый. Күп табибларга да күренде, ләкин әлегә файдасын күрми. Ничек дәваланырга икән? Нинди анализлар биреп карарга мөмкин? Бәлки сезнең газета аша берәр табиб яхшы киңәш бирер.

Камил ЗӘКИЕВ. Балтач районы

Шәрифҗан Мәүләвиев, терапевт:

– Авыруны күрми торып, читтән киңәш бирү уңайсыз да, бик үк дөрес тә булмас, билгеле. Төпле киңәш бирер өчен, беренче чиратта, табиб авыруның миндальсыман бизләренең торышын билгеләргә тиеш. Әгәр еш авырый һәм авырлык белән кичерә икән, бизләрне алдыру хәерле, чөнки авыру катлаулана гына. Табиб гадәттә тамактан мазок ала һәм аның нәтиҗәсе буенча туры килә торган антибиотик билгели. Моннан тыш, лейкоформула белән гомуми кан анализы бирергә кирәк. Өй шартларында исә тозлы-содалы су катнашмасының да файдасын күрәләр. Тамакны аның белән көнгә 5-6 тапкыр чайкау кирәк.

Китапханәчеләргә өстәмә акча булырмы?

Россия Президентының «Май указы» буенча китапханәчеләргә өстәмә акча түли башлаганнар иде. Ике ай түләделәр дә бетте. Ул шулай берничә ай гына түләнергә тиеш булдымы икән?

ГӨЛИНӘ. Яшел Үзән районы

Татарстан Мәдәният министрлыгының матбугат хезмәте:

– Әлеге түләү бер генә тапкыр бирелде. Дәүләт учреждениеләре өчен хезмәткә түләү системасы Министрлар Кабинетының 413 карары белән билгеләнгән. Шундый ук нормалар муниципаль актларда да күрсәтелгән. Аларда кызыксындыру характерындагы түләүләр турында сүз бара. Шул ук вакытта республикада уртача хезмәт хакы даими контрольдә тора. Шул исәптән, мәдәният тармагындагы хезмәт хаклары да министрның шәхси контроле астында. Россия Президенты указлары һичшиксез үтәлә.

Беткән авылга һәйкәл куелырмы?

Мин Актаныш районының Мәчти авылыннан булам. Ул 1974–1976 еллардан бирле юк инде. Калган 30 хуҗалык Иске Байсар авылына күчерелде. Бервакыт Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Юкка чыкан авыллар урынына һәйкәлләр куярга кирәк», – дип әйткән иде. Әгәр мондый истәлек урнаштырылса, авылыбызда исемнәре ташка уелырга лаек булган бик күп хөрмәтле шәхесләребез бар. Чыннан да, юкка чыккан авыл урынына һәйкәл куярга буламы икән? Бу эшне ничек һәм кайдан башларга?

Далия ХАННАНОВА. Актаныш

Актаныш районы башлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү буенча ярдәмчесе Руслан Усманов:

– Актаныш районында исемнәре мәңгелеккә картадан җуелган авыллар шактый. Аларның һәрберсендә диярлек шушы җирлектән чыккан кешеләр ярдәме белән исеме, тарихы, күренекле шәхесләре язылган һәйкәлләр, стелалар куелган.

Мәчти авылы – зур тарихи һәм археологик әһәмияткә ия җирлек. Авыл тарихына багышланган бик күп китаплар дөнья күрде. Әле бүген дә биредә Фәннәр академиясе белән берлектә өйрәнү эшләре дәвам итә, мәгълүмат туплана һәм биредә, авылның тарихи мирасын үсеп килгән буынга җиткерер өчен, истәлек билгесе урнаштыруны, әлбәттә, кирәк дип саныйбыз. Якын киләчәктә, тарихи эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, Мәчти авылының исемен мәңгеләштергән һәйкәл куелачак.

Дөрес бәя алдылармы?

Декабрьнең беренче көннәрендә хат ташучыбыз кергән иде. 465 сум түләп, «Ватаным Татарстан» газетасының җомга санына язылдык. Ләкин газета артында ул сумманы сызып, 404 сум дип язгансыз. Ник бездән шундый бәя алды икән хат ташучыбыз?

Илсур РӘХИМҖАНОВ. Әтнә районы

Редакциядән:

– Илсур абый, хат ташучы Сезне газетага 6 декабрьгә кадәр яздырган булса кирәк, чөнки ташламалы бәя белән шул вакыттан соң гына язылырга мөмкин иде. Әлеге атналык ун көн дәвам итте. 6 декабрьгә кадәр һәм хәзерге вакытта газетаның җомга санына язылу бәясе – 465 сум.

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

27 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хаерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ...» 12+
10.00, 23.30 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Металлург» (Мг). Прямая трансляция 6+
22.00 «Реальная экономика» 12+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.25 «Соотечественники» 12+
00.50 «Здоровая семья: мама, папа, я». Мударисовы, ч.1 6+
01.05 «Если хочешь быть здоровым» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
08.40 «Башваткыч» 6+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.30, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча әйрәнәбез» 6+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
17.00, 18.20, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.00 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Металлург» (Магнитогорск). Трансляция Казаннан 6+
23.05 «Башваткыч» 12+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 6+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Эй, язмыш, язмыш...» 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости
12.15, 17.00 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00, 03.45 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.40 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Даниил Страхов. «ЗНАХАРЬ». Новые серии (S) 16+
23.30 «Познер» 16+
00.35 Хоккей. Молодежный чемпионат мира 2022. Сборная России – сборная Швейцарии. Прямой эфир из Канады (S)

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Премьера. Алёна Спивак, Леонид Кулагин, Дмитрий Блохин, Валерий Сторожик. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Премьера. Фёдор Добронравов, Татьяна Кравченко, Людмила Артемьева, Александр Феклистов, Анна Кошмал, Николай Добрынин, Виктор Добронравов. «СВАТЫ. СЕДЬМОЙ СЕЗОН» 12+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. США – Словакия. Прямая трансляция из Канады
08.00, 08.55, 12.30, 15.35, 18.25, 22.40 Новости
08.05, 17.30, 23.40 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.20 «Проспект обороны» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 Сильвестр Сталлоне. «УБРАТЬ КАРТЕРА» 16+
15.00, 15.40 Николас Кейдж в фильме» ОРУЖЕЙНЫЙ БАРОН» 16+
18.30 Церемония вручения наград «Globe Soccer 2021» Прямая трансляция из ОАЭ.
20.00 «Громко». Прямой эфир
21.00, 22.45 «СОЛДАТ ДЖЕЙН» 16+
00.20 «МИСТЕР ОЛИМПИЯ» 12+
02.30 «Всё о главном» 12+
03.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Германия – Чехия. Прямая трансляция из Канады

НТВ

05.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Денис Шведов, Сергей Маковецкий. «ВОЛК» (S) 16+
23.40 Игорь Новоселов. «ОТПУСК ЗА ПЕРИОД СЛУЖБЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Потусторонние тумаки» 16+
07.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.10 «Давай разведёмся!» 16+
09.15 «Тест на отцовство» 16+
11.30 «Понять. Простить» 16+
12.40 «Порча». «Мачеха» 16+
13.10 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.20 «Про здоровье» 16+
14.35 «ОПАСНЫЕ СВЯЗИ» 16+
19.00 «ТЫ МОЙ» 16+
23.20 «ПРОВОДНИЦА» 16+
03.10 «Реальная мистика» 16+
04.05 «Верну любимого» 16+
04.35 «Порча» 16+
05.00 «Знахарка» 16+
05.25 «Понять. Простить» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «Война в корее» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.20, 01.35 «ДЕЛО РУМЯНЦЕВА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Сделано в СССР» 12+
13.40, 14.05 «ЯЛТА-45» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва экономик». Док. сериал. «10 лет, которые потрясли мир» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №85» 16+
20.25 «Загадки века». Док. сериал. «Агент «Хола» – «Красная бабушка». Премьера! 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.35 «КАМЕНСКАЯ» 16+
03.15 «Освобождение». Док. сериал. 16+
03.40 «ЯЛТА-45» 16+

28 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хаерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «БИЧАРАКАЙ» 12+
10.00, 23.00 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
17.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова. 1 нче булек 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы « 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Фешин. Монолог художника 12+
00.45 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
01.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.15 «Память сердца» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40, 20.30, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
17.00, 19.10, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости
12.15, 17.00 «Время покажет» 16+
15.15, 02.50, 03.05 «Давай поженимся!» 16+
16.00, 03.35 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.40 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «Знахарь». Новые серии (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 К 80-летию Сергея Шакурова. «Влюбляться надо чаще» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Премьера. Алёна Спивак, Леонид Кулагин, Дмитрий Блохин и Валерий Сторожик в телесериале «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 Русская серия. Премьера. Фёдор Добронравов, Татьяна Кравченко, Людмила Артемьева, Александр Феклистов, Анна Кошмал, Николай Добрынин, Виктор Добронравов. «СВАТЫ. СЕДЬМОЙ СЕЗОН» 12+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Швеция – Словакия. Прямая трансляция из Канады
08.00, 08.55, 12.30, 15.35, 18.25, 22.40 Новости
08.05, 14.55, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Специальный репортаж 12+
09.20 «ПРОСПЕКТ ОБОРОНЫ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Все на регби!
13.10, 15.40 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Спринт. Прямая трансляция из Швейцарии
17.40, 18.30 Сильвестр Сталлоне. «УБРАТЬ КАРТЕРА» 16+
19.50 Биатлон. «Рождественская гонка звёзд». Масс-старт. Прямая трансляция из Германии
21.05 Биатлон. «Рождественская гонка звёзд». Гонка преследования. Прямая трансляция из Германии
22.45 «ВЫШИБАЛА» 16+
00.30 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Швейцария – США. Прямая трансляция из Канады

НТВ

04.55 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ВОЛК» (S) 16+
23.40 Премьера. Олег Чернов. «ГРАНИТ» (S) 18+
01.40 Евгений Дятлов, Михаил Трухин. «НАСТАВНИК» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Битва приворотов» 16+
07.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.35 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Роковое время» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «ТЫ МОЙ» 16+
19.00 «РАДИ ЖИЗНИ» 16+
23.15 «ПРОВОДНИЦА» 16+
03.05 «Реальная мистика» 16+
04.00 «Верну любимого» 16+
04.30 «Порча» 16+
04.55 «Знахарка» 16+
05.20 «Понять. Простить» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ЯЛТА-45» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25 «ВЛЮБЛЕН ПО СОБСТВЕННОМУ ЖЕЛАНИЮ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «НАСТОЯЩИЕ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва экономик». Док. сериал. «На краю пропасти». Премьера! 16+
19.40 «Легенды армии». Николай Челноков. Премьера! 12+
20.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.35 «КАМЕНСКАЯ». «СМЕРТЬ И НЕМНОГО ЛЮБВИ» 16+
01.35 «ТИХАЯ ЗАСТАВА» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Актив иҗтимагый эшчәнлеге, республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Айзатуллин** Мансур Нәҗип улы; мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Е.Н.Королёв исемендәге Түбән Кама политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе методисты **Галәветдинова** Гүзәлия Риза кызы; республикада сатыла торган алкоголь продукциясенең сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итүгә һәм кулланучылар базарында хокук бозуларны кисәтүгә зур өлеш кертүе өчен Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе административ һәм суд практикасы бүлеге башлыгы урынбасары **Җамалетдинов** Ильяс Илдус улы; күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Казан биохимия һәм биофизика институты өлкән фәнни хезмәткәре, наносистемалар биофизика химиясе лабораториясе мөдире **Зуев** Юрий Федорович; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Камалиев** Фәргать Талверт улы; физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Факел» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең йөзү буенча тренеры **Кузнецов** Сергей Васильевич; Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Юность» универсаль спорт залы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Мостафин** Радик Илгиз улы; «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Р.Кәлимуллин исемендәге Борындык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Юнысов** Хәмзә Мөхәммәтбәшир улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Мөсәгыйтов** Фәнис Наил улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Самонина** Светлана Петровна; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең иҗтимагый оешмалар белән эшчәнлек бүлеге башлыгы **Шакиров** Илнур Габделнасыйр улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге башлыгы **Вальков** Николай Николаевич; Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе **Сабиржанова** Дамирә Равил кызы; «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре урынбасары – юридик идарә башлыгы **Столяров** Сергей Николаевич; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге башлыгы **Фетилина** Валентина Ивановна; Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече **Йосыпова** Рәсимә Фатыйх кызы; җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттырудагы казанышлары, муниципаль районның финанс-икътисади үсешенә кертүләре өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе **Зыятдинова** Ләйсән Шәймәгъсүм кызы; «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенең фаразлау һәм икътисади анализ бүлеге башлыгы **Ситдыйкова** Рәмзия Галимҗан кызы; күпьеллык намуслы хезмәте, гражданлык хәле актларын теркәү системасын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең мәгълүмат эшкәртү, саклау һәм бирү (архив) бүлеге баш белгече **Кәбирова** Гөлшат Марат кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлекләре өчен хезмәт ветераннары: **Баһаутдинова** Наилә Тәхвәт кызы; **Бударин** Виктор Николаевич; **Галиев** Илфат Габдрахман улы; **Гусева** Татьяна Михайловна; **Закиров** Илгизәр Галиәхмәт улы; **Исаев** Георгий Анатольевич; **Ошина** Эльмира Шәйхетдин кызы; **Петров** Геннадий Сергеевич; **Сыромолотов** Борис Хәнәфи улы; **Устин** Владимир Иванович; **Фәхретдинова** Галина Ивановна; **Хохлов** Виталий Ильич; **Шәрипов** Закир Шәрип улы; **Галимов** Фиркать Гариф улы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башлыгы урынбасары **Закирҗанов** Расих Рәхимҗан улы; Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен «ТУРАН АРТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хәйбрахманова** Суфия Камай кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК САТАМ.

Йомырка салучы тавыклар өчен катнаш азык

Адрес: Казан, Техническая урамы, 15.

Телефон: 8 (927) 049-97-06

Ярдәм кирәк кешегә сиделка хезмәте күрсәтәбез. «Помощник» социаль хезмәте

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН: 8 (929) 962-76-44

МАССАЖ ИММУНИТЕТНЫ НЫГЫТА

Бер сәгатьлек массаж сигез сәгатьлек йокыны алыштыра! Күз алдына китерәсезме?! Моннан тыш дистәләрчә чирдән дәва булуы белән дә игътибарга лаек ул. Бүген даими рәвештә стресс, киеренкелек шартларында яшәгән кешелек аңа аеруча мохтаҗ. Массаж ясауның серләрен, аның кеше организмына нинди файда китерүен ачыклау максатыннан, Казандагы «Рельсы-рельсы, шпалы-шпалы» спа-студиясендә кунакта булып кайттык. Тәҗрибәле массаж ясау остасы Эльвира БИЛАЛОВА массаж турында сорауларыбызга ачыклык кертте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Сезнең студиядә массажның нинди төрләрен ясатырга мөмкин? Алар бербереннән нәрсәсе белән аерыла?

– Безнең салонда тәнне яздыра, арыганлыкны бетерә торган, лимфодренаж, целлюлитка каршы массаж* ясатырга мөмкин. Берничә ысулны бергә кушып та ясатып була. Бездә шулай ук биткә дә массаж ясыйлар. Яздыручы массаж мускулларга ныграк басым ясау хисабына, кысылган, буылып торган урыннарны яздырып җибәрүне күздә тота. Арыганлыкны бетерә торган массаж күпкә йомшаграк. Лимфодренаж ысулы организмнан артык сыеклыкны чыгара, иммунитетны ныгыта. Целлюлитка каршы массаж тәндәге кытыршы урыннарны тигезли, шомарта, гәүдәне зифаландыра. Биткә ясаганда, массажның япон техникасын, хиропластика ысулын кулланабыз. Беренчесе йөздәге авырткан нокталарны юкка чыгарып, киеренкелекне бетерсә, соңгысы бит тиресен тарттыра. Бездә биткә скульптур-буккаль массаж да ясатырга мөмкин. Анда биттәге бөтен мускуллар да эшкә җигелә. Нәтиҗәсе беренче процедурадан соң ук күренә – бит тиресе тартыла, иң тирән җыерчыклар, икенче ияк юкка чыга. Биткә ясала торган башка төрләр белән чагыштырганда, скульптур-буккаль массаж ясаганда шактый авырттыра. Әмма өченче тапкыр ясаганда авырту акрынлап кими башлый.

:: Балаларга да массаж ясыйсызмы?

– Әйе, җиде яше тулган балаларга да массаж ясыйбыз. Әмма иң элек ата-анадан язмача рөхсәт алабыз.

:: Сезнең студиягә килеп керү белән бөтенләй башка дөньяга эләккән кебек буласың. Талгын музыка яңгырый, монда диварлар ук тынычландыра кебек.

– Әйе, шәһәр ыгы-зыгысында кайнап, ашыгып килеп кергән кеше бездә үзеннән-үзе тынычланып кала. Игътибар итсәнсездер: бездә эшләүчеләр дә салмак кына, тавыш күтәрми генә сөйләшә. Болар бар да студиядә уңайлы, җылы мохит тудыра. Нәтиҗәдә бездә, тәнең белән генә түгел, күңелең белән дә рәхәтләнеп ял итәргә мөмкин. Өстәвенә безнең спа-студиядә андый рәхәт мизгелләрне арттыра торган махсус процедуралар да ясала. Бездә гүзәл затларның күңеленә хуш килә торган тукыма маскалар, тәнгә сөртелүче күп төрле эфир майлары сайларга була, төрү, тиренең картайган күзәнәкләрен ышкып төшерү кебек спа алымнар да кулланыла.

Кемнәргә массаж ясату катгый тыелган?

1 Билгеле бер урында гына авырту сизелгән, тәненә тап чыккан, кан басымы уйнаудан интеккән кешеләргә массаж ясатканда сак булырга кирәк.

2 Аякта кан тамыры киңәю диагнозы куелган кешеләргә массаж ясату киңәш ителми.

3 Яман шеш вакытында массажны ремиссия вакытында гына ясату хәерле. Анда да билгеле бер ысулларны гына кулланырга ярый.

4 Йөклелекнең икенче-өченче триместрында массаж ясатырга мөмкин. Сынган, җәрәхәтләнгән урыннары булган кешеләргә дә бу эшне башка вакытка күчереп торырга туры киләчәк.

5 Массажны салкын тигән вакытта да ясатырга ярамый. Юкса массаждан соң инфекция бөтен организмга таралырга мөмкин.

«Рельсы-рельсы, шпалы-шпалы» спа-студияләр челтәренә моннан өч ел элек нигез салынган. Бүген алар илнең 35 шәһәрендә яшәүчеләргә хезмәт күрсәтә. Күптән түгел, шул ук исемдәге спа-студия Казанда да ачылды. Салон хуҗалары Серия һәм Константин Быковлар **(рәсемдә. – Д.Г.)** *сүзләренә караганда, якын арада башкалада шундый тагын өч студия ачылачак. «Без массаж ясаучы осталарның «иң-иң»нәрен генә җыйдык. 60 кандидат арасыннан алтысын гына сайлап алдык. Ачылыш алдыннан аларны өстәмә рәвештә укыттык. Шунысы да бар: бездә бары тик хатын-кызлар гына массаж ясый», – ди Константин Быков.*

:: Массаж ясатыр алдыннан анализлар тапшырырга кирәкме?

– Юк, массаж ясатыр алдыннан ниндидер анализлар тапшырырга кирәкми. Ләкин табиб юлламасы булса, үзегез белән аны да алып килсәгез яхшы.

:: Организм үзенә массаж кирәклеген нинди билгеләр буенча сиздерә?

– Аның ярдәм сорап ялваруын котәргә кирәкми. Организм сәламәт булсын өчен, атнага ике тапкыр массаж ясатып тору хәерле. Болай эшләгәндә арка авыртулары да борчымаячак, тәндә кысылган, сызлаган урыннар да булмаячак. Массаж ясаткан кешенең иммунитеты да ныгый. Кемгәдер ярты елга бер мәртәбә ун көн массаж ясатып алу да җитәргә мөмкин.

:: Иммунитетны да ныгыта, дидегез. Ул нәрсә хисабына ныгый?

– Массаж вакытында кан әйләнеше яхшыра, лимфа чистара. Шуның хисабына иммунитет та ныгый.

:: Массаж тагын нинди авырулардан коткара?

– Массаж, иң беренче чиратта, остеохондроздан интеккән кешеләргә ярдәм итә. Нәтиҗәсе булсын өчен аны, ким дигәндә, ун тапкыр ясатырга кирәк. Кайвакыт кешегә башны бору кебек гади генә хәрәкәтләрне ясау да кыен була башлый. Андый вакытта массажның ярдәме бик зур. Даими рәвештә хәлсезлек сизгән, депрессия, стресстан интеккән кешегә дә массаж булышачак. Процедурадан соң псориазлы кешеләрнең дә хәле яхшыра. Форсаттан файдаланып, әлеге авырудан интеккән кешеләргә мөрәҗәгать итәсем килә. Массажга йөрүдән курыкмагыз, оялмагыз! Тәндәге кутырлардан уңайсызлануга караганда, алардан котылу күпкә мөһимрәк.

:: Соңгы арада массажер кәнәфиләр дә бик популяр. Алар зур сәүдә үзәкләрендә еш очрый. Акчаңны саласың да, биш минут дигәндә бөтен гәүдәңне яздыра. Мондый кәнәфиләрнең организмга файдасы бармы?

– Массаж ясаучы мондый кәнәфиләрнең файдасына караганда зыяны күбрәк. Кешеләрнең организмы гына түгел, тән төзелеше дә, буе да төрле бит. Кәнәфиләр исә билгеле бер стандарт зурлыкта гына чыгарыла. Шуңа күрә алар массаж ясаганда кешегә зыян салырга мөмкин. Әйтик, анда утырган ябык кешенең кирәкмәгән җиренә массаж ясарга, тазарак гәүдәле кешегә тиешенчә ясарга көче җитеп бетмәскә мөмкин. Буе үзенә тиешле биеклектә булмаган кешенең иң куркыныч саналган умыртка баганасы, бөер кебек әгъзаларына бәрергә дә мөмкин ул. Шуңа күрә мондый кәнәфиләрне читләп үтүең хәерле.

:: Массаж серләрен үзлегеннән өйрәнеп, аны өй шартларында ясаучыларга ни диярсез?

– Теләсә кайсы эш кебек үк массаж да, белеп эшләсәң, файда китерә, теләсә ничек тотынсаң, киресенчә, зыян гына салырга мөмкин. Аны ясау өчен кешенең тән төзелешен, организмын биш бармагың кебек белергә кирәк. Мускулларыбыз да катлаулы. Аларга да теләсә ничек кагылырга ярамый. Дөрес нокталарга тимәсәң, кеше аягына баса, кулын күтәрә алмаска мөмкин.

:: Массажның нәтиҗәле булуына нәрсә ашавыбыз да йогынты ясыймы?

– Әлбәттә, ясый. Моның өчен, иң беренче чиратта, дөрес тукланырга кирәк. Бигрәк тә целлюлитка каршы массаж ясатканда нәрсә ашавың мөһим. Клетчаткага (боткалар, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.), аксымга бай ризыкларга өстенлек бирергә кирәк. Кыздырган, майлы, ысланган ризыклардан, гомумән, баш тарту хәерле. Кичке ашыгыз аксым, клетчаткага бай булса, иртәнге ашка аксымга бай ризыклар ашарга кирәк. Көн дәвамында тиешле күләмдә чиста су эчәргә дә онытмагыз. Кеше көненә бер килограмм тән авырлыгына 30 мл су эчәргә тиеш.

*Әлеге хезмәт спа-процедура санала, дәвалау хезмәте күрсәтмибез.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ЯҢА ЕЛНЫ ДӨРЕС КАРШЫЛЫЙК

Яңа елны каршыларга санаулы көннәр калып бара. Киләсе 2022 ел Көнчыгыш календаре буенча Кара (Күк) төстәге су юлбарысы елы булачак. Яңа ел каршылаганда нәрсәләргә игътибар итәргә соң?

КЕМ БЕЛӘН КАРШЫЛАРГА?

Якынлашып килүче елны, кемнәр янәшәсендә үзегезне уңайлы, әйбәт хис итәсез, шулар белән каршыларга кирәк. Ел символы таныш булмаган кешеләрне яратмый һәм аларга бик сак карый.

Юлбарыс елына әйбәт кәеф һәм уңай фикерләр белән аяк атлау хәерле. Вак-төяк аңлашылмаучанлыклардан качыгыз, күңелсез уй-фикерләрне куып таратыгыз. Шулай икән, алдагы унике ай гаять уңышлы, имин узачак.

НӘРСӘ БҮЛӘК ИТӘРГӘ?

Бүләккә килгәндә көндәлек кирәкле әйберләр бирү яхшы булыр. Тәгаен генә нинди бүләк икәнен үзегез хәл итегез. Иң мөһиме, кирәкмәгән, аунап йөри торган бүләк кенә булмасын. Якыннарыгыздан нинди бүләк теләүләре турында да сорарга кыенсынмагыз һәм шул ук вакытта үзегезнең теләк-тәкъдимнәрне дә җиткерергә онытмагыз. Ә инде хезмәттәшләрегезгә уңайлы токкычлы матур бокал яисә офиста эшләүчеләргә компьютер «тычканы» өчен keləмчек, блокнот, каләм ише кирәк-ярак бүләк итүдән дә яхшысы юк.

НӘРСӘ КИЯРГӘ?

Бәйрәм киеменә килгәндә, янып торган җете төсләрдәге, кызыл яки чуар кием сайлый күрмәгез. Иң яхшысы – фирәзә, көмеш, кара, куе яшел, коңгырт, алтынсу, көмешсыман төсләрдәге киемнәргә өстенлек бирү.

Киләсе елда акчаның ишелеп-ишелеп керүен теләүче туташ-ханымнар өчен алтынсу һәм көмешсыман төстәге күлмәктән дә яхшысы юк. Кара күлмәк киеп, муенга алтынсу яки көмешсыман шарф бәйләргә яисә беләзек киеп куярга мөмкин. Ләкин күлмәк ялтыравыклы икән, аяк киеме ялтыравыксыз булырга тиеш. Юлбарыс артыгын кыланганны яратмый. Ә инде ир-атларга күзгә бәрелеп тормаган төсләрдәге классик киемнәр кию киңәш ителә. Шуңа көчле затларга чалбарлы костюм киюдән яхшысы булмас. Тик кара түгел, ә коңгырт яки соргылт төстәгесен сайларга киңәш ителә. Иң мөһиме – Яңа елны джинсыдан каршыламагыз. Ир-атның киеме сөйгәне киеменә туры китереп сайланса, ямь өстенә ямь булачак.

ӨЙНЕ НИЧЕК БИЗӘРГӘ?

Юлбарыс бик чиста-пөхтә җанвар санала. Шуңа күрә Яңа 2022 елны каршылау өчен сайлап алынган бүлмә әйбәтләп җыештырылган булсын. Бәйрәм алдыннан өйне бер тузан бөртеге дә калдырмаслык итеп чистартырга-җыештырырга кирәк. Барлык иске-москыдан котылырга киңәш ителә. Шуны истә тотыгыз: җете төсләр Юлбарысның ачуын чыгара, шуңа күрә табигыйрәк төсләргә өстенлек бирегез. Гел уңышлар гына китереп торсын өчен, ел символы рәвешендәге «копилка» булдырыгыз. Өйне балалар белән бергәләп кәгазьдән ясалган кар бөртекләре белән бизәргә була.

Юлбарыс – бии-и-к зур мәче. Ә мырауҗаннар йомшак диванга җәелеп ятарга гына тора. Шуңа диваннарга йомшак япмалар җәегез, йомшак мендәр-уенчыклар куегыз. Моның ише әйберләр шкаф почмагында тузан җыеп кына ята икән – кичекмәстән тартып чыгарыгыз! Юлбарыс аларны бик яратачак.

Быел чын чыршыга өстенлек бирү яхшы. Аны алтын-көмеш шарлар, шундый ук төстәге укалар белән дә бизәп җибәрсәгезме!.. Чыршы төбенә пыяла вазага шарлар да урнаштырырга мөмкин.

Өстәлгә матур эскәтер җәегез. Көмеш яки алтынсу төстәге тәлинкә, чәнечке-кашыкларыгыз бар икән, табынны шулар белән купшыландырыгыз. Юлбарысның күңелен күрү өчен шулай кирәк.

НИНДИ АШ-СУ ӘЗЕРЛӘРГӘ?

Бәйрәм табынына, әлбәттә, күбрәк ит ризыклары әзерләргә киңәш ителә. Бигрәк тә каз, үрдәк, тавык һәм бәрән итенә өстенлек бирү яхшы булыр.

Юлбарыс бик көчле хуш исләрне ярата. Шуны истә тотып, ризык әзерләгәндә тәмләткечләрне кызганмагыз. Яшелчә тәлинкәсенә күп итеп базилик, кинза, петрушка, укроп, кузаклы фасоль тутырыгыз, кырыена брюссель кәбестәсе куегыз. Алары сәламәтлегегез өчен дә файдага булыр.

Ләкин укроп-петрушка чемченеп кенә бәйрәм каршылап булмый. Телемләп турап куелган ит, күп итеп яшел тәмләткечләр салынган, майонез урынына каймак ише табигый ризыклар белән болгатылган салатларсыз бәйрәм табынын күз алдына да китереп булмый.

Юлбарыс күңеленә хуш килми торган ризыкларның да барлыгын онытмагыз. Әйтик, диңгез продуктларын ул өнәми икән. Шулай да су стихиясе (ел символы – су Юлбарысы бит) табында мондый нигъмәтләргә дә бераз гына урын бирергә рөхсәт итә. Аннан килеп, ярма урынына яшелчәдән гарнир ясау әйбәтрәк булачак. Табынга тозланган, ысланган, пешерелгән яки кыздырылган балык куярга мөмкин.

Эчемлекләргә килгәндә, газлысыннан баш тарту әйбәтрәк. Алар урынына табынга соклар һәм компотлар куегыз.

Табында татлы-баллы ризыклар аз булсын: ел символы татлыны бик үк яратмый икән.

Исеңдә тот!

Яңа елны ничек каршыласаң, шулай үткәрәчәксең, диләр. Шуңа бәйрәмне күңелле һәм кызык итеп үткәрергә тырышыйк! Моның өчен түбәндәгеләрне истә тотыгыз:

- Акча ел буе көтелмәгән урыннардан кереп торсын өчен, ишек төбенә җәелгән келәм яки эскәтер астына тимер акча салып куегыз.
- Табынны мул итегез, шул ук вакытта ризыкны исраф та итмәгез.
- Яңа ел чыршысы бизәмәсәгез, берәр ылыслы агач ботагын бизәп кую да бәйрәм төсмере өстәр.
- Яңа ел каршылыйсы көнне өй җыештырмагыз һәм кер юмагыз.
- Яңа ел табынын әйбәт кәеф белән корырга тырышыгыз, аш-су әзерләгәндә ялгыш кына да бер-берегезгә тупас сүзләр әйтә күрмәгез.
- Узып баручы ел турында, кыенлыкларын искә алып, шөкер, артта калып бара, дип кычкырып сөйләмәгез. Уегызда гына калсын.

Сәхифәне Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

«ЕЛНЫҢ НИНДИ БУЛАЧАГЫН АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ГЕНӘ БЕЛӘ»

«Яңа ел безнең бәйрәм түгел, мөселманга бу көнне бәйрәм итәргә ярамый» дигән фикерләрне ел саен ишетергә туры килә. Бәйрәмдә бүләк бирешү, Кыш бабайга ышануны да гөнаһка санаучылар бар. Шушы «ярый» белән «ярамый»ларның чиге кайда?

Казан шәһәренең «Рамазан» мәчете имамы Солтан хәзрәт МОРАДЫЙМОВ Яңа елга бәйле сорауларга ачыклык кертте.

:: Солтан хәзрәт, Яңа ел җитә башласа, бер сорау тирәсендә гел бәхәсләр куера. Тагын бер кат искәртеп үтегезче: мөселманнарга Яңа ел каршыларга рөхсәт ителәме?

– Әгәр мөселман изгелекләре белән Аллаһы Тәгаләгә якыная, шайтаннан ерагая алса, аның өчен һәрбер көн бәйрәм булып санала. Әгәр без 31 декабрьне Аллаһы Тәгалә риза булган гамәлләр белән, изгелекләр белән мул итсәк, намаз, догалар укып уздырсак, бу бәйрәм дә безнең өчен күркәм көн булыр. Аллаһы Тәгаләнең ачуын китерә торган, гөнаһ гамәлләр белән уздырсак, мөселманнар өчен иң зур бәйрәм саналган җомга көннең дә нуры, бәрәкәте югалырга мөмкин. Бервакыт мәчеткә, киңәш сорап, бер карт килде. Балаларының Яңа елны эчеп, ямьсезләнеп, кәеф-сафа корып үткәрүеннән туеп килгән иде ул. Аларны күпме генә үгетләсә дә, дөрес юлга кертергә тырышса да, нәтиҗәсе булмаган. Аңа: «Гаиләң белән хәләл, күркәм табын артына җыел, вәгазьләр тыңлап, балаларың белән бергә басып намаз укып, 31 декабрьне бер тапкыр булса да шулай үткәрегез әле», – дип киңәш бирдем. Ни гаҗәп: шушы киңәшне тотканнан соң, бу гаилә ел саен бәйрәмне шулай хәләл рәвештә уздыра башлады. Ул ел да бу картның балалары өчен шундый уңышлы булды. Тормышларында дәрәҗә, саулык ягыннан да, бәрәкәт мәсьәләсендә дә бик зур алга китеш булды. Декабрьнең соңгы көне безгә бер еллык гомеребезгә йомгак ясау, үз-үзебезгә хисап кылу вакыты да булырга тиеш. Бу елны ничек уздырдым? Аллаһы Тәгаләгә якынайдыммы? Коръән аятьләре ятладыммы? Кешеләргә ярдәм итә алдыммы икән? Бу көнне әнә шул сорауларга да җавап табу мәслихәт.

:: Мөселман балаларына Чыршы бәйрәмендә катнашу, әйлән-бәйлән уйнау, Кыш бабайдан бүләк алу гөнаһмы?

– Минем тирәмдә Кыш бабай бар дип ышанган бер генә бала да юк. Баланы алдарга кирәкми. Балага Яңа елның Кыш бабай булып киенгән кеше килә, балалар шигырь сөйли, күңел ача торган бәйрәм икәнлеген аңлатырга кирәк. Чыршы бәйрәменә килгәндә, ул хәләл юл белән хәләл бүләкләр тарату рәвешендә оештырылган булса, аның бер начарлыгы да юк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам бер хәдисендә: «Һәрбер гамәл ниятенә карап билгеләнер», – дигән. Шуңа күрә чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйнауның да төп максаты табыну түгел, күңел ачу гына булырга тиеш.

:: Ел уңышлы булсын дип, бәйрәмдә бер-береңә ел символы төшкән сувенир, магнит бүләк итү дөресме?

– Болай эшләүнең мәгънәсе аңлашылмый. Бу һаман да шул нәрсәгәдер табынуны хәтерләтә. Мөселман кешесенә күркәм рәвештә тәсбих, мәчет рәсеме төшерелгән, мөселман бәйрәмнәре язылган календарь бүләк итү хәерлерәк.

pixabay.com

:: Бәйрәм алдыннан мулдан табын әзерлибез. Бу ризыкларның күбесе икенче көнне үк бозылып бетә. Ул көннәрдә ашауда да чама хисе югала. Бәйрәм дип, берьюлы ике гөнаһка батабыз булып чыга түгелме?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам хәдисендә: «Исраф кылу – хәрамгә алып бара торган гамәл», – диелә. Табын әзерләгәндә чама хисе булмауның иң беренче куркынычы әнә шуннан гыйбарәт. Икенчедән, исраф кылгач, ризыкта, малда, мөлкәттә, гаиләңдә бәрәкәт югала башлый. Шуңа күрә Яңа елда гына түгел, нинди генә бәйрәм, мәҗлескә табын әзерләсәгез дә, ризыкны исраф итүдән сакланырга кирәк. Шул ук вакытта ашаганда да чама хисен югалтырга ярамый.

:: Яңа елда теләк теләү – гөнаһмы?

– Моның бер зыяны да юк. Аллаһы Тәгалә: «Миннән сорагыз, мин сезгә җавап кайтарырмын», – дигән. Һәр көнне, һәр мизгелдә дога кылыгыз. Мөселман кешесе гыйбадәтенең асылы – дога, теләк теләү.

:: Яңа ел алдыннан белгечләр елның нинди булачагын фаразлый башлый. Киләсе елга йолдызнамә төзелә. Аларга ышанылыргамы?

– Киләчәкнең нинди булачагын бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Көз көне: «Быел кыш салкын, карсыз була», – дип сөйләгәннәр иде. Менә күреп торасыз. Матур итеп кары да яуды, көннәре дә кышка хас булганча салкын. Шуңа күрә мондый фаразларга, йолдызнамәләргә ышану – гөнаһ. Алар бар да билгеле бер кешенең уйлап чыгарулары белән бәйле. Әгәр алар дөрестән дә киләчәктә ни буласын белсәләр, иң бай кеше булырлар иде. Җир йөзендәге барлык гыйлемнәрнең ачкычы – Аллаһы Тәгаләдә. Аннан өстен булырга ярамый.

ЯКЫНЫҢ ТУРЫНДА ДА УЙЛА

Гыйбрәт

Дәрәҗәле бәйгедә ел саен җиңү яулап килгән, кукуруз үстерүче фермерга: «Сезнең уңыш сере нидә?» – дигән сорау биргәннәр.

– Иң яхшы кукуруз орлыкларын күршеләремә таратам. Уңышымның бөтен сере шунда, – дип шаккатырган фермер.

– Алар да ел саен шушы ук бәйгедә катнаша, сезнең көндәшләрегез булып тора. Шулай булгач, ник иң яхшы орлыкларны аларга өләшәсез?

– Беләсезме, җил минем басудагы серкәләрне – аларныкына, аларныкын минем кукурузларга тарата. Әгәр алар начар орлык чәчсә, минем уңышым да начар булачак дигән сүз. Ә менә утырткан үсемлекләрне кем ничек тәрбияли, анысы инде – икенче мәсьәлә. Бер үк орлыктан төрле уңыш алуыбыз да әнә шуңа бәйле, – дип җавап биргән тәҗрибәле фермер.

Тормышта да шулай. Уңышка ирешергә теләгән кеше янәшәдәгеләре турында да кайгыртырга, аларга уңышка ирешергә булышырга тиеш. Янәшәсендә бар да тәртиптә булган кешенең тормышында да тәртип урнаша. Бу дөньяда бар нәрсә бер-берсенә бәйләнгән.

Йөгез, бер дога!

Саранлыктан саклауны сорап укыла торган дога:

«Аллааһуммә иннии әгүүзү бикә минәл-һәмми вәл-хәзән, вә минәл-гаҗзи вәл-кәсәл, вә минәл-җүбни вәл-бухли, вә минәл-мәә-сәми вәл-мәгърам, вә мин галәбәтид-дәйни вә каһрир-риҗәәл!»

Мәгънәсе: «Йә Аллаһым! Сиңа гына сыенамын! Синнән генә ярдәм сорыймын. Күңел төшенкелегеннән, көчсезлектән һәм куркудан, саранлыктан һәм вакчыллыктан, бурычлы булудан һәм адәмнәрнең золымыннан Сиңа гына сыенамын!»

Авырган кешеләргә 7 киңәш

- Ике рәкәгать хаҗәт намазы укып, Аллаһтан шифа сорарга.
- Табибка мөрәҗәгать итәргә. Даруларны Аллаһтан гына шифа өмет итеп, Аңа ихлас тәвәккәлләп эчәргә.
- «Белеп һәм белми кылган гөнаһларымны ярлыка, бәндәчелек белән кылган хата-кимчелекләремне гафу ит», – дип тәүбә итәргә, мөмкин кадәр ешрак «Әстәгъфируллаһ» (Аллаһтан гафу утенәм) дип әйтергә.
- Авырган җиргә кулны куеп, җиде мәртәбә «Фатиха» сүрәсен укырга яки шул сүрәне җиде мәртәбә суга укып, шул суны эчәргә.
- Бал һәм тмин маен кулланырга.
- Мохтаҗ булган кешегә сәдака бирергә.
- Нәтиҗә нинди булуга карамастан, Аллаһны мактарга, ихлас шөкер итеп: «Нәкъ менә шушы нәтиҗә минем өчен хәерле», – дип уйларга.

(«Матбугат.ру» порталыннан)

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

КЫШ БАБАЙ – НИЯЗ РАХМАН:

«ХӘЗЕР КАР КЫЗЫН СИРӘГРӘК ЧАКЫРАЛАР»

Татарстанның иң популяр Кыш бабаеның елның иң тылсымлы бәйрәме – Яңа ел алдыннан кәефләре ничек? Узып баручы елы ничек үткән? Кечкенә кызының әтисен ак сакаллы килеш күргәне бармы? Бүген без «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка Кыш бабай, танылган радио- һәм тележурналист, алып баручы Нияз РАХМАНны чакырдык.

:: Ни хәл?

– Хәлләр әйбәт, ел ахыры, Яңа ел чаралары башланган вакыт. Чаба, йөгерә, ашыга торган вакыт.

:: 2021 ел ахырына якынлаша. Ниятләрегез, ел буена планлаштырылган эшләрегез тормышка аштымы?

– Бу ел безнең гаилә өчен бик шатлыклы булды. 9 июль көнне кызыбыз Сәминә туды. Ә бала туу – иң зур бәхетләрнең берсе, мөгаен.

:: Танылган журналист, алып баручы булудан тыш, сезнең тагын бер мөһим ролегез бар. Ничек Кыш бабай булырга уйладыгыз?

– Әлеге уй ничектер көтмәгәндә килде. Танышлар Яңа ел алдыннан Кыш бабай эзли иде. Әйдә, үзем киләм, дип тәкъдим иттем. Менә шуннан башланып китте дә инде. Әлеге эшкә моннан алты ел элек тотындым. Мин кечкенә вакытта мәктәптәге Яңа ел бәйрәмендә Кыш бабай булып әни киенә иде. Шуңа да аның чын түгеллеген иртә белдем. Хәтта башка балаларга да бу турыда сөйләп йөргәнем хәтердә.

:: Кыш бабай булып йөргәндә кызыклы хәлләр булгалыймы?

– Кыш бабайны күрүгә, ниндидер үзенчәлекле бәйрәм рухы барлыкка килә. Ә башкаларга бәйрәм рухы бүләк итү – рәхәт нәрсә ул! Сине күреп, балалар гына түгел, олылар, гомумән, һәр кеше елмая. Кызык хәлләр була инде. Мәсәлән, бер тапкыр 28 яшьлек «кызым»ны котладым. Аңа моңа кадәр гомерендә бер тапкыр да Кыш бабай килгәне булмаган. Мине ире чакырды. И кочаклаштык, и елаштык!

:: Ялгышмасам, сез сабыйларның хыялларын да чынга ашырасыз?

– Быел беренче тапкыр хәйрия акциясе оештырдык. Казанда яшәүче биш яшьлек Айзат чыршы турында хыяллана иде. Бу хакта миңа әнисе язды. Бу турыда хәбәр иткәч, чыршы сатучы бер кибет хезмәткәрләре бәйрәм агачын бушка бирде. Ә җырчы Динә Вәлиева аңа планшет бүләк итте. Инстадуслар да булышты. Барлыгы биш мең сум акча җыелды. Ул акчага шулай ук бүләкләр алырга ниятлибез. Кар кызы – Альбина Асылгәрәева белән 25 декабрьдә, бүләкләр алып, янына барабыз.

:: Халык арасында Кыш бабайга мөнәсәбәт үзгәрмәдеме?

– Аңа карата үзгәрмәде, аны бар да ярата, ә соңгы арада Кар кызын чакыручылар кими.

Блиц-сораштыру

– Яңа ел кәефе бүләк итә торган фильмнар?
– «Ирония судьбы, или С лёгким паром», «Один дома», «Любовь и голуби», «Джентельмены удачи», «Карнавальная ночь».
– Тамашачы һәм балалар сезне кайсы сыйфатыгыз өчен күбрәк ярата?
– Балаларны тыңлый, ишетә белү араларны якынайта. Башта Кыш бабайдан курыккан сабыйлар да, аралашып алгач, алдыма менеп утыра.
– Яңа ел алдыннан тылсымга ышанасызмы?
– Әлбәттә! Башкаларга да ышанырга кирәк. Могҗизалар була ул!
– Идеаль Кар кызы нинди булырга тиеш?
– Ул балаларны яратырга тиеш.
– Сезнең өчен бәхет ул – ...
– ... гаилә, балабыз, әти-әни, туганнар, дуслар!

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Җырлар башка булса да, шартлар үзгәрмәде: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санда чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып **Гөлфинә Шакирова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Ришат Төхвәтуллинның «Тиңнәр юк», Раяз Фасыйховның «Өлешемә тигән көмешем» һәм Гөлназ Асаева башкаруындагы «Китә кызлар туган өйдән» җырларын яшергән идек. Бу юлы да катнашучылар шактый булды, барчагызга да рәхмәт!*

Әлеге җырны башкаручы, сине таңнардан эзләдем, ди. Ул сине эзләгән, юраган һәм кемнәндер сораган.

Исләреңә төшеп, төшләреңә кереп, мәхәббәт һәм сагыну хисләрен аңлата торган җыр.

Әлеге җыр кышның аерылгысыз атрибуты турында. Җырчы аларга кат-кат карый һәм аларның бар җиһанны уравын тели.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

29 декабрь | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «БИЧАРАКАЙ» 12+
10.00 «ПРОЩАНИЕ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Калеб» 0+
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Автомобилист» – «Ак барс».Прямая трансляция 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.00 «ВИШЕНКА НА НОВОГОДНЕМ ТОРТЕ» 16+
00.25 «Соотечественники». Резеда Ахиярова. Музыка звезды 12+
00.50 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
01.05 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.20 «Не от мира сего...» 12+
01.35 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
17.00 « Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Автомобилист» (Екатеринбург) – «Ак барс» (Казан) 6+
20.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Хәй Вахитов турында телеочерк 6+
21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 6+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Хәй Вахитов турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00 «Время покажет» 16+
15.15, 03.05 «Давай поженимся!» 16+
16.00, 03.45 «Мужское Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.40 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «Знахарь». Новые серии (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.25 Хоккей. Молодежный чемпионат мира 2022. Сборная России – сборная Словакии. Прямой эфир из Канады (S)
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу. 12+
14.55 Премьера. Алёна Спивак, Леонид Кулагин, Дмитрий Блохин, Валерий Сторожик. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Премьера. Фёдор Добронравов, Татьяна Кравченко, Людмила Артемьева, Александр Феклистов, Анна Кошмал, Николай Добрынин, Виктор Добронравов. «СВАТЫ. СЕДЬМОЙ СЕЗОН» 12+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 Людмила Артемьева, Александр Феклистов, Анна Снаткина, Павел Баршак. «СНЕГУРОЧКА ДЛЯ ВЗРОСЛОГО СЫНА» 12+
04.00 Николай Добрынин. «БАЙКИ МИТЯЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 15.00, 18.25 Новости
06.05, 18.30, 21.20, 23.55 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.20 «ПРОСПЕКТ ОБОРОНЫ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «РАЗБОРКИ В СТИЛЕ КУНГ-ФУ» 16+
15.05 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Женщины. 10 км. Прямая трансляция из Швейцарии
16.45 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Мужчины. 15 км. Прямая трансляция из Швейцарии
18.55 Хоккей. КХЛ. «Локомотив» (Ярославль) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
21.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Олимпиакос» (Греция) – ЦСКА (Россия). Прямая трансляция
00.30 «ВОЗВРАЩЕНИЕ К 36-ТИ СТУПЕНЯМ ШАОЛИНЯ» 16+
02.30 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов». Трансляция из Германии 0+
03.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Канада – Германия. Прямая трансляция из Канады
05.30 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Швеция – США. Прямая трансляция из Канады

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ВОЛК» (S) 16+
23.40 Премьера. «Настоящий разговор» (S) 16+
00.10 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
00.45 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.40 Квартирный вопрос (S) 0+
02.35 «Билет на войну» (S) 12+
03.25 Александр Половцев. «ЗИМНИЙ КРУИЗ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика». «Тайна белого мага» 16+
07.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Чужая судьба» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «РАДИ ЖИЗНИ» 16+
19.00 «ПРОПАСТЬ МЕЖДУ НАМИ» 16+
23.20 «ПРОВОДНИЦА» 16+
03.15 «Реальная мистика» 16+
04.05 «Верну любимого» 16+
04.35 «Порча» 16+
05.00 «Знахарка» 16+
05.25 «Понять. Простить» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «НАСТОЯЩИЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25 «ОДИНОКИМ ПРЕДОСТАВЛЯЕТСЯ ОБЩЕЖИТИЕ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «НАСТОЯЩИЕ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва экономик». Док. сериал. «Тотальная война 1943-1944 гг.» 16+
19.40 «Главный день». «Фильм «Ирония судьбы» и Эльдар Рязанов» 16+
20.25 «Секретные материалы» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.35 «КАМЕНСКАЯ». Телесериал (Россия, 2000). «Чужая маска» 16+
01.35 «МИГУДАЧИ» 12+
02.40 «Артисты фронту». Док. фильм 16+
03.15 «Москва фронту». Док. сериал 16+

30 декабрь | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «БИЧАРАКАЙ» 12+
10.00 «ПРОЩАНИЕ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.30 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
17.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова. 2 нче бүлек 6+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00 «Таяну ноктасы « 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Газпром трансгаз Казань. Итоги года» 12+
21.00 «Иннополис». Спец. репортаж Алины Сулеймановой 6+
23.20 «МАМЫ 3» 12+
00.55 «Видеоспорт» 12+
01.20 «Соотечественники». Альберт Суфианов. Я спасаю людей 12+
01.45 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
02.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
02.15 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
17.00, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» Новогодний выпуск 16+
10.55 Модный приговор. Новогодний выпуск 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости
12.15 «Сегодня вечером» 16+
15.15 «Давай поженимся!» Новогодний выпуск 16+
16.20, 18.40 «Три аккорда». Новогодний выпуск (S) 16+
19.35 «Поле чудес». Новогодний выпуск 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «Голос». Юбилейный сезон. Финал. Прямой эфир (S) 12+
23.30 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.25 Аглая Тарасова, Кирилл Нагиев. «Марафон желаний» (S) 16+
02.00 «Наедине со всеми» 16+
02.45 Модный приговор. Новогодний выпуск 6+
03.35 «Давай поженимся!» Новогодний выпуск 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «Сто к одному». Телеигра. Новогодний выпуск
11.00, 20.00 Вести
11.30 Елена Панова, Виталий Кудрявцев, Анастасия Матвеева, Александр Усердин. «ФЕРМЕРША» 12+
15.25 Александр Демьяненко, Алексей Смирнов, Наталья Селезнёва, Юрий Никулин, Георгий Вицин и Евгений Моргунов. «ОПЕРАЦИЯ «Ы» И ДРУГИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 6+
17.15 «Привет, Андрей! Песня года. 50 лет вместе». Спец. праздничный выпуск 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Фёдор Добронравов, Татьяна Кравченко, Людмила Артемьева, Александр Феклистов, Анна Кошмал, Николай Добрынин, Виктор Добронравов. «СВАТЫ. СЕДЬМОЙ СЕЗОН» 12+
00.25 Премьера. Данила Козловский, Паулина Андреева. «ПОКУПАЙ» 18+
00.40 Нина Усатова, Ксения Лукьянчикова, Павел Трубинер, Иван Оганесян, Алексей Демидов. «УПРАВДОМША» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Швеция – США. Прямая трансляция из Канады
08.00, 08.55, 12.15, 15.35, 18.25, 23.00 Новости
08.05, 20.30, 23.05 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.20, 15.40 «В СОЗВЕЗДИИ СТРЕЛЬЦА» 12+
17.50, 18.30 «СОЛДАТ ДЖЕЙН» 16+
20.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Црвена Звезда» (Сербия) – «Зенит» (Россия). Прямая трансляция
23.55 Футбол. Чемпионат Португалии. «Порту» – «Бенфика». Прямая трансляция
02.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. УНИКС (Россия) – «Анадолу Эфес» (Турция) 0+
03.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Словакия – Швейцария. Прямая трансляция из Канады
05.30 Матч! Парад 16+

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.40 Премьера. «ВОЛК» (S) 16+
01.10 Фильм «СИРОТА КАЗАНСКАЯ» 6+
02.30 «Дачный ответ» (S) 0+
03.20 Федор Лавров, Игорь Хрипунов, Лукерья Ильяшенко. «НОЛЬ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Ветреная» 16+
07.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Беглянка» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «ПРОПАСТЬ МЕЖДУ НАМИ» 16+
19.00 «ВСЁ РАВНО ТЫ БУДЕШЬ МОЙ» 16+
23.30 «ЗОЛУШКА.RU» 16+
01.45 «ЗОЛУШКА» 0+
03.10 «Реальная мистика» 16+
04.05 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «НАСТОЯЩИЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.35 «ЗИГЗАГ УДАЧИ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости. 16+
14.05 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+
18.50 «Битва экономик». Док. сериал. «Последний бой» 16+
19.40 «Легенды науки». Игорь Курчатов 12+
20.25 «Код доступа» 12+
21.15 Новости дня. 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.35 «КАМЕНСКАЯ». «НЕ МЕШАЙТЕ ПАЛАЧУ» 16+
01.40 «ДВЕНАДЦАТАЯ НОЧЬ» 12+
03.05 «СИРОТА КАЗАНСКАЯ» 12+
04.30 «Новый год на войне». Док. фильм 16+

31 декабрь | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

11.20 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 19.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «ПУТЕШЕСТВИЕ К РОЖДЕСТВЕНСКОЙ ЗВЕЗДЕ» 0+
11.00 «Татарлар». Яңа ел чыгарылышы 12+
12.00 «Яңа ел төнендә». Телевизион нәфис фильм 12+
14.00 «Республика Яңа ел чыршысы-2022» 6+
15.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» һәм «Сәйлән» 0+
15.30 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты 6+
17.00 «Мин» 12+
17.30 «Татарлар». Яңа ел чыгарылышы 12+
19.00 «Халкым минем...» Яңа ел чыгарылышы 12+
20.00 «Итоги года» 12+
20.10 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 12+
22.00 «МЕНӘ УЛ БӘХЕТ!» 6+
23.50 Новогоднее обращение Президента Республики Татарстан Р.Н. Минниханова 0+
23.55 Новогоднее обращение Президента Российской Федерации В.В. Путина 0+
00.05 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
04.40 «Гомеремнең бер елы». Ришат Төхвәтуллин 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 16.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Әсхәт Хисмәт турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.00 Республика Яңа ел чыршысы-2022 6+
17.05 «Татарлар». Яңа ел чыгарылышы 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20 «Итоги года» 12+
18.35 «Башваткыч» 6+
19.30 «Җырлыйк әле!» 6+
20.25 «ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ» 12+
22.00 «МЕНӘ УЛ БӘХЕТ!» 6+
23.50 Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Яңа ел котлавы 6+
23.55 Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинның Яңа ел котлавы 6+
00.01 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!»
04.40 «ТУТЫК КЫҢГЫРАУ» 12+

1 КАНАЛ

05.00, 06.10 Фильм «УКРОТИТЕЛЬНИЦА ТИГРОВ» 0+
06.00 Новости
06.45 Фильм «ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС» 12+
08.25 Фильм «ВАРВАРА-КРАСА, ДЛИННАЯ КОСА» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.20 «КАРНАВАЛЬНАЯ НОЧЬ» 0+
11.50 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ» 12+
14.40 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН» 6+
17.30 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 12+
19.25 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 6+
20.45 «Иван Васильевич меняет профессию» 6+
22.15 Новогодняя ночь на Первом. 30 лет спустя (S) 16+
23.55 Новогоднее обращение Президента Российской Федерации В. В. Путина (S)
00.00 Новогодняя ночь на Первом. 30 лет спустя (S) 16+

РОССИЯ 1

04.30 Евгения Осипова, Татьяна Назарова, Кирилл Жандаров и Владимир Стержаков. «ДОЯРКА ИЗ ХАЦАПЕТОВКИ» 12+
07.40 Александр Демьяненко, Алексей Смирнов, Наталья Селезнёва, Юрий Никулин, Георгий Вицин и Евгений Моргунов. «ОПЕРАЦИЯ «Ы» И ДРУГИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 6+
09.20 Надежда Румянцева, Николай Рыбников, Люсьена Овчинникова, Инна Макарова, Светлана Дружинина, Михаил Пуговкин. «ДЕВЧАТА» 0+
11.00 Вести
11.20 Местное время. Вести-Татарстан
11.30 Премьера. «Короли смеха». 16+
13.50 Александр Михайлов, Людмила Гурченко, Нина Дорошина, Сергей Юрский, Наталья Тенякова. «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ» 12+
15.35 Андрей Мягков, Барбара Брыльска. «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЁГКИМ ПАРОМ!» 0+
18.50 Юрий Никулин, Андрей Миронов, Анатолий Папанов, Нина Гребешкова, Нонна Мордюкова и Светлана Светличная. «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА» 0+
20.35 Евгений Леонов, Савелий Крамаров, Георгий Вицин, Раднэр Муратов, Эраст Гарин и Наталья Фатеева. «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ» 6+
22.05 Премьера. «Новогодний парад звёзд»
23.55 Новогоднее обращение Президента Российской Федерации В.В. Путина
00.00 Новогодний голубой огонёк-2022

МАТЧ ТВ

06.00, 11.30, 23.30, 05.30 Матч! Парад 16+
07.00, 08.50, 12.50, 18.10 Новости
07.05 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «БРЭК!» Мультфильм 0+
09.05 «КТО ПОЛУЧИТ ПРИЗ?» Мультфильм 0+
09.15 «НЕУДАЧНИКИ». Мультфильм 0+
09.25 «РАЗБОРКИ В СТИЛЕ КУНГ-ФУ» 16+
12.00 Скелетон. Кубок мира. Женщины. Прямая трансляция из Латвии
12.55 «Премия Матч ТВ» 12+
14.30 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Германии
15.55 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов». Прямая трансляция из Германии
17.05 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Германии
18.15 Все на Матч! Новогодний эфир 12+
21.00 Хоккей. НХЛ. «Оттава Сенаторз» – «Питтсбург Пингвинз».
23.55 НОВОГОДНЕЕ ОБРАЩЕНИЕ ПРЕЗИДЕНТА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ. В.В. ПУТИНА
00.05 Смешанные единоборства. UFC. Лучшие бои Хабиба Нурмагомедова 16+
03.00 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Канада – Финляндия. Прямая трансляция из Канады

НТВ

05.00 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.25 Леонид Куравлев, Евгений Леонов, Евгения Симонова. «АФОНЯ» 0+
08.00, 10.00, 13.00 Сегодня
08.15 Олег Янковский, Ирина Купченко, Екатерина Васильева. «ПРИХОДИ НА МЕНЯ ПОСМОТРЕТЬ» 0+
10.15 Олег Табаков, Валентин Гафт, Николай Фоменко. «СИРОТА КАЗАНСКАЯ» 6+
11.35 Следствие вели... Новогодние расследования (S) 16+
13.15 «Следствие вели... в Новый год» 16+
18.00 Премьера. «Новогодняя сказка» (S) 12+
20.22 Премьера. «Новогодняя Маска 2022» (S) 12+
23.55 Новогоднее обращение Президента Российской Федерации В.В. Путина.
00.00 Премьера. «Новогодняя Маска 2022». Продолжение (S) 12+
02.00 Премьера. «Квартирник НТВ у Маргулиса. Новогодний андеграунд» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Пять ужинов» 16+
07.00 «ЧУЖАЯ СЕМЬЯ» 16+
11.00 «ОДНА НА ДВОИХ» 16+
15.20 «ДОМ, КОТОРЫЙ» 16+
19.30 «Предсказания: 2022» 16+
23.55 «Новогоднее обращение президента российской федерации В.В. Путина» 0+
00.05 «Предсказания: 2022» 16+
03.50 «Наш Новый год. Романтические шестидесятые» 16+
04.40 «ГАДАЮ-ВОРОЖУ» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «НОВОГОДНИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ МАШИ И ВИТИ» 6+
06.15 «ФОРМУЛА ЛЮБВИ» 12+
07.45, 08.10 «АХ, ВОДЕВИЛЬ, ВОДЕВИЛЬ...» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.10 «ЗА ПЯТЬ МИНУТ ДО ЯНВАРЯ» 16+
12.45, 13.10 «КАЛАЧИ» 12+
14.20 «ОВЕЧКА ДОЛЛИ БЫЛА ЗЛАЯ И РАНО УМЕРЛА» 12+
16.25, 18.10 «ПРИХОДИ НА МЕНЯ ПОСМОТРЕТЬ...» 12+
18.25 «НОВОГОДНИЙ РЕЙС» 16+
22.00 «Звездная ночь» 6+
23.55 Новогоднее обращение Президента Российской Федерации В.В. Путина
00.05 «Салют, страна!» 6+
00.40 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА» 12+
03.00 «ОБЫКНОВЕННОЕ ЧУДО» 12+

1 гыйнвар | Шимбә

ТАТАРСТАН

21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 Детский телевизионный фестиваль исполнителей татарской песни «Сәйлән-2021» 0+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «60 яшь тә узып китте, 61 килеп җитте».Татарстанның халык артисты Виталий Агапов 6+
14.25 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 12+
16.10 Эльмира Кәлимуллина концерты 6+
18.00 «Җырлыйк әле!» Яңа ел чыгарылышы 6+
19.00 IX «Болгар радиосы» Милли музыка премиясен тапшыру тантанасы 6+
22.30 «ЗАМЁРЗШАЯ ИЗ МАЙАМИ» 16+
00.15 «Видеоспорт» 12+
00.40 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 12+
04.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.35 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Таҗдай кояш нурлары». Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдинов турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Атылган йолдыз эзләреннән. Ф.Яруллин» 6+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
17.00 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты 6+
18.30 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
22.00 «ТУКРАН ТӘҮБӘСЕ». «МУНЧА ТАШЫ» татар эстрада театры спектакле 16+
01.05 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе 6+

1 КАНАЛ

05.30 Хоккей. Молодежный чемпионат мира 2022. Сборная России – сборная США. Прямой эфир из Канады (S)
08.00 «КАРНАВАЛЬНАЯ НОЧЬ» 0+
09.15, 10.15 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
11.55 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН» 6+
14.35 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 6+
15.55 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ» 6+
17.25 Премьера. «Лучше всех!» Новогодний выпуск (S) 0+
19.00 Премьера. «Две звезды. Отцы и дети». Новогодний выпуск (S) 12+
20.45 Премьера. Дмитрий Нагиев. «БУМЕРАНГ» (S) 16+
22.30 «Вечерний Ургант». «Ciao, 2021!» (S) 16+
23.40 Мировая премьера. Экранизация романа Жюля Верна «ВОКРУГ СВЕТА ЗА 80 ДНЕЙ» 16+
00.30 «Новогодний концерт» (S) 12+
01.55 «Новогодний калейдоскоп» (S) 16+
03.40 «Первый дома» (S) 16+

РОССИЯ 1

04.20 Андрей Мягков, Барбара Брыльска. «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЁГКИМ ПАРОМ!» 0+
07.40 Надежда Румянцева, Николай Рыбников, Люсьена Овчинникова, Инна Макарова, Светлана Дружинина, Михаил Пуговкин. «ДЕВЧАТА» 0+
09.20 Александр Михайлов, Людмила Гурченко, Нина Дорошина, Сергей Юрский и Наталья Тенякова в комедии Владимира Меньшова «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ» 12+
11.10 Евгений Леонов, Савелий Крамаров, Георгий Вицин, Раднэр Муратов, Эраст Гарин, Наталья Фатеева. «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ» 6+
12.40 Юрий Никулин, Андрей Миронов, Анатолий Папанов, Нина Гребешкова, Нонна Мордюкова и Светлана Светличная. «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА» 0+
14.20 Премьера. «Песня года»
16.15 Премьера. «Юмор года» 16+
18.35 Светлана Крючкова, Ирина Муравьёва, Владимир Машков, Фёдор Добронравов, Сергей Маковецкий, Михаил Пореченков, Чулпан Хаматова, Сергей Пускепалис, Ирина Пегова, Марина Александрова, Павел Деревянко, Евгений Ткачук, Роман Мадянов, Авангард Леонтьев. «ОДЕССКИЙ ПАРОХОД» 12+
20.00 Вести
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. Виктор Хориняк, Мила Сивацкая, Екатерина Вилкова, Елена Яковлева, Константин Лавроненко, Тимофей Трибунцев, Александр Семчев, Сергей Бурунов, Елена Валюшкина, Юрий Цурило. «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ: КОРЕНЬ ЗЛА» 6+
23.35 Премьера. Евгений Миронов, Евгений Романцов, Виктория Агалакова, Ян Цапник, Гоша Куценко, Мария Лисовая, Елена Яковлева, Михаил Ефремов, Дмитрий Назаров, Светлана Иванова. «ВРАТАРЬ ГАЛАКТИКИ» 6+
01.40 Ольга Лерман, Евгений Романцов, Дарья Румянцева, Александр Макогон, Ольга Кузьмина. «НОВОГОДНИЙ ЭКСПРЕСС» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Фестиваль гимнастических видов спорта «Возрождение». Трансляция из Москвы 0+
08.00 МультиСпорт 0+
09.00 «АС ИЗ АСОВ» 12+
11.10, 13.55 Лыжные гонки. Кубок мира. Спринт. Прямая трансляция из Германии
13.05 Санный спорт. Кубок мира. Двойки. Прямая трансляция из Германии
15.55 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов». Прямая трансляция из Германии
17.45, 02.00 Матч! Парад 16+
18.15 «КРАСНАЯ ЖАРА» 16+
20.25 Смешанные единоборства. UFC. Лучшие бои Хабиба Нурмагомедова 16+
22.00 Хоккей. НХЛ. «Нью-Йорк Айлендерс» – «Эдмонтон Ойлерз». Прямая трансляция
00.30 Дартс. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Великобритании
03.00 Хоккей. НХЛ. «Зимняя классика». «Миннесота Уайлд» – «Сент-Луис Блюз». Прямая трансляция
05.30 Теннис. Кубок АТР. Россия – Австрия. Прямая трансляция из Австралии

НТВ

05.00 Максим Аверин, Ярослав Бойко. «ГОРЮНОВ 2» (S) 16+
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
09.20 Сериал «ГОРЮНОВ 2» (S) 16+
14.00 «НОВОГОДНИЙ ПЁС» (S) 16+
15.30 Премьера. «Новогодний миллиард» (S)
17.00 Премьера. Евгений Цыганов, Светлана Ходченкова, Владимир Меньшов, Максим Лагашкин. «ВЕЗЁТ» (S) 16+
21.25 «Новогодняя Маска 2021» (S) 12+
01.00 Федор Лавров, Светлана Колпакова. «ГАРАЖНЫЙ ПАПА» (S) 12+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «ВОЗВРАЩЕНИЕ В ЭДЕМ» 16+
12.15 «ЕСЛИ НАСТУПИТ ЗАВТРА» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
23.10 «ЖЕНСКАЯ ИНТУИЦИЯ» 16+
01.35 «АНЖЕЛИКА – МАРКИЗА АНГЕЛОВ» 16+
03.35 «Наш Новый год. Душевные семидесятые» 16+
04.50 «Наш Новый год. Золотые восьмидесятые» 16+
06.00 «Домашняя кухня» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «СОЛОМЕННАЯ ШЛЯПКА» 12+
07.35 «СОБАКА НА СЕНЕ» 12+
09.55 «ВАРВАРА-КРАСА, ДЛИННАЯ КОСА» 6+
11.20 «ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО» 12+
22.00 «ОВЕЧКА ДОЛЛИ БЫЛА ЗЛАЯ И РАНО УМЕРЛА» 12+
00.05 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ» 12+
03.20 «НОВЫЙ ГОД В НОЯБРЕ» 12+

2 гыйнвар | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

20.45 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар концерты 6+
08.30 «ХАЙКЮ». Мультфильм 12+
09.00 Детский телевизионный фестиваль исполнителей татарской песни «Сәйлән-2021» 0+
10.00 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 12+
14.30 «7 малай». Фирдүс Тямаев концерты 6+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
21.30 «НОВОГОДНИЙ ПАПА» 12+
23.15 «ПРАЗДНИК ВЗАПЕРТИ» 16+
00.35 «Видеоспорт» 12+
01.00 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
01.30 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
07.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Фердинанд Сәләхов турында телеочерк (субтитрлы) 6+
08.00 «АВЫЛ ЭТЕ АКБАЙ». Балалар өчен спектакль 6+
09.15 «КАЙДА СИН?» Беренче серия 12+
10.15 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова концерты 6+
12.05 «ЕГЕТ СҮЗЕ БЕР БУЛА» 6+ (субтитрлы)
13.00 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин концерты 6+
15.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
17.10 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
18.00 «КАЙДА СИН?» Икенче серия 12+
18.50 «Кемгә – юмор, кемгә – җыр». Җәвит Шакировның юбилей кичәсе» 6+
21.10 Т.Миңнуллин. «ЙӨРӘК МАЕМ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
23.25 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
23.50 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
03.30 «Бер сулышта». Артур Исламов һәм Эльза Заяри концерты 6+
05.05 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+

1 КАНАЛ

05.40, 06.10 Фильм «ЗОЛОТЫЕ РОГА» 0+
06.00 Новости
07.05 Фильм «ФИНИСТ–ЯСНЫЙ СОКОЛ» 0+
08.25 Фильм «СТАРИК ХОТТАБЫЧ» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.10 Премьера. «ПРОСТОКВАШИНО» (S) 0+
10.50 Фильм «МОРОЗКО» 0+
12.25 «Особенности национальной охоты в зимний период» (S) 16+
13.50 Премьера. «Главный новогодний концерт» (S) 12+
15.55 Маколей Калкин. «ОДИН ДОМА» 0+
17.55 «Ледниковый период» (S) 0+
21.00 «Время»
21.20 Финал. «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига (S) 16+
00.00 Мировая премьера. Экранизация романа Жюля Верна «ВОКРУГ СВЕТА ЗА 80 ДНЕЙ» 16+
01.00 «Точь-в-точь». Новогодний выпуск (S) 16+
03.35 «Новогодний календарь» (S) 0+

РОССИЯ 1

05.05 Мария Куликова, Игорь Бочкин, Елена Дробышева, Катерина Шпица, Александр Пашков, Кирилл Гребенщиков, Александр Феклистов, Анна Легчилова, Александр Лазарев-ст., Светлана Немоляева. «ГОЛУБКА» 16+
07.05 Мария Порошина, Татьяна Колганова, Дарья Щербакова, Олег Алмазов, Алексей Коряков, Пётр Баранчеев, Алексей Демидов, Дмитрий Пчела, Анатолий Лобоцкий, Евгения Нохрина. «ЧЁРНАЯ КРОВЬ» 12+
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым». Праздничный выпуск
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 Алёна Хмельницкая, Пётр Баранчеев. «ГАЛИНА» 12+
15.20 Премьера. «Песня года»
17.25 Премьера. «Юмор года» 16+
20.00 Вести
20.45 Местное время. Вести-Татарстан
21.00 Виктор Хориняк, Мила Сивацкая, Екатерина Вилкова, Елена Яковлева, Константин Лавроненко, Александр Семчев, Сергей Бурунов. «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ» 12+
23.15 Виктор Хориняк, Мила Сивацкая, Екатерина Вилкова, Елена Яковлева, Константин Лавроненко, Тимофей Трибунцев, Александр Семчев, Сергей Бурунов, Елена Валюшкина, Юрий Цурило. «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ: КОРЕНЬ ЗЛА» 6+
01.25 Мария Порошина, Елена Панова, Светлана Иванова, Ирина Розанова, Владимир Епифанцев, Юрий Цурило, Вадим Колганов, Константин Юшкевич, Зоряна Марченко, Макар Запорожский. «ЧЕЛНОЧНИЦЫ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Теннис. Кубок АТР. Россия – Австрия. Прямая трансляция из Австралии
07.00 МультиСпорт 0+
08.55 «БЕГЛЕЦЫ» 12+
10.45 «КРАСНАЯ ЖАРА» 16+
12.50 Санный спорт. Кубок мира. Женщины. Прямая трансляция из Германии
13.50 Смешанные единоборства. UFC. Лучшее 16+
14.55 Футбол. Чемпионат Шотландии. «Селтик» – «Рейнджерс». Прямая трансляция
17.00 «ВОИН» 16+
19.50, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
20.30 Хоккей. НХЛ. «Нью-Йорк Рейнджерс» – «Тампа-Бэй Лайтнинг». Прямая трансляция
00.00 Матч! Парад 16+
01.00, 03.30 Хоккей. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. 1/4 финала. Прямая трансляция из Канады

НТВ

04.30 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.00 «АЛМАЗ В ШОКОЛАДЕ» (S) 12+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.15 Алена Бабенко, Павел Деревянко, Михаил Ефремов, Гарик Сукачев, Ильзе Лиепа в новогодней комедии «ЛЮБИ МЕНЯ» 12+
10.20 Сериал «ВЕЗЁТ» (S) 16+
16.20 «Новогодняя Маска 2022» (S) 12+
19.25 «Новогодняя Маска 2022». Продолжение (S) 12+
23.20 Светлана Ходченкова, Дмитрий Дюжев. «В ЗОНЕ ДОСТУПА ЛЮБВИ» (S) 16+
01.25 Федор Бондарчук, Алексей Кравченко. «ДЕД МОРОЗ. БИТВА МАГОВ» 6+
03.15 «НОВОГОДНИЙ ПЁС» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «Пять ужинов» 16+
06.55 «ЗОЛУШКА» 0+
08.45 «ЗОЛУШКА» 16+
13.20 «ЗОЛУШКА С РАЙСКОГО ОСТРОВА» 16+
15.10 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
19.00 «ХРУСТАЛЬНАЯ МЕЧТА» 16+
23.30 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» 16+
02.00 «ВЕЛИКОЛЕПНАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
03.45 «Наш Новый год. Лихие девяностые» 16+
05.00 «Ванга. Предсказания сбываются» 16+
05.50 «Домашняя кухня» 16+
06.15 «Пять ужинов» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Не факт!» 12+
06.25 «ОБЫКНОВЕННОЕ ЧУДО» 12+
08.45, 09.15 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
11.20, 13.15, 18.10 «ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО» 12+
22.15 «СОБАКА НА СЕНЕ» 12+
00.30 «СОЛОМЕННАЯ ШЛЯПКА» 12+
02.45 «ВАРВАРА-КРАСА, ДЛИННАЯ КОСА» 6+
04.05 «НОВОГОДНИЙ РОМАНС» 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 27 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10 Ибраһим Сәлахов. «Колыма хикәяләре». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Гаяз Исхакый. «Локман Хәким». Хикәя
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 28 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Салих Сәйдәшев әсәрләре

Чәршәмбе, 29 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Эстрада концерты

Пәнҗешәмбе, 30 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Мостафа Ногман шигырьләренә җырлар

Җомга, 31 декабрь

11.10 «Яңа елга бергәләп». Балалар өчен радиопостановка
12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00, 21.00-21.10, 22.00-22.10, 23.00 Трансляция радио России
13.10, 15.10, 21.10 «Татарстан дулкынында». «Татар сүзе» республика конкурсының Гала-концерты
18.10 Новости. Итоги года
22.10 «Хуш киләсең, Яңа ел!» Татарстан һәм Россия сәнгать осталары концерты
22.45 Татарстан Президенты Р.Н.Миңнехановның Яңа ел мөрәҗәгате

Шимбә, 1 гыйнвар

Хуш киләсең, Яңа ел!
8.10 «Чыршы әйләнәсендә». Балалар өчен әдәби-музыкаль программа
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10,16.00 Трансляция радио России
10.10 «Кызыклы очрашулар кунакханәсе». Әсхәт Хисмәт
11.25 Әсхәт Хисмәт җырлый
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Айдар Хәлим хикәяләре

Якшәмбе, 2 гыйнвар

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10, 11.10 Туфан Миңнуллин. «Авыл эте Акбай». Г.Камал ис. ТДАТ спектакленең радиоварианты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Дания Гайнетдинова әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция

ЕРЫК АВЫЗ

Укытучы балаларга «Әгәр мин фирма директоры булсам...» дигән темага инша язарга куша. Барысы да эшкә тотына, бер малай гына тик утыра.

– Ә син ник язмыйсың?

– Сәркатипне көтәм.

* * *

– Менә өйләндем, хәзер тәмәке тартырга ярамый, эчәргә ярамый, кызларга карарга ярамый...

– Үкенәсеңме?

– Үкенергә дә ярамый.

* * *

Пессимист белән оптимист очраша.

Пессимист:

– Шайтан алгыры! Көннәрнең үткәне сизелми дә кала. Күз ачып йомарга өлгермисең – ай узып та киткән.

Оптимист:

– Шулай шул. Һәм тагын акча ала торган көн җиткән.

Диплом о среднем профессиональном образовании регистрационный № 1675, выданный 01.07.2020 г. Казанским Энергетическим Колледжем на имя Фазульзянова Разиля Динаровича считать недействительным в связи с утерей.

«Аучылар ит өчен генә йөрергә тиеш түгел, табигатьне саклауны беренче урынга куям». Саба районында коткаручы булып эшләүче, 25 ел аучылык белән шөгыльләнүче Марат Әхмәтвәлиев әнә шулай ди. Аның белән кышкы урман, аучылар һәм кыргый хайваннар психологиясе турында сөйләштек.

УЕН ӘШ ТҮГЕЛ

АУЧЫ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ ТУРЫНДА

Һәр эз якын

Казан дәүләт университетының тарих бүлегендә укыганда ук Марат тулай торакта яшәүче кызларга куян койрыклары бүләк итә иде. Ул чакта аның ауга йөрим дип сөйләнүенә әллә ни исебез китмәгән. Мәктәптә тарих укытып, коткаручы эшенә күчкән егетнең күңеленә тулы бер урман сыйган булып чыкты. Андагы һәр фасыл, һәр эз, тавыш якын аңа. Киров өлкәсенең Нократ авыл хуҗалыгы академиясенең аучылык факультетына укырга кереп, югары белем дә алган икән. Элегрәк бу хакта белгән булсам, тарих бүлегенә кермәгән дә булыр идем, бәлкем, ди. Монда аңа белемнәр туплаган.

Шулай да сорауның иң катысыннан башладым. Бераз ошап та бетмәде, ахры.

– Аучыларның бәгырьләре катыга әйләнеп бетмиме? – дип сорадым яшьлек дустымнан.

– Әгәр кызганасың икән, аучы булып булмый, билгеле. Әмма бу каты бәгырьле дигәнне аңлатмый. Аучы ул – күргән бер нәрсәне атучы дигән сүз түгел. Теләсә кайчан, күпме кирәк шуның кадәрне атучылар браконьер дип атала. Аучыларга кешеләрнең тискәре карау гадәте бар. Ничек каргыштан курыкмыйсың, диләр. Тик без табигатьне, җәнлекләр дөньясын да саклыйбыз. Көртлекләргә – ташлы ком, куян, пошиларга – тоз, кабаннарга ашлык чүпләре салабыз. Кабанга кышын ашарга табу авыр. Әгәр салкын булса, балаларының күбесе ачтан үлә. Ашарга куйган җирдә үсә алар. Ятим бала кебек күзгә карап торалар, кайвакыт яныбыздан да китмиләр. Тирән карда йөри алмыйлар, – ди ул. – Төлкеләргә каршы көрәш алып барабыз. Төлкеләр, фермаларга барып, сыерларга ташлана, этләрне талый. Ул этләр мәчеләргә, кешеләргә, хуҗаларны тешләргә мөмкин. Котыру чире белән күп кеше җәфалана. Без моның белән шөгыльләнмәсәк, кем шөгыльләнер? Кыш буе урманда җәнварларның исәбе алына. Һәр участокта, әйтик, күпме поши, кабан атарга яраганлыгы билгеләнә. Ау ул – уен-муен эш түгел, шул ук математика, журналистика кебек бер өлкә, бер фән. Әгәр куян санын киметмәсәң, чир чыга да озын колакларның бөтенесе үлеп бетә. Аларның санын нормага җиткерү өчен тагын биш ел вакыт кирәк.

Марат әйтүенчә, браконьерлар – «мылтыклы кешеләр», аларга бары атарга гына булсын. Аучыларга исә кыргый хайваннарга качар өчен шанс та бирергә туры килә. Ауда сине хайван алдыймы, әллә син анымы – менә шул процесс кызык. Ядрә тиде дип шатланган, шул ук вакытта әле ярый тимәде дигән чаклары да була.

Сүзебез матурлыкка таба борыла. «Кышкы урман үзенчә матур. Көртлек, боҗырлар, пырхылдап, аякка бәрелеп үтәләр. Урманда кошлар сайрамаса, җәнлек эзләре күренмәсә, бернинди ямь дә булмаячак. Коры агачлар белән генә урман була алмый. Мондагы тереклекне тоя, матурлыкны күрә белергә генә кирәк», – ди. Бер романтик икәнсең бит син, Марат!

Урман җене кагылган

Әтисе урманчы булып эшләгәч, Марат ун ел урманда, кордондагы урманчы өендә яшәгән. Табигатькә якынаю шул чактан килә. Аучы әтисенә ияреп, күп нәрсәгә өйрәнгән. Этләр ияртеп, җәнлекләр эзеннән йөрү бер ләззәт булган. Сусарларга капкын да куйгалаган. 1996 елда аучылык җәмгыятенә кергәч, эте белән законлы ауга йөри башлаган. Бу урында ул: «Этләрнең поши, кабан, кошлар куа торганы була. Ә минеке төлке, куяннар артыннан чабарга ярата», – дип аңлата. Урманга гел мылтык алып та йөрми. Эте куян куганда, ул табигатькә соклана. Эте белән төрле төбәкләргә күргәзмәләргә, куян куу ярышына барып, урыннар да алгалый.

Куянын гына түгел, поши, кабанын да, аю да атканы бар. Дөрес, Татарстанда урман хуҗаларын аулау рөхсәт ителми. Тик Россиядә тыелмый бу. Шуңа күрә аю ауларга Киров якларына йөргәли. Саба урманында исә алар 1990 елда барлыкка килгән. Аюның очраганы юк икән. «Андый очракта биегрәк җиргә басып, катырак кычкырырга кирәк», – ди аучы.

Марат көзге, кышкы урманны күбрәк ярата. Җәй көне кигәвен, черкигә чыдасаң гына, озак йөреп була, ди. Тигәнәге, кычытканына да түзәргә кирәк. Урманда адашмыйча, күзен йомып та йөри ала. Кешеләрне коткарган чаклары да аз түгел. Гөмбә, җиләк җыярга баручылар ярдәм сорап та шалтыраткалый. Фәлән агач төбендә, фәлән урында басып торам, диючеләргә телефон аша да юл табарга булышкан. Бер елны көз көне иртәнге сәгать алтылар тирәсендә эте өрә башлаган. Бик нык кычкырган тавыш ишеткән. Барып караса, яланаяк, салкыннан күшегеп беткән бер хатын басып тора икән. Маридан килгән, хәтере чуалган булып чыккан. Аны урманнан алып чыгып, җылытып, полициягә илткән. Алар туганнарына тапшырган.

Кешеләрне җиләккә, чикләвеккә, гөмбәгә йөртә, үзе дә чиләген тутырып кайта. Ку гөмбәсен (чага) җыя. Себеркеләр бәйли. Урманның файдасын күрә, кыскасы.

Байлар кими төлке тун

Хәзерге вакытта бөтен төр җәнлек, кыргый хайваннарны да ауларга ярый. Җәй ахырында ачылган сезон февральгә кадәр дәвам итә. Җәй көне ауга бару тыела, бу вакытта урманда тереклек дөньясы балалар үстерә.

Һәрбер төр хайванга рөхсәт кәгазе сатып аласы. Көртлекме, куянмы, пошимы – һәрберсенең үз бәясе. Шуңа күрә бер әйбер дә бушлай атылмый. Бер поши ату өчен – 60, кабанга 20 мең сумлык рөхсәт кәгазе кирәк. Казаннан поши атучылар да кайта. Әгәр ата алмасалар, акчалары әрәм дигән сүз. Тояклы хайванны аучылар күмәкләшеп аулый. Махсус яктыртмыч киемнән чыкмасалар, штраф түләргә туры килә.

– Тире сатып баеп булмый, ул чыгымны капласа да ярый әле. Элек төлке тиресе бер айлык хезмәт хакына тиңләнсә, бүген аны җыючы юк. Хатын-кызлар төлке тунга кызыкмый бит хәзер. Төлкене бары котыру чире чыкканга гына атабыз. Сусарлар, кыйммәтле мехлы җәнлек тиреләре алалар. Итен гаиләм ашамый. Дусларга бирәм, үзем пешереп ашыйм. Сораучылар бар. Атканда бисмилла әйтеп атам. Аткач, сулышы бетмәсә, чалам, чалынмаса, хәрам була, – ди Марат.

Үч

Бүредән курыксаң, урманга бармыйсың. Барасың икән, барлык кагыйдәләрне белергә кирәк. Бүре дигәннән, ул хәзер урман санитары дип саналмый. Киресенчә, терлекләрне юк итеп, зыян гына сала икән. Ике бүрегә өч тәүлеккә бер поши кирәк. Һәрхәлдә, аңгәмәдәшем шулай ди. Безнең урманнарда очрамыйлар икән.

Мылтык бар нәрсәне хәл итми. Кыргый хайваннар һөҗүм итәргә дә мөмкин. Кыр куяны кулны тырный. Башкасы башка яктан холкын күрсәтә. Һәрберсе яшәү өчен көрәшә.

– Элек бер аучы пошины аткан да янына килгән, ә ул җан бирмәгән булган. Мөгезе белән ике агач уртасына тотып ыргыткан тегене. Аучының киемнәре ертылган, көч-хәл белән исән калган. Яраланган аю, кабан да хәтәр. Бервакыт ата кабанны аткач, анасы, балаларын ияртеп, артымнан килеп чыкмасынмы?! Биш метр арада күзгә-күз карашып тордык. «Кит!» – дип бик каты кычкырдым. Кулда мылтык бар, тик артыгын атарга ярамый. Әйттем ич инде, аучы теләсә ничек атарга тиеш түгел дип. Бу вакытта инде син браконьер буласың, – диде Марат Әхмәтвәлиев.

Сәрия МИФТАХОВА

Федор БАТКОВ, Татарстан Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе:

Татарстанда соңгы ун елда пошилар саны 12 меңгә җитте. Кызганыч, юлларга чыгу сәбәпле, ел саен 120–130 поши таптала. Көртлек, ак көртлек, суер кебек кошлар күбәйде. Кыр кәҗәләре ун тапкыр артты. Ә куяннар саны кими бара. Әйтик, кыр куяннары кимеп, Кызыл китапка кертелде. Безнең урманнарда 86 төрле хайван һәм җәнлек яши. Аларны саклау өчен урманнарда тозлыклар, җимлекләр куябыз. Быел 31 меңнән артык шундый урын булдырылды. Ел саен аучыларга 35 мең рөхсәт кәгазе бирәбез. Бер ел эчендә браконьерларга карата 1294 административ эш ачылды.

Кыргый хайваннар очраганда, үзеңне ничек тотарга?

Татарстан Биоресурслар буенча дәүләт комитеты белгечләре киңәшләре

1 Юлда кыргый хайван очратсагыз, аңа якын килмәгез.

2 Аларны ашатудан һәм алар янәшәсендә фотога төшүдән тыелып торыгыз.

3 Хайванны күргәч, кискен хәрәкәт ясамыйча, тыныч кына куркынычсыз урынга китегез. Бу койма, подъезд, йорт булырга мөмкин. Тормышыгызга куркыныч янамавына инангач, 112 номеры буенча ашыгыч хезмәт чакырырга кирәк.

4 Хайваннарга кычкырырга яки аларга карата агрессия күрсәтергә ярамый. Төлке, бүре, селәүсен һәм башка кыргый җанварлар кешеләрдән курка һәм бары куркыныч сизгәндә генә ташланалар.

***Исегездә тотыгыз:** сәламәт хайван өч очракта һөҗүм итәргә мөмкин: аны куркытканда, хайван сездән агрессия көтсә һәм токымын яклаганда.*

СӨЕМБИКӘ ХАНБИКӘ

«Хөрмәтле редакция! Шаһгали хан турында тарихи язманы бик кызыксынып укыдык. Без белмәгән нәрсәләр искиткеч күп икән, дөрес, кайберләре онытылгандыр да инде. Шул җәһәттән Сөембикәбез турында да укыйсы килеп китте. Аның хакында да күбебез риваятьләргә таянып кына эш йөртә кебек. Чынбарлыкта ханбикәбезнең язмышы ничек булган икән?»

Хөрмәт белән, Сәлим ГӘРӘЕВ.

Укучыбызның соравына җавап бирү ниятеннән без тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН белән сөйләштек.

:: Фаяз Шәрипович, татар тарихында дәүләт башлыгы булып торган берденбер хатын-кыз Сөембикәнең язмышы тарихның бәхетле мизгелләрен дә, кайгы-хәсрәтләрен дә, өмет-хыялларын да – барысын да сыйдырган. Кем ул безнең ханбикәбез? Кайдан, нинди нәселдән?

– Түбән Идел белән Җаек елгалары арасында, хәтта тагын да ераграк – Арал диңгезенә кадәр сузылган иксез-чиксез далаларда Нугай кабиләләре күчмә тормыш алып барган. Алтын Урда таркалган чорда нугайлар дәүләт булып оешалар. Хакимнәре – Идегәй нәселеннән чыккан бәкләр, морзалар. Җаекның түбән агымында, Каспий диңгезенә килеп җитәрәк бер урында барлыкка килгән Сарайчык аларның башкаласы була. Казан ханнары белән тыгыз элемтәдә торганнар. Алар арасында никах бәйләнешләре дә булган.

:: Сөембикәнең дә Казанга килеп чыгуы никахына бәйле...

– 1531 елда Казан тәхетенә Мәскәү тәкъдиме белән Касыймнан килгән Җангалине утырталар. Ул – татар тарихында сатлыкҗан буларак кереп калган Шаһгалинең бертуган энесе. Мөстәкыйль сәясәт алып бару өчен әле яшь була. Ә Мәскәү кенәзе бик мәкерле эш йөртә. Аның максаты бер: Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларны үзенә буйсындыру. Мәскәү Касыймнан китереп утыртылган Җангали аша Казан белән үзе теләгәнчә идарә итә алачак. Әгәр дә аны берәр Нугай кызына өйләндереп тә куйсаң, Казан аша Нугай Урдасына да юл салырга мөмкин. Үсмер кыз Сөембикә боларны әлегә белми. Әмма аның язмышы шул сәясәт белән бәйле булачак.

:: Иркенлек, мөстәкыйльлек яратучы дала-кырлар кызы Казанны ничек кабул итә?

– Сөембикә өчен бөтенләй яңа тормыш башлана. Казан – гүзәл, бай, искиткеч матур кала. Анда биек таш йортлар, манаралары күккә ашкан мәчетләр һәм адым саен аны баш иеп сәламләүче сарай әһелләре. Әмма Сөембикә үзен ялгыз хис итә. Ул бик күзәтүчән, үткен, эшнең асылына тиз төшенүчән бикә була. Беренче күрүгә үк, Җангалине ошатмый – хыялындагы егеткә бер дә туры килми ул. Казан кадәр Казанның ханы бик тә горур, һәр сүзен үлчәп сөйли торган, акыллы һәм... кул астындагы түрәләрнең котын алып торырлык гайрәтле һәм каты куллы ир булырга тиеш бит. Ә ул – беркатлы һәм җебегән, йомшак холыклы бер бәндә. Үз шәүләсеннән үзе куркып йөри. Сарай түрәләре арасында барлыкка килгән ике капма-каршы төркемнең үзара көрәшен дә күрми, күрсә – аңламый. Дошманнары көннән-көн артып тора. Җангалинең ил-дәүләт өчен бернинди файдалы гамәл дә кылганы юк, Мәскәү ни кушса шуны эшләп ята, ахыры хәерле булмастыр, ул Казан тәхетенә лаек түгел, дип уйлый Сөембикә. Шулай булып чыга да: 1935 елның 25 сентябрендә Казансу буенда Җангалинең үле гәүдәсен табалар.

:: Җангали урынына тәхеткә килгән Кырым ханы Сәхипгәрәйнең энесе Мөхәммәтгәрәй улы Сафагәрәй белән Сөембикәнең мәхәббәте легендаларга кереп калган...

– Сафагәрәйгә ул вакытта 26 яшь була. Өйләнгән, дүрт хатыны бар. Аңа Казан түрәләре иреннән тол калган Сөембикәне димлиләр. Йола шулай куша. Ата-бабаларының гореф-гадәтен белгән Сөембикә моңа күңеле белән әзер була, ризалыгын бирә. Тарихи язмалардан күренгәнчә, бу икәүнең мәхәббәте, чыннан да, беренче күрешүдән үк башлана һәм соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Сафагәрәй бар яклап та Җангалинең киресе булып чыга: кыю һәм тәвәккәл, табигать биргән акыл, үз сүзен сүз итә алырдай көчле рухлы гайрәтле ир. Тагын бер өстенлеге: ул Мәскәүдән еракта туып үскән һәм тәрбияләнгән. Мәскәүдән дә, Кырымнан да бәйсез сәясәт корырга омтыла. Әмма Сафагәрәй идарә иткән чорда Мәскәү хөкүмәте Казанга дәгъвасыннан баш тартмый, Кырым ханы да Казан җирен үзенеке дип саный. Сафагәрәй рус җирләренә яу чаба. Мәскәүдә бу вакытта «Явыз» кушаматын алачак Иван IV идарә итә. Җавап йөзеннән ул да сугышка әзерләнә башлый, Җангали чорындагы бәйләнеклекне кайтарып алырга ниятли. Шул ук вакытта Кырым ханы, Иван IV Казанга сугыш белән килгән очракта, рус җирләренә басып керәчәген әйтә. Бу шартларда Сафагәрәй Кырым яклы булырга карар кыла. Кырымнан чыккан кешеләрне үз янына туплый, казанлыларга ышанып җитми. Бу хәл белән килешмәгән Казан түрәләре Сафагәрәйгә каршы астыртын көрәш башлыйлар. «Мәскәү патшасы Казанга үзенең гаскәрен җибәрсен, бергәләп кырымлыларны куарбыз. Сафагәрәйне кулга алып, сезгә тапшырырбыз», – дип хат җибәрәләр. Мәскәүлеләр яу белән киләләр, әмма уңышсызлыкка очрыйлар. Бу хәлгә ризасызлык белдереп, Казан морзалары ханга каршы үзләре корал күтәрә. Сафагәрәй аптырап кала. Югыйсә ул Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге өчен көрәш алып бара бит. Ә монда нинди каршылык! 1546 елның гыйнварында Сафагәрәй – Кырымга, Сөембикә исә атасы янына, Нугай Урдасына китәргә мәҗбүр була.

:: Сөембикәнең кабат Казанга кайтуы нәрсә белән бәйле?

– Сафагәрәй киткәч, тәхеткә яңадан Шаһгали утыра. Тик күпкә түгел – бу юлы халык ризасызлык күрсәтә. Кем икәнлеген беләләр бит инде, Җангалигә кадәр тәхеттә утырганы бар. Сафагәрәй дә тик ятмый. Берничә айдан яхшы гына коралланган Нугай гаскәрләре белән Казанга кайта. Аны бернинди каршылыксыз кабул итәләр. Тормыш акрынлап үз җаена төшә. Тиздән хан белән ханбикәнең уллары Үтәмеш туа. Тик Казан тагын туздырылып ташланган кырмыска оясын хәтерләтә башлый. Сафагәрәй, элеккеге сәясәтен дәвам итеп, җирле түрәләрне кыерсыта, иң мөһим дәүләт урыннарына Кырым кешеләрен билгели. Ахыр чиктә 1949 елның мартында үтерелә. Аңа әле 40 яшь тә тулмаган була.

:: Шулай итеп, Сөембикә улы белән ялгызы кала...

– Ул үзен бик тиз кулга ала. Мәрхүм иренең васыяте һәм ата-анадан калган йола буенча, хан тәхетенә Үтәмешгәрәйне утырталар. Үсеп балигъ булганчы, аның исеменнән Сөембикә үзе идарә итеп торырга тиеш була. Хөкүмәт башлыгы итеп Сафагәрәй белән Кырымнан килгән хан гвардиясе башлыгы Кошчак билгеләнә. Тик Үтәмешгәрәйнең тәхеткә утыртылуыннан риза булмаган түрәләр хакимият өчен көрәшне туктатмыйлар. Сафагәрәйнең Кырымдагы өлкән улы Булатгәрәйне хан итеп куюны сорап, Бакчасарайга илчеләр җибәрәләр. Сәхипгәрәй, күрәсең, Сөембикә яклы була, ризалыгын бирми. Мәскәү патшасы да тик ятмый. Казанны тулысынча буйсындырырга җай чыкты дип, хәлиткеч сугышка әзерләнә.

:: Казан ханлыгын саклап калу өчен ханбикә нинди чаралар күрә?

– Сөембикә тарафыннан солых белән Мәскәүгә җибәрелгән илчеләр уңышка ирешә алмый. Казанга 1550 елда зур һөҗүм ясала. 1551 елда Иделнең аргы ягында, Зөя тамагында, рус крепостена нигез салына. Шул тирәдәге халыкны Мәскәү патшасына тугрылык сакларга ант иттерәләр. Ханбикә югалып калмый. Казан халкы белән киңәшләшеп, саклану чараларына тотына. Шәһәр ныгытмалары яңартыла. Корал җитештерүче остаханәләрдә көн-төн эш кайный. Әмма хәлләр катлаулана бара. Кошчак, гаиләсен алып, 300ләп кешесе булган гаскәре белән Казаннан чыгып качарга мәҗбүр була. Качакларны куып тотып, Мәскәүгә озаталар, барысын да җәзалап үтерәләр. Яңа хөкүмәт сайлана. Аның әгъзалары тарафыннан Зөя каласына Кол Шәриф җитәкчелегендә илчелек җибәрелә. Максатлары – бернигә дә карамастан, Казанны рус баскыннарыннан саклап калу. Ике арада солых төзелә. Аның бер шарты буенча, Сөембикәне һәм аның улы Үтәмеш ханны, әсирлеккә төшереп, Мәскәүгә озаталар. Бу 1551 елның августында була.

:: Күргәнебезчә, ханбикәне үз куллары белән әсирлеккә биреп җибәрүнең бернинди файдасы да булмый?

– 1552 елның 2 октябрендә Казан ханлыгы басып алына. Бу фаҗигадән соң Явыз Иван артыннан Шаһгали дә сугышчылары белән Мәскәүгә кайтып китә. Рус патшасы аңа Сөембикәне мәҗбүриләп кияүгә бирә.

:: Тарих битләрендә Сөембикәне яклаучылар турында язылганмы?

– Әтисе Йосыф морза, Сөембикәне әле Мәскәүгә алып киткәнче үк, аңа ярдәм кулы сузарга омтыла, кызын һәм оныгын әсирлектән йолып калу максаты белән, ике тапкыр үзенең гаскәрен Казанга җибәрә, әмма ике тапкырында да уңышсызлыкка очрый. Тиздән Йосыф морза белән Явыз Иван арасында хат алышу башлана. Мәскәү патшасыннан ул бары тик бер нәрсәне гозерләп сорый: кызы Сөембикә белән оныгы Үтәмеш сабыйны тоткынлыктан азат итеп, атасы янына, Нугай далаларына кайтарып җибәрергә. Хатлары катгый һәм ачулы була. Иван патша Йосыф морзага, һич тә борчылма, Сөембикә оҗмахта яши, тормышыннан бик тә канәгать, дип матур-матур, ләкин асылда чеп-чи ялган җавап хатлары яза.

:: Чынлыкта ханбикә ничек яши?

– Сөембикәне ялгызлык бетерә, аның хәтта эч серләрен сөйләп бушанырлык ахирәте дә булмый. Ире Шаһгали белән ике арадагы мөнәсәбәтләрдә дә бушлык. Ханбикә көннәр, атналар буе беркем белән дә сөйләшмичә, дәшмичә яши. Бу халәтне дә яшәү дип әйтеп булмый инде. Сабые Үтәмешне чукындырганнар, Александр дип исем кушканнар, дигән коточкыч хәбәр килеп ирешкәч, ул бөтенләй бетерелә, яшәвенең мәгънәсе калмый. Сөембикә күзгә күренеп сула, саргая, ашаудан кала һәм, бу газапларны кичерә алмыйча, 1557 елны, 38 яшендә якты дөнья белән хушлаша.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

СИННӘН – ЯРАТУ, АЛАРДАН – РӘХМӘТ

Тәрбиягә бала алучылар турында еш язабыз. Барысы да бер киңәш бирә: аны үзеңнеке итеп яратырлык булсаң гына алырга кирәк. Бала язмышы белән уйнарга ярамый! Арчада яшәүче Лилия Хәйретдинова да шулай ди.

Гаилә архивыннан

Ире белән алар авыру балаларны тәрбиягә алганнар. Теләкләре бер – бу сабыйларны интернатта яшәтмәү, аларны әти-әниле итү.

– Казанга 1995 елда Дагыстанның Махачкала шәһәреннән күчеп кайттык. Дәрвишләр бистәсенә килеп урнаштык. Ул вакытта үзебезнең улыбыз һәм кызыбыз үсә иде. Бистәбездә ятимнәр йорты барын белеп алдык та ирем белән шунда күчтәнәчләр илтә башладык. Әле ул вакытта балалар алу турында уйлаганыбыз юк иде, – дип сөйли Лилия апа.

Куңелләре шулай куша аларның. Кемгәдер ярдәм итәсе, кешеләрне сөендерәселәре килә. Үз балалары үсеп җиткәч, алар зур өйдә икәү генә утырып калалар. Менә шулчакта тәрбиягә бала алырга булалар.

– Ятимнәр йортына килгәч, безгә тормышта баскан җирдә ут чыгара торган малайларны күрсәттеләр. Ә безнең ярдәмгә мохтаҗ балаларны аласы килде. Сайланып вакыт уздырмадык. Авыру балаларны күрсәтергә куштык. Берне алырбыз дип барып, дүртне алып кайттык, – ди Лилия апа. – Мин аларның бер кимчелеген күрмим. Шулкадәр ияләндем инде. Аларсыз яшәүне күз алдына да китермим. Бер ел элек тагын бер бала алыйк дип барган идек, бишне алып кайттык. Дөрес, берсенең әлегә документлардын әзерлимәр. Әмма ул бездә яши инде.

Хәйретдиновлар йортында хәзер 18 яшьлек Данила, 16 яшьлек Юра, 15 яшьлек Андрей, 14 яшьлек Игорь белән Владик, 12 яшьлек Әмир һәм Артем, 13 яшьлек Илмир яши.

– Бу балаларны өйгә алып кайту белән, малларны да бетердек. Хәтта тавыкларны да апама бирдем. Эшләтер өчен бала алалар дип әйтмәсеннәр дидем. Үземне бары тик шул балаларга багышлыйм. Алар белән шөгыльләнәм, дәвалануга йөртәм. Әле менә бер улыбызга катлаулы операция ясадылар. 12 сәгать буе барды ул. Улыбыз хәзер бар нәрсәне оныта башлады. Наркоз нәтиҗәседер инде. Аңа да гел ярдәм кирәк, – ди әниләре.

Малайларның үз әти-әниләре кайдалыгы билгесез. Аларны тугач та ташлап калдырганнар.

– Акыл ягыннан зәгыйфь сабыйлар кемгә кирәк инде? Балалар йортыннан соң аларны психоневрологик интернатка җибәрәләр бит. Әнә шунда китмәсен дип алдык та инде. Ни дисәң дә, өйдә яшәү – ятимнәр йорты түгел бит, – ди Лилия апа. – Мин ул балаларны эшкә дә өйрәтәм. Алар миңа шулкадәр рәхмәтле. Сүземне тыңлыйлар. Ашарга да пешерә беләләр. Бик оста итеп төрле салатлар ясыйлар.

Лилия апа малайларны Кенәрдә урнашкан коррекция интернатына йөртә икән. Дүшәмбе илтеп куялар, җомга алып кайталар. Әмма ул моны дөрес түгел дип саный. Уларын янында тотасы килә. Әнә шуңа да алар киләчәктә, коррекция мәктәбе булган шәһәргә күченмәкчеләр. Әниләре аларның һәркөн өйгә кайтуын тели.

– Үсмерлек чорына җиткән балаларны тәрбиягә алырга теләүче сирәк. Әле бит авырулары да бер кочак. Ә миңа, киресенчә, бу балалар белән рәхәт. Кирәк икән, мин аларга катырак та торам. Эшкә өйрәтүем дә алар өчен. Авыру балаларны алгач, аңламаучылар да булды. Әмма мин аларны яратам. Кешеләрдән авыр сүз дә әйттерәсе килми. Аллаһы Тәгалә шушы балаларны үстерергә көч, сәламәтлек, гомер бирсә иде, – дип тели ул. – Бала алып үстергәнемне зур эшкә санамыйм. Мактаганнарын да яратмыйм. Мин бит бу эшне үзем өчен, күңелем кушканга эшлим. Бер генә теләгем бар: игелек эшлисе килгән кеше ятимнәрне сөендерсен иде. Ә аларның рәхмәте гомер буена җитәрлек.

Ярдәм итәргә теләүчеләр өчен Резеда Хәлим кызы Сафина исемендәге Саклык банкы картасы номеры:

2202 2003 5703 7736.

Әлеге карта **89586274731** телефон номерына бәйләнгән.

ӨЕНӘ «КАМАЗ» КЕРГӘН РЕЗЕДА САФИНА:

«УЛЫМНЫ ХОДАЙ САКЛАДЫ»

Ялгызы өч малай тәрбияләүче, Апас районының Түбән Биябаш авылында яшәүче Резеда Сафинаның йортын яңартып бетергәненә бер ел гына була. Авыру бала – Илназларына уңайлы булсын дип, өйгә терәп, янкорма да салалар, мунча да төзеп куялар. Тик җитеш йортларында яшәргә генә насыйп булмый. Йокларга җыенып йөргән чакларында өйләренә «КамАЗ» килеп керә.

– Язмыш мине җитәрлек сынаган иде инде. Олыгайган көнемдә улларымның тормышына сөенеп, тыныч кына яшисем килгән иде. Тик насыйп булмады. Бөтенләй башка юлдан китәсе машина йортыбызга килеп керде, – ди Резеда Сафина. – Ул көнне без өйдә ике улым белән идек. Олысы Алмаз Казанда эшли. Минем янымда Айзатым һәм Илназ иде. Уртанчы улым янкормага кереп япты, Илназ исә ботка пешерүемне сорады. Аны ашаттым да, кухняга чыгып, чәй ясарга булдым. Менә шулчакта нидер булды. Көчле тавыш ишеттем. Газ шартлады бугай, дим. Түшәмнән балчык коела башлады. Күп үтмәде, кухня җимерелде. Ничек залга чыгып калдым…

Баксаң, янкорма да җимерелгән икән. Машина нәкъ шул яктан килеп кергән. Бөтен җире канга баткан Айзатын күрми дә Резеда апа. Каушап кала, куллары калтырый башлый. Соңрак, телефонын табып, олы улына хәбәр итә.

– Айзат, тизрәк киенеп чыгыйк, дигәч тә кием таба алмадым. Өс киемнәре торган бүлмә дә җимерелгән. Шкафларны ачарлык түгел. Йортның түбәсе урыннан күчте. Бер зал бүлмәсенә генә берни булмады. Без шунда тордык та инде. Ул бүлмәдә авыру улым иде. Аллаһы Тәгалә аны саклаган, дибез инде хәзер, – ди Резеда апа.

Алар тәрәзәдән чыга. Әле ул да җиңел бирелми. Авыру малайны тотып тору да, күтәреп алу да кыен була. Ярый, шул арада ярдәмгә килгән күршеләре, туганнары булыша. Гөлфия апалары Илназны үзләренә алып кайтып китә.

– Ул көнне уйласам, елыйсым килә. Гомер буе интегеп, өй җиткердек. Кемгә үпкәләргә дә белмим. Машина йөртүчесен дә кызганам. Тормозларым тотмады, рульне борып өлгермәдем, ди икән. Үзенең умырткалыгы сынып беткән. Әле машинасына килгән зыянны да аңа түләтәселәр ди. Безнең урамдагы газ торбасы да өзелде бит. Аны да шул егет төзәттерәсе икән. Яшь егет бит әле ул. Ике кечкенә баласы бар, – ди Резеда апа. – Үзе исән-сау терелсәм, аягымны сөйрәп йөргән очракта да сезне ташламас идем, ди икән. Ничекләр без ул егеттән акча сорыйк инде? Үз улларым да рульдә. Шуңа да без ул кешене кызгандык. Боларның йортын җимерим әле, дип кермәгән бит инде ул!

Гаиләне вакытлыча Ябалак авылында буш торучы йортка күчергәннәр. Әлегә үзләренең өйләренә керә алмыйлар. Бернинди киемнәр дә, кирәк-яракны да алып чыга алмаганнар. Бөтен әйбер җимерекләр астында калган.

– Ирем 50 яшендә үлеп китте. Табиблар, йөрәк, диде. Гомеремнең авыр чаклары иде. Әтиләре үлгәч тә, улларым белән тырышып яшәдек. Бераз акча булса, йортның әле бер җирен, әле икенче ягын яңартыр идек. Тик эшләгәнебез бушка китте, – ди ул. – Илназ авыру тугач, мин эшли алмадым. Быел инде улыма 18 тула. Аңа гел ярдәм кирәк. ДЦП диагнозлы ул. Аяклары да начар йөри, бар әйберне оныта. Аны ике айга бер тернәкләндерү үзәкләренә йөртә идек. Әлегә анысы да тукталып тора. Җимерелгән йортыбызны кирәдән торгызыр өчен күп акча кирәк. Үз көчебез генә җитмәячәк. Шуңа да мәрхәмәтле кешеләрдән ярдәм сорыйбыз. Булышсагыз иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ӘСХӘТ ХИСМӘТ:

«ТӘҖРИБӘ – ЯҢАЛЫК УЛ, КОЛАКНЫ БАШ АРКЫЛЫ КАШУ ТҮГЕЛ»

Аны олылар «Зәңгәр шәл»дәге Булаты, балалар Акбае өчен ярата. Чыңгыз Айтматов әсәре буенча куелган «Ахырзаман»дагы Ташчәйнәре дә тамашачы күңелендә саклана. Табигыйлеге, энергиясе, көчле рухы белән аерылып тора Татарстанның халык артисты Әсхәт ХИСМӘТ тудырган образлар. Артист нинди борчу-мәшәкатьләр белән яши? Кайдан көч ала? Нинди сөенеч-шатлыклары бар? Әңгәмә әнә шул хакта.

kitaphane.tatarstan.ru

:: Елны нинди нәтиҗәләр белән тәмамладыгыз, Әсхәт абый?

– Елны хәвеф-хәтәрсез үткәрәбез, шөкер. Инде санаулы көннәр генә калды… Дөрес, пандемия тормышыбызга үз тәртипләрен кертте. Хәзер иртәгә нәрсә буласын да әйтә алмыйбыз. Элек бит атналык план кора идек, хәзер алай эшләүнең мәгънәсе калмады кебек. Узган елны ук «тегә» чирне дә үткәрдек. Кирәк булгач, прививкасын да ясаттык. Кыскасы, сәламәтлекнең иң зур байлык икәнен аңладык. Тулаем алганда, ел әйбәт, бакчада да уңыш яхшы булды, театрда да рольләрем булып тора.

:: Бакча – сезнең өчен…

– …җан дәвасы. Агачлар, чәчәкләр белән сөйләшеп йөрергә яратам. Читтән караганда сәеррәк тоеладыр, ләкин алар да – җан иясе. Аларга да игътибар кирәк. Алмагачларның исемнәре дә бар бит әле безнең. Берсе Әсхәт алмагачы булып китте. Сорты «Башкирская красавица» бугай аның, менә шул агач баштарак үсә алмыйча интекте. Балачактан бакчачылык тәртипләрен күреп-белеп үсмәгәч, аның рәтен дә белеп бетереп булмый бит. Бер җиргә утыртам, монда ярамый, бакчаны каплап китәчәк, диләр, икенче җиргә күчердем. Бераз үсте дә туктады бу. Нәрсә булды икән, дим. Казып карасам, аста зур гына таш, тамыр җибәрә алмыйча интеккән. Ташны алгач, үсеп китте. Мин гел кайгырткач, янында биепләр йөргәч, Әсхәт алмагачы дип йөртә башладылар. Аның янында Булат алмагачы үсә. Ул агачны әле утырткан гына идек, шул ук елны бер алмасы ярадлы. И көтәбез үскәнен, нинди булыр, тәме нихәл икән дип. Дуслар кунакка килделәр дә, Булат, алма ашыйсыгыз киләме, дип йөгереп барды да, шул бердәнбер алманы өзеп алып та килде. Шуннан Булат алмасы булып калды. Зәйнәп апаның да алмагачы бар бездә. Аны ул кайгыртты чөнки. Тирән утыртылган бу, әйдә күтәрик дип күтәрттереп, мәш килеп йөрде. И, ул алмагачлар темасына керсәң! Калдырыйк без моны. Чугунка алмасы, Юныс абый алмасы, кызым Илсөяр алмасы турында көннәр буе сөйли алам мин. Миләшкә груша, грушага миләш ботаклары ялгау дисеңме, әллә нәрсәләр эшләп бетерәм мин бакчамда, шуннан тәм табам. Быел алма бигрәк уңды! Искә төшергәч тә, авызга сулар килә…

:: Пандемия безне нәрсәгә өйрәтте?

– Азрак бер-беребезгә игътибарлы булырга, ихтирам итәргә өйрәтте. Алайса, дөнья куа-куа бер-беребезне белми, күрми, санга сукмый башлаган идек бит. Ләкин кешеләр барыбер тәртипсезләр. Битлек киярргә кушалар, без барыбер кимибез. Үзең яшәгән җирне чүпләү турында әйтмим дә инде. Әйтик, безнең бакча табигатьнең иң гүзәл җирендә урнашкан. Әкешеләр, чүпләрен түгәргә иренеп, пароходка төшкәндә, юл буена ташлап калдыра. Элек шулкадәр чиста урын иде, хәтта черки юк иде. Хәзер чүп басты, черки басты, чебен басты… Барысы да үзебездән тора шул.

:: «Зәңгәр шәл»дә кайсы рольгә кадәр «үстегез»?

– Гаҗәеп спектакль ул! Шәкерт җыры белән башлаган идем, ишан роленә кадәр үсеп җиттем. 1977 елда училищеда укыган чакта ук Марсель Сәлимҗанов шәкерт җырын җырлаткан иде. Ул чакта шәкертне Барый абый Әшрәпов уйный, җырын мин җырлый торган идем. Яңа бинага күчкәч, 1986 елда Булат булдым. Аны 10 ел уйнаганнан соң, Марсель абый спектакльне яңартты. Анда инде Булатны Рамил Төхвәтуллин, мин Наил абый Әюпов белән Шәйхи бабай роленә кердем. Сүз уңаеннан бер кызык хәлне дә әйтеп үтим әле. Бервакыт Марсель абый белән Фәрит Бикчәнтәев шушы спектакль турында сөйләшәләр ди. Фәрит: «Нәрсәсе бар инде бу «Зәңгәр шәл»нең?» – дип әйтә икән. Марсель абый аңа: «Ашыкма, вакыт узар, үзең дә шушы спектакльне куярсың әле», – дип җавап биргән. Шулай булып чыкты да. Фәрит тә «Зәңгәр шәл»не үзенчә, яңача куйды. Анда инде мин ишанны башкарам. Рольләр күп, әмма иҗат юлым «Зәңгәр шәл» спектакленә бәйле булды дип әйтергә дә мөмкин.

:: «Зәңгәр шәл»дән ничә буын Булат үсеп чыкты. Халык барыбер элеккеләрен сагына. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?

– «Зәңгәр шәл»нең тарихына күз салсак, беренче Булатны Кәрим Тинчурин үзе уйнаган. Театрда бу турыда мәзәк тә йөри. Артистлар, Кәрим ага, рольләр дә бүленеп бетте, сез Булатны кем уйнаячагын гына әйтмәдегез, дип сорыйлар икән. Шуннан Кәрим ага «үзебез дип торабыз» дип җавап биргән. Бу җөмлә театрда канатлы фраза булып йөри хәзер. Аннан Азат Аббасов, Мәсгут Имашев, аннан соң бер генә тапкыр Айрат Арсланов уйнаган. Алардан соң Наил Әюпов, яңа бинада исә мин, Нариман Гарифуллин белән алмашка уйнадык. Ун ел Булат булдык без. Күбрәге миңа туры килде дип мактанып алсам да ярый торгандыр. Аннан Рамил Төхвәтуллин булды. Алардан соң Ирек Кашапов белән Ришат Әхмәдуллин рольгә керде. Булат образына килгәндә, халык шахтада чыныгып кайткан ир-егет образын сагына торгандыр. Алга таба да Булатлар булыр дип уйлыйм әле мин.

:: Булат дигәннән, улыгызга исемне «Зәңгәр шәл» спектаклендәге героегыз хөрмәтенә куйдыгызмы?

– Әлбәттә, шулай! Хатынны бала тудыру йортына илтеп калдырдым да, үзебез Күн авылына «Авыл эте Акбай» спектакле белән «Казан егетләре» спектаклен уйнарга киттек. Кайттым, улыбыз туган! Хатын хат язып чыгарган. Малаең үзеңә охшаган, нинди исем кушабыз, дигән. Минем әле «Казан сөлгесе»ннән Ильяс та бар бит. Хатын шуңа, Булат дип кушабызмы, Ильясмы, дип сораган. Булат исемен сайладык.

:: Җырчы булам дигән җирдән театр артисты булып киткәнсез. Хәзер үкенмисезме?

– Мәктәптә укыганда 42 бала арасыннан мин берүзем артист булам дип инша язган булганмын. Илһам абый Шакиров репертуарындагы җырларны яттан белә идем. Музыка белеме алырга дип килдем, ләкин укырга керә алмадым. Арттан төртүче юк иде. Кермәгәнемә үкенмим дә, чөнки мин театрда да җырлап уйныйм. «Туй алдыннан» дигән спектакльдә җырлатты мине Празат абый. «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Гөргери кияүләре», «Ханума», «Кара чикмән»дә дә җырладым. Менә «Әрем исе» спектакле чыкты. Илгиз Зәйнигә үзем белән булган вакыйганы сөйләгәч, ул аны пьеса итеп язган иде. Шушы спектакльдә «Әрем исе»н, «Бибисара»ны җырлармын дип ниятләп куйган идем, насыйп булмады. Гәрчә җыр сорап торган спектакль булса да. Халык җырлы-моңлы спектакльләрне ярата, ни дисәң дә. «Галиябану»ны һәр авылда, һәр сәхнәдә ник куйганнар дисеңме? Җырлы булганга, әлбәттә! Сәхнәдә гармун моңы да яңгыраса, тагын да күңелле.

:: «Яңа театр» дигән төшенчә барлыкка килде. Үзегезне яңа театрда күрәсезме?

– Яшьләргә тәҗрибәләр кирәк, һичшиксез. Тик шул ук вакытта өлкән буын тамашачыны да онытмаска кирәк. Алар бөтен тәҗрибәне дә кабул итә алмый. Бигрәк тә халыкның бәгыренә үтеп кергән классик әсәрләрне, халык җәүһәрләрен тәҗрибә корбаны итсәләр. Бу сәнгатьнең бар төренә дә кагыла. Шул исәптән җыр сәнгатенә дә. Яңа язылган, заманча җырларны теләсә нишләтсеннәр, әллә нинди тәҗрибәләр ясасыннар, бер сүзем дә юк. Тик «Арча көе»н, «Сарман»ны, «Гөлҗамал»ны, «Галиябану»ны бозып җырламасыннар. Зинһар өчен, ничек бар, шулай җиткерегез халыкка. Әйтик, «Үзгәреш җиле»н татар җырын Европага чыгарабыз дип оештырдылар, оркестр яллыйлар. Гәрчә үзебезнең Шутиков оркестры булса да. Аңа шушы бурычны йөкләсәң, бәлкем фестиваль татарча килеп чыккан булыр иде. Ник дисәң, Шутиков татар җырын Александр Ключарев кебек үк ярата, аңлый, нечкә тоемлый да. Алинә Шәрипҗанова – шәп җырчы, бернинди каршылыгым юк, әмма «Гөлҗамал»ны алай башкарырга ярамый. Ул җырны бит ярларын 25 елга сугышка озаткан кызлар җырлаган. Алар нинди генә егеткә барырбыз дип борчыла, чөнки авылда куштаннар гына калган. Җырның бит мәгънәсен аңларга кирәк. Озын сүзнең кыскасы, үзгәреш кирәк, тик ул үзгәреш мәгънә бозуга кайтып калмасын, киресенчә, сәнгатьне баетсын иде. Яшь режиссер Айдар Җаббаров тәҗрибәләре әнә шундый. «Хуш, авылым» спектаклен генә искә алыйк. Яңалык шундый була ул! Колакны баш аркылы кашу исә яңалык була алмый.

:: Уйналмаган роль калдымы, Әсхәт абый?

– Их, шул роль күңелдә калды, дип үкенечкә калган роль юк. Үкенү минем холкыма туры килми ул. Миннән барыбер Гамлет чыкмас иде. Мин – чып-чын татар ир-аты. Гомергә мөгез чыгармадым, ничек бар – шулай уйнадым. Бәлки шуңа

Блиц-сораштыру

– Тормышыгызда зур роль уйнаган шәхес?

– Әти-әнидән соң Марсель абый Сәлимҗановтыр, мөгаен. Ул мине укытты да, театрга эшкә дә алды, икесеннән кала, барлык спектакльләрендә дә уйнадым. Ул һаман: «Казанның мең еллыгын, театрның 100 еллыгын, үземнең 70 яшемне күрсәм, үлсәм дә риза», – дип әйтә торган иде. Кызганыч ки, берсен дә күрә алмады.

– Сәхнә ул – ...

– ...яшәеш. Дүрт баламның да үскән, тәрбияләнгән урыны. Булат – биредә «Су төбендә сөйгәнем», «Хуҗа Насретдин», «Зәңгәр шәл»дә, кызым Илсөяр «Әни килде», «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакльләрендә уйнады. Илсөярнең сәнгать юлыннан китәргә исәбе дә бар иде, мин каршы килдем. Авырлыктан саклыйсым килде. Хатын-кыз артистларга тормышны алып бару җиңел түгел.

– Күңелегезгә юаныч булырдай җыр?

– Кәефкә һәм халәткә карап сайлана инде ул. Бүген 1968 елны озатып, 1969 елы каршы алган мизгел гел күз алдында әле. Анда сәхнәгә без өчәү: әти – Кыш бабай, сеңлем Рәмзия – Кар кызы һәм мин алып баручы булып күтәрелдек. Ул чакта «Яңа елда – яңа җыр» дигән конкурс та бар иде әле. Шунда «Хәтерләү» дигән җырны башкардык. Менә шул җырны көйләп килдем әле. Гыйнварда булачак юбилей кичәмдә дә башкарырга исәп. Ә сәхнәгә мин, җырламасаң, «икеле» куям, дигәнгә генә чыккан кеше. Алтынчы сыйныфта укыган чак иде, «Җырлыйм әнием турында» дигән җырны башкардым. Менә шушы җыр сәхнәгә алып чыкты. Аңарчы да җырлый идем. Башлангыч сыйныфта мәхәббәт турында җыр җырлаганга, укытучы бик каты орышты. Куркудан еладым да бугай. Шуннан бик озак җырлый алмадым.

– Сезгә иң килешкән җыр «Бибисара» бугай.

– Бу җырны Барда районына баргач, Сәүбән Чуганаевтан алып кайттык. Саҗидә Сөләймановaның «Гөлбадран» повестеннан әткәй җыры ул. «Аһ, җаныем, Бибисара»ны хәзер Фердинант Сәлахов та җырлый, тагын берничә кеше башкара. Җырлансын, җыр ул җырланырга тиеш. Композитор Рөстәм Яхин да шулай дип әйтә торган булган. Аның «Күзләрем тик сине эзлиләр» дигән җырын да бик яратып җырлыйм. Ул җыр миңа килешәрәк бугай.

фильмнарга да чакырганнардыр. Эдмас Үтәгәнов «Яшьнәп үткән яшьлек» фильмына чакырган иде. Аннан соң Әхтәм Зарипов рольле итте. Аннары «Мыраубатыр»да Ризван байны уйнадым. Аннары Нурания Җамалиның «Китәм, димә», «Яланаяклы кыз», «Еракгагы якты йолдызым», «Җылы эзли җаннар» фильмнарында уйнадым. Әйтәм бит, мөгез чыгармадым. Ничек күрәм образны – шулай башкардым. Телевидение «Авыл эте Акбай» спектакле аша да кешегә танытты мине. Бер туй мәҗлесендә кәләш: «Сез бит – Акбай!» – дип, гаҗәпләнүеннән урынына утыра алмыйча торды. Андый мизгелләрдә эчкә җылы йөгерә, беләсеңме... Акбай – бер хәл, 20 елдан артык Кыш бабай да булдым әле мин. Өлкән кешеләр хәзер дә, безнең балалар синең Кыш бабаеңны күреп үсте, дип рәхмәт әйтеп китәләр. Хәзерге Кыш бабайларны карыйм, әллә нинди алар шунда. Заманына күрәдер инде... Кыш бабай, минемчә, олпат ул, «вуги-вуги»га сырпаланучы түгел.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Язып кына карыйм

БАШСЫЗ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

< Ахыры. Башы 26 ноябрь, 10, 17 декабрь саннарында

Рәхмәт хисе

Күңелеңне рәхмәт хисе балкытып торанда явызлык кылып булмыйдыр. Чөнки ул кешенең үзен дә нурландыра, якты омтылышларга этәрә. Кеше күңеленең иң саф чагы – аның рәхмәтле вакыты. Дога-гыйбадәтләрнең нигезендә дә нәкъ менә шушы үзенчәлек ята. Ходайга рәхмәтле булу, мактау яудыру ул Алладан бигрәк, бәндәнең үзе өчен кирәк. Күңелен сафландыру, яшәү көчен яңарту өчен.

Алдан билгеләнгән эшләрне, авырып киткәч, кичектереп торырга туры килә. Һәркем белән аерым-аерым сөйләшүдән ялкып, «Инстаграм»да һәм «ВКонтакте»да шундыйрак пост урнаштырдым: «Бөтен эшләр билгесез вакытка кичектерелә». Шулай итсәм, җайлы гына котылырмын кебек иде.

Ләкин бу хәл белешеп шалтыратучылар санын арттырып кына җибәрде. Шул пост астында да хәлне белешеп, ярдәм тәкъдим итеп, изге теләкләр теләп язган язулар йөздән артып китте. Шәхси хатлары да шул чама булгандыр. Киңәш бирүчеләр, теләк теләүчеләр, дару, акча, тагын әллә нинди ярдәмнәр тәкъдим итүчеләр. Әгәр бөтен теләкләр дә кабул булса, барлык даруларны да куллансам, мин әле тагын йөз ел яшәргә мөмкинмен.

Үземә язарга яки шалтыратырга кыймаганнар хатынга шалтыраткан. Минем хәлне аның аша белешкәннәр. «Маратны сакларга кирәк... Маратны коткарырга кирәк... Маратны...» Теләкләре изге, әлбәттә. Тик хатынның хәле ул чакта минекеннән күпкә авыррак иде. Үлем белән тартышып яткан чагында «Маратны... Маратны...» дигән сүзләрне ишетү аңа бик рәхәт булды микән инде? Бәлки аның үзенең дә: «Хәлең ничек?» – дигәнне ишетәсе килгәндер. Белмим. Сорарга кирәк әле.

Ләкин бөтенләй эндәшмичә калсалар, барыбер бик кыен булыр иде. Ә кешеләрнең шулай хәлемә керүе, теләктәшлек белдерүе зур этәргеч булды. Мин үземнең шундый кирәкле кешир яфрагы икәнемне бик белми идем әле. Укучыларының, әдәбият сөючеләрнең шулай күтәреп алуы, кадер-хөрмәт күрсәтүе зур нәрсә икән. Күңелеңә канат куя, рухыңа көч өсти. Кара көннәреңнең кояшына әверелә. Чынлап та кешеләрдән килгән ул якты хисләр синең җаныңа җыела бит инде, аны тылсымлы бер нур белән балкытып җибәрә, гайрәтлерәк итә, яшәү көче өсти. Әгәр әнә шундый кешеләрең булмаса, берүзең генә беркая да китәлмисең, бөгелүең, сыгылуың, сынуың да ерак түгел.

Мин һәркайсыгызга рәхмәтлемен. Киләчәк тормышымда, язылачак әсәрләремдә сезнең дә өлешегез бар, зур өлешегез бар, дип уйлыйм. Рәхмәтләремнең яктылыгы сезнең тормышны да балкытып яшәсен. Бәхетле булыгыз!

Мине көн саен диярлек сөендереп торучы тагы бер нәрсә бар әле. Бергә яткан кешеләргә кайвакыт эш урыныннан шалтыраталар. Болар трубкаларын алмый: «Чистый ялкыттылар инде», – дип сүгенеп куялар. Сәбәбе гади генә икән. Аларга: «Кайчан чыгаралар, кайчан эшкә киләсең?» – дип шалтыраталар икән. Бу да бәлки ихтыяҗ, кешеләргә кирәклелек билгеседер инде. Ә бәлки хезмәткәрләреңә шәхес итеп түгел, ә эш аты дип караудыр.

Минем бу мәсьәләдә дә хәлләр үзгә иде. «Ватаным Татарстан» газетасыннан кем генә, кайчан гына элемтәгә чыкса да, хәл белешә:

– Нинди ярдәм кирәк? Нәрсәләр китерик? – дип кызыксына. Мин сөенәм. Кирәкле әйберләр булса, алып килергә кушам. Китерәләр. Кайчагында кыенсынып та куям:

– Соңгы вакытта бернәрсә дә язып булмый бит әле...

– Син ул хакта уйлама әле, Марат, – диләр. – Башта савыгып чык.

Мондый мөнәсәбәт тә кешегә канат куя. «Терелеп кенә чыгыйм әле, эшләп күрсәтермен», – дип уйлыйм үзем дә. Һәм бөтен булмышым терелүгә, эшләүгә көйләнгән шикелле тоела. Синең бүген кем булуың түгел, кая омтылуың мөһим. Хәтта бер хәлең калмаса да, үзең омтылган якка авасың. Хәлең булса – атлап китәсең. Канатларың булса – күтәрелеп. Кешенең киләчәгеннән аның омтылышы билгели.

Яхшы кешеләр арасында кайнау ярты бәхет инде ул. Син аларга һәрвакыт рәхмәтле буласың. Рәхмәт хисе яшәү көче бирә...

Ркаил Зәйдулла шалтырата

Бер мәлне Ркаил Зәйдулла шалтырата. Бу – вакыйга. Минем өчен.

Язучылар берлеге рәисе, халык шагыйре... Гомумән, татар дөньясында абруйлы шәхес. Әгәр шалтыратса, сезнең өчен дә вакыйга булыр иде...

Язучылар берлеге рәисләре хәтсез генә. Кемнәрдер элек булган, кемнәрдер киләчәктә булыр. Халык шагыйрьләре дә күп. Ә Ркаил – берәү. Эш аның биләгән вазыйфасында да, мактаулы исемнәрендә дә түгел. Эш аның шәхесендә.

Мин һәр язучыны талантлыдыр дип уйлыйм инде. Аерма шунда гына: кайберләренең әсәрләрен көтеп алып укыйм, кайберләрен укып тормый гына талантлы дип уйлыйм. Шулай җайлырак чөнки. Укысаң, фикерең үзгәрергә мөмкин. Ләкин шундый талантлы кешеләр арасында да үзең тиңсенгән шәхесләр сирәк була. Рухташ дип атарга мөмкиндер инде андыйларны. Иҗатын да яратасың, үзен дә хөрмәт итәсең. Тоткан юнәлешләр дә, уйлаган уйлар да бер чамарак булып чыга. Чынлабрак эзли башласаң, хәтта характерның да уртак яклары табыла. Алар белән рәхәтләнеп, бернәрсәдән шикләнмичә ачылып сөйләшеп, үзеңә ышанган шикелле ышанып була. Күп булмый инде андый кешеләр. Бармак белән генә санарлык. Шуңа кадерле дә. Һәр аралашу үзе бер вакыйгага әверелә.

Менә бу юлы да Ркаил абый шалтырата. Мин хастаханәдә ятам. Бу чирнең аңгырайта торган гадәте барлыгын әйткән идем инде. Тагын шунысы да бар әле: кеше белән сөйләшәсе килми. Беркем белән дә. Сөйләшү – мәшәкать. Монда кешене ишетергә, сүзенең мәгънәсен аңларга, ничек җавап бирергә кирәген ачыкларга, уйларга һәм дөрес итеп җавапларга кирәк. Бу үзе үк бер эш шикелле тоела. Ә монда Ркаил Зәйдулла үзе шалтырата...

Ә мин төне буе юньләп йокламаган. Күршедәге палатада тавышланып чыктылар. Мин аны башта кемнеңдер үзе өрә дип уйлаган идем. Әйтәм ич баш бик эшләп бетерми бу чир белән. Кем палатага эт ияртеп керде икән? Ник ул шулкадәр өрә икән? Аны нигә алып чыгып китмиләр? Уянып торып утыргач кына аңладым. Бернинди дә эт юк, пациентның үпкәсе шундый тавышлар чыгара икән. Ул төн буе газапланды да таң алдыннан каядыр алып киттеләр. Кая икәнен соңыннан гына белдем, туганнары документ тутырып йөргәндә генә...

Ркаил абый шалтыратканда да берәүне алып китеп баралар иде. Мин сантый сорамый калалмадым. Кичә генә коридорда күреп калган идем әле. Шуңа кызыксынганмындыр инде.

– Моргка, – дип җаваплады яшел халатлыларның берсе. – Шундый хәлләр.

Үземнең дә тән эсселе-суыклы булып куйды. Хатын икенче хастаханәдә ята, ул да хәбәр итеп тора. Әйбәт кенә йөри дә кеше, кинәт чире көчәеп китеп бара. Аларда да шундыйрак хәлләр икән. Күреп тә, ишетеп тә торгач, рәхәт түгел. Әҗәл синең тирәдә йөридер, ул бер мәл синең дә караватыңа килеп утырып кулыңны сорар кебек тоела.

Мин шундый моңсу уйлар белән трубканы алдым.

– Больницада ятасың икән, – ди Ркаил абый. – Кайда ятасың? Әйбәт карыйлармы? Берәр төрле ярдәм кирәкмиме? Кирәк булса әйт, кыенсынып торма, җайларбыз.

Бу сүзләрне ишеткәч, рәхәт булып кала. Үзең сөйләшергә теләгән кешеләр сирәк шалтыратучан була. Ә ярдәм тәкъдим итеп шалтырату тагын да сирәгрәк. Сөйләшеп алабыз. Күңел ачылып китә.

– Борчылма, – ди Ркаил абый, – мин дә чирләп алдым. Хәзер әйбәт инде, вирус юк. Барысы да әйбәт булачак, Марат. Ул кадәр куркыныч чир түгел ул.

Мин үземнән ерагая барып, моргка юнәлгән каталкага карап алам. Шул тәгәрмәчле табут янында Ркаил Зәйдулланың сүзләре бик үк дөрес түгелдер кебек тоелып китә. Юату өчен генә әйтәдер кебек. Ләкин... Ул сүзләр шундый көчле, ышанычлы яңгырый. Хакыйкатьнең үзе шикелле.

– Барысы да әйбәт булачак, Марат. Ул кадәр куркыныч чир түгел ул.

Һәм мин Ркаилга ышандым.

Әле менә шул чакларны уйлый-уйлый хастаханәдән кайтып киләм. Үз аягым белән.

Шагыйрьләргә ышанырга кирәк.

26 октябрь – 14 ноябрь, 2021 ел

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

✓ мини-тракторлар;
✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә – 465 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә – 1000,92 сум

Реклама 16+

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru



Рәис Габдулла

17 декабрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Мәләвез, Нигерия, Ахир, кушу, нисан, Ури, Кабо, инәлү, Лев, Танич, Кир, әйе, турка, чәлү, Хөснияр, колба, Твин, тачка. **Вертикаль буенча:** Кук, хата, Али, Шуберт, скит, Мансуров, Нона, Раил, Логан, итәк, ябык, ехидна, Арча, варис, әнә, Ираклий, зая, үчегү.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Сәхипгәрәй хан идарә иткән еллар.

А) 1521–1524;
Б) 1551;
В) 1497–1500.

2 Аркадий Гайдарның «Тимур һәм аның командасы» исемле повесте йогынтысында нинди хәрәкәт популярлаша?

А) фриганнар;
Б) кызыллармиячеләр;
В) тимурчылар.

3 «Барбаросса» планы ул – ...

А) күмәкләштерү сәясәте;
Б) 1941 елда Советлар Союзына каршы яшен тизлегендәге сугыш – блицкриг үткәрүне, Германия гаскәрләренең өч ай эчендә Архангельск – Әстерхан сызыгына чыгуын күздә тота;
В) «Россия халкы арасында наданлыкны бетерү турында» Декретның бер өлеше.

4 Кайсы рәсем К.С. Петров-Водкинныкы?

А) «Степан Разин»;
Б) «Кызыл атны коендыру»;
В) «Маршал Жуков портреты».

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) Б; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 388

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+